№ 4 2018

ТУГАРӘК УЕН

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

Урамнарда
гармун бәйрәмнәре,
Бәйрәмнәрдән ничек каласың?!
Өзгәләнә гармуннары илнең,
Уятырга адәм баласын.

Сөлге башы. Тамбурлы чигү. XIX гасыр уртасы. Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана.

Харрас ӘЮП

Гармун бәйрәме

Урамнарда гармун бәйрәмнәре,
Бәйрәмнәрдән ничек каласың?!
Өзгәләнә гармуннары илнең,
Уятырга адәм баласын.

Өзгәләнә гармуннары илнең...
Халык җаны, димәк, буш түгел.
Әйтер сүзен ул бит гомер буе
Гармуннарга, җырга кушты гел.

Буш булалмый бүген халык җаны,
Шуңа карап гамәл кылына:
Кемдер җирдә кылыч күтәргәндә,
Гармун ала татар кулына.

Гармун ала татар...
Җилкендерә
Эчләрендә җаны булганны.
Көйләр булып күтәрелә еллар...
Җиңеп кара шушы моңнарны!

Мәйданнарга гармуннары чыга
Ялганына каршы ятларның –
Кылычларың бер яктарак торсын,
Гармуннары барда татарның...

Өзгәләнә гармуннары чорның,
Күңелдәген әйтеп, илдәген.
Бәйрәм генә булыр иде җирдә,
Тыңласалар халык йөрәген...

№ 4 2018

ТУГӘРӘК УЕН

Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

*«Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул»*

16+

Гамәлгә куючылар:

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Редколлегия:

Әхмәтҗанов М.И.
Бакиров М.Х.
Вәлиева З.Р.
Вәлиев Р.И.
Гайсин И.З. (Мари Эл)
Деникаева В.А. (Ульян)
Заһидуллина Д.Ф.
Каюмова Э.Р.
Локманов А.Х. (Башкортостан)
Сибагатуллин А.М.
Тукаев М.Р.
Шәрәфиева Р.Г.
Юсупов Ф.Ю.

Директор: **Фәнзилә Җәүһәрева**

Баш мөхәррир: **Илсөяр Иксанова**

Альманахның иҗат төркеме:

Гөлсинә Хәмидуллина
Сөмбел Толпегина
Раилә Хәялиева
Мөнирә Кузиева

Альманах 2014 елның 5 августында элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77-58939. Өч айга бер чыга.

Бу санны бизәүдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Г. Тукайның әдәби музее фондларындагы, Гөлсинә Хәмидуллина, Рәилә Хәялиева, Гүзәл Гыймадиева, Лилия Бәхтиева һәм авторларның шәхси архивларындагы фотолар файдаланылды.

Кәгазь форматы 60x90$^{1}/_{8}$. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды 12.11.2018 ел. Заказ Е-3015.
Тираж 1050 экз.

Редакциянең адресы: 420021, Казан, Тукай урамы, 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин урамы 66/33 йорт.
Телефон: 293-27-99. E-mail: tugarakuen@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Казан, Декабристлар ур., 2.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен»нан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

4 Фестиваль
Раилә Хәялиева
Актаныш гармуннары

8 **Фидакарьләр**
Гөлназ Гыйлемҗанова, Гөлсинә Хәмидуллина
Тугрылык

27 **Фестиваль**
Раилә Хәялиева
«Берзаман бардым Печән базарына...»

30 **Фольклор туган җирдә**
Илсөяр Гарипова, Гөлсинә Хәмидуллина
Сәфәр чыктык Себергә

© «Түгәрәк уен», 2018

44

Күргәзмә

Гөлнара Гарипова
Лилия Закирова
Самавырлы табыннан башладык...

46 **Тарихын белмәгән халык – тамырсыз агач**
Гали Рәхим
Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

50 *Нурихан Фәттах*
Сызгыра торган уклар

55 *Гөлнур Хәйруллина*
Балан ачымы?



58 **Вәгазь-нәсыйхәт**
Мөхәммәт Галләм
Тугры юл

УЕНДА ҖИҢГӘН – ҖЫЕНДА ҖИҢӘР

62 Без, без, без идек...

64 **Өй күрке – аш**
Раилә Сабирова
Гөлҗимеш кәтере

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Актаныш гармуннары

Ул көнне Актанышта уракка төштеләр. Яңгырлар вакытында явып, илгә-көнгә җитәрлек мул уңыш алырга насыйп булсын иде дип, хәер-догада үстерелгән игенне җыеп алырга старт бирелде, кырларда икмәк исе таралды. Шул ук вакытта, әле кайчан гына чәчүчеләрне данлаган Сабантуй мәйданында өздереп-өздереп гармун уйнаган тавышлар ишетелә, «Актаныш гармуннары» фестиваленә килгән кунаклар шау-гөр килә иде. Тырыш татар халкы яшәгән җирлектә икмәк белән моң бәйрәменең бер көнгә туры килүе дә юкка гына булмагандыр әле!

«Икмәк булса,
Җыр да була –
Икмәк илгә көч бирә!» диләрме?!

Беренче көн

«Актаныш гармуннары» фестиваленә кайлардан гына килмәгәннәр! Удмуртия, Оренбург, Төмән өлкәсе, ут күршеләр – Башкортостаннан, шулай ук республикабызның төрле районнарыннан гармунчылар җыелган. Кемдер баян тоткан, кемдер тальян, Саратов, Вараксин, Тула гармуннары... Сабантуй мәйданының һәр почмагында дәртле көйләр яңгырый. Иң мөһиме, олы-олы апалар, абыйлары янында яшь-җилкәнчәкнең мәш килеп йөрүе күңелне сөендерә!

Актанышлылар – кунакчыл халык. Мәйданга килгән һәркемне самавырда кайнаган төрле үлән чәйләре, тәбикмәк белән сыйладылар. Керү уңаенда ук Әлфия Авзалова тормышына, иҗатына багышланган матур татар йорты тора. Мәйдан эчендә оештырылган күргәзмәләрдә Актаныш районының күп кенә авылларының шәҗәрәсе һәм тарихы белән танышырга була иде.

Күктә хәлне ала торган август кояш кыздыра, күңелне якында гына агып яткан Агыйдел ымсындыра, дәртле тальян моңнарыннан баш әйләнә торган аерым халәт иде биредә. Гармунчыларны, аларның кызыклы гармун тарихларын ишетергә мәйдан эченәрәк узам. Биредә танылган татар гармунчылары осталык дәресләре бирә иде. Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге хезмәткәре Дамир Алмаз улы Габдрахманов тарафыннан эшләнгән «Татар гармуннары һәм аларны ясаучы осталар» фотокүргәзмәсе дә бик кызыклы. Гармунчылар инде алдан ук билгеләнгән «Сөн», «Агыйдел», «Ык» мәйданчык-

ларына җыелган. Фестивальнең беренче көнендә бәйге кысаларында конкурсантларны тыңлау каралган иде. Балалар, аерым башкаручылар, ансамбль булып чыгыш ясаучылар бәйгегә әзерләнә, жюри каршында тырышып чыгыш ясый.

Фестивальдә катнашучы кунакларның саны 280ләп булса, Актанышның үзеннән генә дә тагы йөзгә якын кеше кушылды. Районда гаилә белән гармун уйнаучылар да, Сабантуйларда гармун уйнап халык күңелләрен кузгатучылар да шактый икән. Мөхәррам абый Мөхаззаров Усы авылыннан килгән. Әллә нинди кызыклы тарихлары булган, сул кул белән уйнарга яраклаштырылган ун телле Вараксин гармунында уйный ул. Малай чактан ук бик авырлык белән уйнарга өйрәнгән гармунын әле дә кулыннан төшергәне юк икән. Гомер буе иген иккән, җиргә хезмәт иткән Мөхәррам абый тормыш юлын гармун белән узган. Егетләрне солдатка озатулар, туйлар, клубтагы кичәләр... берсе дә гармунсыз үтмәгән! Авыл Сабантуйларында хәзер мәйданга гармунчылар чыкмавына өзгәләнә Мөхәррам абый. «Сабантуйда бер уйнасам – күңелемә еллык азык җыеп кайтам. Гармун тавышы ишеткән халык кутәрелеп китә. Халыкка гармун моңы кирәк!» – ди ул. Флера апа Насретдинова Башкортостанның Краснокама районыннан килгән. «Гармун уйнарга алтынчы класста өйрәндем. Мәктәптә гомер буе балаларга гармун уйнадым. Инде мондый зур фестивальгә килә алуыма бик бәхетлемен», – дип хисләре белән бүлеште гармунчы ханым.

Көн кичкә авышкач, гармунчылар парады үтте. Аны район башлыгы, әлеге фестивальнең идея авторы Фәттахов Энгель Нәвап улы үзе җитәкләде. Фестиваль ачылышына багышланган зур концерттан соң, «Көй тартыш» бәйгесе башланды. Әлеге ярышта катнашыр өчен 28 гармунчы сәхнәгә күтәрелде. Җиңүчегә район җитәкчесе махсус бүләк

Илгиз Закиров, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

Фестивальнең бәйге өлешендә мин яшь башкаручыларны тыңладым. Балалар мәйданында 28 гармунчы чыгыш ясады. Барысы да бик сокландырды, өметле күренәләр! Яшьләрнең тальян-гармуннарга тартылмавын заманга гына сылтамыйк. Кеше күңеле кечкенәдән милли моңнарны ишетеп, моңга гашыйк булып үсәргә, күңелендә моң йөртергә тиеш. Шулай булганда ул үзеннән-үзе гармунга тартылачак.

Актаныш районы башлыгы Энгель Фәттахов үзенең хәләл җефете Сәрия ханым белән татар гармунына куелган һәйкәл янында.

әзерләгән иде. Бәйгенең беренче өлешендә жюри тарафыннан тәкъдим ителгән көйне уйнап күрсәтте гармунчылар. Бөтен катнашучы да уйнап бетергәч, иң осталарны сайладылар. Икенче өлештә исә катнашучыларның саны җидегә, өченчедә дүрткә калды. Жюри өчен дә, гармунчылар өчен дә ярыш катлаулана гына барды. Гармунчылар торган саен остарак, бизәклебрәк уйнады. Ниһаять, финалда Саба районыннан Айнур Габделхаков белән Актаныштан Гөлсияр Хәсәенова гына калды. Ике сәгатькә якын авыр гармунын күтәреп егетләр белән бертигез ярышты гармунчы ханым. Көйләр һаман да авырая, салмаклана барды. Тамашачылар дулкынланып, көч биреп торды. Озак уйланулардан, тамашачыларның тартышыннан соң, җиңүче булып Саба егете Айнур Габделхаков табылды.

– Баянны кулыма беренче тапкыр өченче сыйныфта алдым. Аннан соң Сабада музыка мәктәбенә укырга кердем, анда шулай ук тальянда, курайда уйнарга өйрәндем. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, укуымны Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятендә дәвам иттердем. Гармун уйнау минем күптәнге хыялым иде. Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасының фольклор музыкасы дәүләт ансамблендә эшли башлагач, гармунда ныклап уйнарга өйрәндем. Бүгенге көндә Сабада мәдәният хезмәткәре булып эшлим, – дип сөйләде ул бәйгедән соң.

Фән Вәлиәхмәтов, Татарстанның һәм Башкортостанның халык артисты:

Актаныш районы, мондый зур гармунчылар фестивале оештырып, татар моңына һәйкәл куйды. «Актаныш гармуннары» фестивалендә яңгыраган көйләребез яшьләрнең күңелләрендә уелып калсын иде. Көйсез-моңсыз берничә буын үсте. Инде моннан соң безнең балаларыбыз милли моңнарыбызны сеңдереп үссен иде, дигән теләктә яшим. Чөнки тел ул – моң белән бергә саклана. Мин гармунда уйнарга кызларга гашыйк була башлагач өйрәндем. Элек, кызлар егетләргә түгел, гармунга гашыйк була иде. Шуңа егетләр гармунда уйнарга өйрәнергә, кичәләрдә гармун уйнарга тырыша иде. Мин туып үскән Хафиз авылында (Башкортостанның Шаран районы) 23 йортка 25 гармунчы бар иде. Ә хәзер районында бер гармунчы юк дип әйтерлек. Гармунның дәрәҗәсен күтәрергә, яшьләрне гармунга тартырга иде!

Икенче көн

Икенче көнне бәйгенең дәвамы Актаныш урамнарында дәвам итте. Шәһәр урамнары буйлап оста гармунчылар, баянчылар атлады. Хакимият йорты каршында туктап, өздереп, татар халык биюләрен дә башкардылар. Актаныш урамнарын моңга күмеп, гармунчылар шәһәрне ике өлешкә бүлүче дуслык күпере – «Актаныш басмалары»на төштеләр. Биредә чараның ябылу тантанасы, җиңүчеләрне билгеләү булды, ә иң мөһиме – бәйгенең киләчәге булуын раслаучы һәйкәл-стела ачылды. Яңа Әлем егете Азат Сәрвәров аны якынча 15 көн эчендә тимердән чүкеп ясаган.

Һәйкәлне ачар алдыннан Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрева сүз алды.

– Хөрмәтле актанышлылар, хөрмәтле Актаныш кунаклары, кадерле гармунчыларыбыз! Фестивалебезнең беренче көнендә, Агыйдел буйларында таңга чаклы уйнаган көйләребез «Бер кайтмасак, бер кайтырбыз», – дип, гармунын иңенә салып Алман сугышына чыгып киткән, сугыш кырларында ятып калган гармунчы ир-егетләребез рухына да, «Мин кайтканчы гармунымны сакла, улым өйрәнә торсын», – дип яуга киткән иренең тальянын кадерләп саклаган тол хатыннар рухына да, Актаныш җире биргән бөек шәхесләр рухына да, татар гармунын сәхнәләргә алып менгән Фәйзулла ага Туишев, Исмәгыйль

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрева Сарманнан килгән гармунчы Рафис Мусин белән.

ага Мусин, Оркыя апа Ибраһимова рухларына да, XIX гасырның икенче яртысында шаулаган Татар, Нижгар базарларында татар көйләре уйнап халыкны таң калдырган гармунчылар рухына да, авылларның данын еракларга җиткезгән гармунчылар нәселләренә дә дога булып барып ирешсен! Бүген дә Сабантуйларның бер мәйданы көрәш булса, икенче мәйдан гармунчыларныкына әверелсен, анда гармун тартыш уеннары гөрләсен иде! Гармунчыларның дәрәҗәсе күтәрелсен! Ә сез, фестивалебезнең кадерле кунаклары, җәй җитеп, тирә-якта чәчәк исләре тарала башлагач, «Актаныш гармуннары» фестиваленә барасы иде, дип яшәгез! Киләчәктә «Актаныш гармуннары» татарны әйди һәм били торган сихәтле урын булып кала бирсен! – дип фестиваль кунакларын

Энгель Фәттахов, Актаныш муниципаль районы башлыгы:

Безнең халык һәрвакыт җыр-моң белән юанып яшәгән. Мин үзем дә бернинди сәнгать мәктәпләрен тәмамламасам, музыкага махсус өйрәнмәсәм дә, эч пошкан саен кулыма һәрвакыт гармун алам, халык көйләрен уйнап юанам. Фестивальдә тәүге тапкыр сәхнәгә чыгып, Нәвап әткәемнең яраткан «Сагынам дуслар» көен уйнадым.

Халкыбызның гореф-гадәтләре сакланып калган, төпле нигезе, ныклы тәрбиясе булган Актанышны кечкенә татар дәүләте итеп күрсәтәсем килә. 90% татар халкы яшәгән җирлек буларак, гармунчылар фестиваленең нәкъ бездә узуы дөрес булды дип уйлыйм. Ай тотылган төндә «Актаныш гармун»нары гөрләде. Бу гомердә истә калырлык тарихи вакыйга булды! Актаныш халыкка талантлы гармунчылар – Кирам Сатиев, Нәфис Мәүлитов, Фәрит Хәбибуллин, Мирзанур Фарукшин, Илгиз Закиров, Инсаф Хәбибуллиннарны биргән район ул. Без алар белән бик горурланабыз. Киләчәктә дә Актанышның гармунчылар нәселе саекмасын, Актаныш урамнары гармун моңына күмелеп яшәсен иде!

җилкендерде ул. Ул арада сәхнәдә Фәнис Яхин башкаруында «Тальяннарга һәйкәл куяр идем» дип исемләнгән өр-яңа җыр яңгырады. Әлеге җырның авторы Уфа шәһәрендә яшәп иҗат итүче татар шагыйрәсе Дилә Булгакова. Җырны исә көйгә Актаныш композиторы Инсаф Хәбибуллин салган.

Каешыңда исемең бар,
Укалап уяр идем.
Мөмкин булса, тальяннарга
Һәйкәлләр куяр идем...

Шөкер, гасырлар буе халкыбызның рухи бердәмлеген ныгыткан, иң авыр чакларда да күңелен күтәргән, шатландырган, юаткан татар гармунына да Актаныштa һәйкәл куелды. Фестиваль көннәрендә кем белән генә аралашсам да бер уртак фикер яңгырады: туган тел ул милли көй, милли моң белән бергә яши, бергә саклана. Киләчәктә дә куллардан гармун төшмәсен, тальян моңнары онытылмасын иде!. Ә «Актаныш гармуннары» фестивале, бәйге кысаларыннан чыгып, гармунчыларны берләштерү, халык көйләрен торгызып, киләчәк буыннарга җиткезү мәйданына әйләнде. Ул һичшиксез әле дәвам итәр, киләсе елларда тагы да күбрәк гармунчылар җыелыр, мәйданнарны шаулатыр!

Тарих битләреннән:

Гармунның тарихы XVIII гасыр азагына барып тоташа. Аны беренче булып 1782 елда Берлин остасы Бушман ясаган дип исәпләнә. Шул еллардан башлап бик күп кенә осталар гармунны үзгәртү, камилләштерү юнәлешендә эшли. Гармунны Вена шәһәрендә һәм Италиядә, XIX гасырның 30нчы елларында Россиянең Тула шәһәрендә ясый башлыйлар. Елдан-ел бу уен коралы камилләшә бара. Аны ясаучы осталар гармунның Тула, Вятка, Бологой, Саратов, Себер, Касимовка һ.б. төрләрен булдыралар. Аннан соң ике рәтле Вена гармуны, бигрәк тә хромка дип аталган төре популярлык казана.

Татар гармуны исә Михаил Вараксин дигән оста исеме белән бәйле. XX гасыр башында Вятка губернасыннан килгән бу кеше Казанда гармуннар ясый башлый. Вараксин гармуннарының даны тиз арада еракларга тарала. 1934 елда Казанда гармуннар фабрикасы төзелә, ул 1950-1960 нчы елларда аеруча киң колач ала. Талантлы яшь осталар барлыкка килә. Әмма ләкин электрон музыка уен кораллары кулланышка керә башлагач, әлеге фабрика ябыла. Хәзер инде татар гармунын аерым осталар гына ясый.

Гөлназ ГЫЙЛЕМҖАНОВА,
Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА

Тугрылык

Быел республикабызның данлыклы коллективы, Халыклар дуслыгы орденлы Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамбленең тәүге тапкыр сәхнәдә чыгыш ясавына 80 ел тулды. Бүген ансамбльне хаклы рәвештә Татарстанның визит карточкасы диләр, чөнки ул республикабызда халкыбызның милли традицияләрен, җыр-биюләрен үз асылында саклаучы һәм заман җилләре тидермичә халыкка җиткерүче төп коллектив булып тора. Әлеге абруйлы миссияне башкаруда ансамбльгә кайчандыр япь-яшь егет-кызлар булып килеп, беренче чыныгу алган, сәнгать серләренә өйрәнгән һәм бар көчләрен, талантларын шушы коллективка багышлаган хормейстер Венера Хәсән кызы Гәрәева, балетмейстер Раилә Мөхәммәтхан кызы Гарипова һәм дирижер Рәшит Шәкүр улы Мостафинның өлеше чиксез зур. Шөкер, алар бүген дә сафта, бүген дә татар сәнгатенә хезмәт юлында.

Данлыклы ансамбльнең юбилее уңаеннан, Татарстанның халык артисты, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш дирижеры һәм оркестр җитәкчесе Рәшит Мостафин белән очраштык.

– Рәшит абый, Сез Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә 1964 елда килеп кергәнсез дә гомерегез буена шушы данлыклы коллективка тугры калгансыз...

– Әйе, шулай килеп чыкты шул... Мине эшкә Марс Андреевич Макаров кабул итте. Без аның белән училищеда укыганда таныштык. Килеп кергәндә дүрт кенә баянчы идек – миннән өч курска алдарак укыган Насыйх Вильданов, Марс Макаров, Илдар Җаббаров һәм мин. (Ә башта, ансамбль оешканда, ике баянчы була – Гали Җәмлиханов һәм Габдулла Халитов.) Без бөтенебез дә бер укытучыда – Ильяс Ислам улы Шәриповта укыдык. Ул вакытта конкурс бик җитди. Мине ансамбльнең ул вакыттагы сәнгать җитәкчесе Җәүдәт Кәрәмәтулла улы Айдаров эшкә алды. Ләкин, программага кермәгән дип, беренче гастрольдән мине әле калдырдылар. Ул вакытта ансамбль гастрольдә ике-өч ай йөри иде. Хәзер иң озагы – атна-ун көн.

– Оркестр ничек оешты – шул турыда сөйләп үтик әле.

– Оркестр оештыру идеясе иң беренче булып Александр Сергеевич Ключаревта туа. Алга таба, әлеге идеяне тормышка ашырырга ансамбльнең күп җитәкчеләре омтылыш ясый. Шул исәптән, Җәүдәт Айдаров та. Ул Мәскәүдән махсус музыкантлар чакыртып китерә. Сигез кешедән думбырачылар октеты оеша. Алар ел-ел ярым гына эшлиләр дә таркалалар. Бу әле эзләнү чоры. Оркестрның формасы, составы нинди булырга тиеш икәнен ачыкларга тырышу. Аннары ансамбльнең оештыручысы Зөләйха Саттар кызы Әхмәтова белән Александр Сергеевич Ключарев Казанда 16 музыкантка штат бирдертүгә ирешәләр. Ул оркестрда мин дә уйнадым. СССРның 50 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә, Чайковский залында узган концертта чыгыш та ясадык әле без. Ул арада матди кыенлыклар килеп чыкты, Александр Ключарев авырды һәм берничә айдан оркестр таркалды да. Шулай да без чирканчык алырга өлгергән идек инде, оркестр төзү уе белән яна башладык. Без тагын өч баянга гына калган идек. Нәтиҗәдә безгә флейта, скрипичный контрабас килеп кушылды. 1965-66 елларда инде махсус партитуралар яза башладылар. Аларны А. Ключарев эшләде, Марс Макаров та катнаша иде. Хор өчен җырларның эшкәртмәләре ясала башлады. Инде 7-8 кеше булдык. 1972 елда А. Ключарев үлеп китте. Катлаулы чор бу, даими составыбыз юк, киләләр, китәләр... Аннары электрогитаралар модасы башланды. Без андый чорны да уздык. 1971-72 еллар иде ул. Ансамбль белән Геннадий Петрович Скалозубов идарә итә иде. Җитәкчелек югары белемле булырга тиеш дип, безне ашыгыч рәвештә Ленинградтагы Н. Крупская

исемендәге дәүләт мәдәният институтының Казандагы филиалына (аннары ул Казан дәүләт мәдәният институты булды) көндезге бүлеккә укырга җибәрделәр. Ансамбльдә 5-6 думбырачы гына калды. Без укып бетергәнче шулай барды. Геннадий Петрович белән 1977 елда укуыбызны тәмамлап, оркестр җыя башладык. Безнең өчен Пятницкий исемендәге хор һәм Моисеев ансамбле үрнәк иде. Мәскәүләргә карыйсың бит инде. Тик аларның мөмкинчелекләре дә зуррак, штатлары да күбрәк иде. Безнең инде Ходай биргән 16 кеше белән чикләнеп, үзебезчә эшлисебез килде. Думбыра белән балалайка янына скрипка да кирәк. Ул да татар халык уен коралы бит. Гобойны да бик яратабыз без. Мандолинаны да. Ансамбльгә сәнгать җитәкчесе булып Заһит Хәбибуллин да килеп эшләде. Ансамбль ул вакытта Татар дәүләт филармониясе каршында эшли иде. Миңа танылган фольклорчы, ул чакта филармониянең директоры Мәхмүт Нигъмәтҗановның да күп ярдәме тиде. Ул, фольклор экспедицияләренә чыгып, татар халык көйләрен язып алып кайта иде. «Ансамбльгә оркестр кирәк, әйдә тырышабыз!» – дип янып-көеп йөрде. Оркестр оешты. Баяннар өчәү калды, һәм хәзер дә шулай. Калганнары – флейта, кларнет, гобой, өч скрипка, өч думбыра, бәрмә уен кораллары, контрабас һ.б. Күп кенә музыкантларыбыз ике-өч инструментта уйныйлар. Мәсәлән, курайда, кубызда, сорнайда. Бу бик мөһим. Барысы да югары белемле. Барысы да консерватория тәмамлаган. Нинди генә катлаулылыктагы ноталар булмасын, утырабыз да уйныйбыз. Мин: «Без әсәрне бер-ике сәгать эчендә өйрәнеп сәхнәгә чыгып уйныйбыз», – дип мактанырга яратам. Башка халыкларның музыкасын уйнаганда, ул халыкка хас аерым уен коралларын да оркестрга кертәбез. Хәзер оркестрның, ансамбль репертуарыннан тыш, үз репертуары да бар. Россининың «Сорока-воровка» операсына увертюра, Н. Җиһановның «Кырлай» поэмасы, Татар халык көйләренә дүрт кисәктән торган сюиталар... Заманында аларны безнең баянчылар триосы өчен Ильяс Ислам улы Шәрипов эшләгән иде.

Заманында Казанда Олег Лундстрем оркестры бар иде. Аларның эшләгән оркестровкалары безнең өчен могҗиза иде инде. Алар Мәскәүгә китеп беткәч, «Татарстан радиосы» китапханәсендә партитуралары калды. Мин аларның партитураларын өйрәндем, һәм без С. Сәйдәшевнең

Җыр һәм бию ансамбленә эшкә килгән вакытлар. 1965 ел.

«Вальс»ын, А.Монасыйповның «Хыяллар»ын, С. Садыйкованың «Танго»сын, А. Ключаревның «Самба»сын һәм башка күп кенә әсәрләрне уйнадык, аннары барлык тәҗрибәне ансамбльдә кулландык. Хәтта Парижда узган күргәзмәләрдә фойеда татар джаз әсәрләрен рәхәтләндереп уйнап утыра идек! Мәскәүдә Үзәк музыка йортында (Центральный дом музыки) безне: «О, татарлар килде, димәк бүген күңелле була», – дип каршылыйлар иде. Югары дәрәҗәдәге башлыкларыбыз да, чит илләргә чыкканда, Республикабызны танытыр өчен, гел безне ияртәләр.

– Җыр һәм бию ансамбле булгач, сез, әсәрләрне эшкәрткәндә, җырчыларны да, биючеләрне дә күз алдында тотарга тиеш... Оркестр бит, гомумән, ансамбльнең умыртка баганасы кебек.

– Әйе, күп кеше белеп җиткерми, безнең темп бирү дә бик күп әйбердән тора. Хәтта сәхнәнең зурмы, кечкенәме булуыннан да. Әйтик, Мәскәүнең Чайковский залымы, әллә район мәдәният йортымы. Зал зур булса, темпны бераз төшерәбез, биючеләргә кыен

булмасын дип, әмма көйнең дәртен саклап калу зарур.

– Балетта, операда оркестр дирижеры сәхнәдә барган бөтен күренеш белән дирижерлык иткән кебек, сез дә – зур коллективның төп дирижеры.

– Әйе. Аннан соң, мин пенсиягә чыкканчы беренче баянда үзем утырдым. Миңа: «Рәшит абый, синең түбәтәең туйдырды инде», – дип шаяртталар иде. Анда бит кул болгап утырып булмый – баш болгыйсың. Ансамбльнең музыкаль төркеме, оркестры, ягъни Музыка берләштерә хорны да, биючеләрне дә, солистларны да. Иң беренче – музыка. Оркестр – берләштерә торган үзәк.

– Сез холкыгыз белән бик йомшак кешегә охшагансыз, ә башкарган вазифагыз таләпчәнлек сорый бит...

– Мине таләпчән генә түгел, «сверхталәпчән» диләр. Башкача булмый. Бер тапкыр күз йомып калсаң, икенчегә, өченчегә китә. Кеше белән эшләү бик авыр. Монда бит коллектив, син ишекнең йә бу, йә теге ягында...

– Бүгенге көндә, кызганыч, гармунда татарга хас милли, халыкчан итеп уйнау традициясе югала бара. Борынгыдан килгән алымнар билгеле бер дәрәҗәдә сезнең оркестрда саклана кебек. Шушы урында сүзне туган авылыгыз – Балтач районының Сосна авылына таба борасы килә. Мәктәп яшенә кадәр Соснада яшәгәнсез бит. Ә бу авыл үзенең атаклы «Сосна чабатасы» биюе белән дан тота. Җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры Раилә Мөхәммәтхан кызы Гарипова нәкъ менә сезнең авыл материалы нигезендә «Сосна чабатасы» биюен дә куйды бит әле. Соснада бүгенге көндә дә менә дигән гармунчылар, биючеләр бар. Сезнең гармунчы булып китүегездә дә, гомумән, тормышыгызны Җыр һәм бию ансамбле белән бәйләвегездә дә, мөгаен, туган авылыгызның йогынтысы бардыр әле.

– Әлбәттә шулай. Дөньяга күз ачыла башлаган малайлык елларым Соснада узды. Иң кызык чаклар. Һәр нәрсәгә ис китә, һәр әйбер ачыш бит ул чорда. Кызганыч, бабам Мостафа мин туганчы дөньядан китеп барган булган, миңа ул да бик күп нәрсә биргән булыр иде. Беренче Бөтендөнья сугышыннан пыяла кисә торган алмаз алып кайта бабай. Һәм тирә-якка «Пыялачы Мостафа» булып таныла. Ул алмазны күз карасы кебек саклыйлар инде. Аннары, бабайның авылда бик зур алма бакчасы була. Немецлар Беренче Бөтендөнья сугышында газ коралы куллана бит. Бабай сугыштан газ белән агуланып, саулыгын бик нык какшатып кайта. Һәм, үпкәсе череп, 48 яшендә дөньядан китеп тә бара. Боларны миңа әни сөйли иде инде.

Соснадан биш-алты чакырым арадагы өч-дүрт авылда туганнар чәчелеп яши. Яшь вакыт – бер авылдан икенчесенә тәпи-тәпи йөгерә идек. Исмәгыйль абыемның гармуны бар иде – ул чакта гармун бик сирәк кешедә. Минем авылда яшәгән чак әле бу. Абый да, Рәмзия апа да эшкә китә, мин рәхәтләнеп гармун уйнап утырам. Аннары әнием үземә дә гармун сатып алды. Шуннан китте инде. Авылда бит ел саен Сабантуй, Кичке уеннар... Менә шунда кызлар-егетләр җыела. Бездә «Гармун көрәштерү» дигән бәйге бар иде. Бер «Авыл көе»н җиде кеше уйный икән – җидесе җиде төрле уйный. Аннары җиңүчене сайлыйлар. Сайлауда шул ук гармунчылар да катнаша: «Менә Гарәфетдин, мәсәлән, болай уйнады. Синең кебек түгел, синең уйнау пүчтәк ул». Гарәфи абый берьюлы уйный да, бии дә, җырлый да иде.

«Гармун бәләкәй булса да, әйтә ул кирәкләрен...»

Балтач Сабан туе безнең Сосна авылының түбәноч болынында, Шушма буенда уза иде. Сабан туе – халык бәйрәме инде ул. Анда бөтен тирә-як авыллардан җыелып киләләр иде. Иң матур киемнәрне киеп, атларга кыңгыраулар тагып, гармуннарга яулыклар бәйләп юл буйлап килә алар. Менә шунда Гарәфи абый, авыл егетләрен ияртеп, уйнап-җырлап-биеп алдан бара. Мин Гарәфи абый кебек булдыра алмый идем, әмма гомер буе аның кебек уйнарга тырыштым. Уйнау техникасы да үзгәрде. Бишенче бармак та кереп китте – болай уйнарга рәсми рәвештә югары уку йортларында да өйрәтә башладылар.

Хәзер баянда, гармунда өйрәтү алымнары башкача бит инде. Мин, әйткәнемчә, ул алымнарны әнә шул Гарәфетдин абзый кебекләрдән алдым. Бик күп конкурсларга чакыралар иде, «Уйнагыз, гармуннар!» конкурсына комиссиягә дә, менә шулардан да бөртекләп җыелган. Минем вазифам – хәтердә ничек калган, башыннан азагына хәтле нотага салып бирү, штрихларына кадәр... Һәм шуның нигезендә башкару. Иң беренче үзем утырып биш-алты тапкыр уйныйм, аннары миңа калганнар иярә. «Рәшит абый, синең артыңнан уйнап булмый, син тагын икенче төрле уйнадың», – диләр алар миңа. «Мин «балыгын» гына уйнап күрсәтәм, калганын шуның нигезендә үзегез импровизировать итеп уйныйсыз», – дим. Элегрәк музыкантлар арасында: «А зачем нам это нужно? Зачем эти гармошки?» – диючеләр бар иде, хәзер андыйлар юк, сөенеп туя алмыйм. Фильтр аша үткәрдек.

– Сез, Гали Җәмлиханов кебек, кечкенә гармуннарда да уйныйсыз. Үзегезне аның укучысы дип саныйсызмы?

– Әлбәттә. Ничектер кечкенә гармуннар белән кызыксынып киттем. Саратов гармунында да, тальянда да уйнагач, әлләни авырлыгы юк иде – күрекләрен тартканда – бер, җыйганда икенче тавыш. Гали абыйга да, Заһит абыйга да мин аккомпанировать итә торган идем. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе булып эшләгәндә, Заһит Хәбибуллин бөтен концертта катнаша иде. Гали Җәмлиханов лекторий бүлегендә эшләде. Мине дә шунда алдылар. Әлфия Галимова, Гали Ильясов, Наҗия Теркулова, Айрат Арсланов, Азат Аббасов, Зифа Басыйровалар эшли иде әле бу

Солистка Миңнегөл Зәкиева белән Нигериядә илчелектә. 1978-1979 еллар.

вакытта. Башта үземнең гармуннарым юк иде, гастрольләрдә йөргәндә Гали Җәмлихановтан алып тора идем. Киттем скрипкага да, гармунга да мөкиббән Фәйзи Биккининнарга. Фәйзи абый ул чакта мәрхүм инде. Хатыны Сара апа янына 5-6 тапкыр барганмындыр – юк, сатмый Фәйзи абыйның гармуннарын! Аптырагач, Гали абый белән барып: «Сара, уйнамасалар гармуннар үләләр бит алар», – дип, ул үгетләде. Миндә ул чакта Урал мотоциклы бар иде, шуны сатып, Фәйзи абыйның 13 гармунын алып кайттым.

– Гармуннар коллекциягез шуннан башландымы инде?

– Шулайдыр. Анда 13 кечкенә гармун иде – 4, 5, 7, 10, 12 теллеләр, баянчик һәм инглиз концертиносы. Системасын белмәгәч, ул концертинода уйнавы читенрәк булды. Англия, Ирландиядә булганда уйнап җибәргән идем, исләре китте. Татарда аңарда миннән башка беркем дә уйнамый бугай хәзер. Миндә ике бонданьон, фисгармония дә бар. Гомумән алсак, 80нән артык гармун, төрлесеннән... Бүген мине бер генә сорау

борчый: миннән соң аларны кая куярлар икән? Нишләп бетәр ул коллекция миннән башка? Аяныч, беркем кирәксенми. Миңа моны әйтүе дә бик авыр. Өч-дүрт җирдә ул гармуннар хәзер: өйдә, гаражда, кызымның фатирында, күрше-күләннәрдә...

– Сезне генә түгел, бүген бу коллекциядән хәбәрдар бик күпләрне борчыган әлеге мәсьәләнең чишелешен якын киләчәктә күрергә насыйп булсын дигән теләктә калыйк...

Сез дирижер, музыкант-башкаручы гына түгел, композитор да бит әле – иҗат иткән байтак әсәрләрегез бар. Музыка яза башлавыгызга бию көйләренә кытлык сәбәп булдымы?

– Әйе, шулай. Балетмейстерлар – атаклы Фәйзи Гаскәров, Гай Таһиров, Мәскәүдән дә киләләр иде әле тагын, сиңа әйтә: «Ты мне сыграй что-нибудь такое... шушындый, шушындый булсын...» Шул моментта нәрсәдер табарга кирәк. Аңа хәзерге минутта кирәк – бетте-китте. Менә шулай музыкант композиторга әйләнә, һәрхәлдә, минем очракта шулай килеп чыкты. Минем өйдә «нәрсә языйм икән» дип уйланып утырганым булмады, үзеннән-үзе килеп чыга иде, каян килеп чыкканын белмисең дә син аның. Әмма мин үземне композитор дип әйтә алмыйм. Бу бик зур дәрәҗә. Хәзер кая карама – бар да композитор. Мин бию төркеменә, хор өчен музыка язам. Казанның меңъеллыгында «Идел тугында җыр» яңгырады – көен дә, сүзләрен дә үзем язган идем. Минем иң популяр әсәрем – «Казан кызлары биюе». Бу әсәр ансамбльнең визит карточкасы булып калды.

– Сезне башка җирләргә эшкә чакырулар күп булгандыр?

– Кая гына чакырмадылар: Валентин Левашов Пятницкий исемендәге хорга чакырды, Борис Кучугуров Казанга килеп өч көн: «Әйдә Оренбург хорына!» – дип үгетләде, Төньяк Осетиянең «Алан» ансамбленә чакырдылар. 1973 елда Рәсәй күләмендә оештырылган конкурста 81 баянчы арасында 3 нче урын алгач, Мәскәүнең «Березка» ансамбленнән Надежда Надеждина да чакырды. Мин барыбер Казаныма, халкыма, үземнең ансамблемә тугры калдым. Дөрес юлны сайлаганыма әле дә сөенеп яшим. Пенсиядә булсам да, һаман эшлим.

– Алма агачыннан ерак төшми, ди халык. Балаларыгыз да сәнгать юлында дип беләбез.

– Әйе, улым Искәндәр тавыш режиссеры; олы кызым Әдилә консерваториянең бишенче курсында укый, Татар дәүләт опера һәм балет театры оркестрында гобойда уйный, инде берничә конкурс лауреаты; кызым Ләйсән белән оныгым Сөмбел биючеләр; икенче кызым Айсылу Р. Яхин исемендәге 3 нче музыка мәктәбендә укый, флейтада уйный.

– Кыскасы, сәнгатьтә Мостафиннар династиясе дәвам итә.

Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамбленең Рәшит Мостафин җитәкчелегендәге оркестры.. 2008 ел.

Бу җәйдә Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең бер төркем яшь белгече Татарстан Республикасының Норлат һәм Чистай районнарында фольклор экспедициясендә булып кайтты.

Сөннәт йоласы

Башка халыклардагы шикелле үк, татарларда да бәби туугa бәйле йола һәм гадәтләр байтак. Гомумән, баланың дөньяга яралуы элек-электән зур бер сер буларак кузаллана. Кешелекнең бик борынгы заманнарында, бу сергә әле аңлатма табылмаганда, шуңа бәйләп бик күп ырымнар, йола-гадәтләр барлыкка килгән, һәм аларның шактые гаилә көнкүрешендә бүгенгәчә сакланып калган. Татарстан Республикасының Норлат һәм Чистай районнарында гомер итүче татарлар да бала туугa бәйле йола-гадәтләрне түкмичәчми бүгенгәчә саклап килә. Әлеге йолаларның нигезендә ана һәм баланың саулыгын, баланың киләчәк тормышын, уңышларын, бәхетле гаилә коруын кайгыртуга корылган кузаллаулар ята.

Дөньяга килүнең беренче кырык көнен, беренче атнасын барлык халыклар да үзенчә бер гадәт белән билгеләп үтә. Чөнки әлеге аралык бәбинең үзе өчен дә, аның әнкәсе өчен дә аеруча әһәмиятле чор санала. Нәкъ шушы көннәрдә баланы карау мәшәкатьле дә, мавыктыргыч та бер төс ала, аны яман күзләрдән-көчләрдән саклау өчен бөтен йолалар да җиренә җиткереп үткәрелә.

Татарлар да баланың беренче кырык көненә аерым бер әһәмият бирәләр. Кырык көн тулу – җанның кешегә иңүе һәм кешедән китүе белән тәңгәлләштерелә. Кешенең вафатыннан соң да кырык көн үтүне билгеләп үтү гадәткә кергән. Баланың тууына кырык көн булгач, сәдака бирү тиешле санала. Бала хөрмәтенә дип, гадәттә, өлкән хатын-кызларга, әбиләргә сәдака бирелә. Себер татарлары телендә «арыслан сәтәкәсе» дип аталган бу йоланың асылында балага саулык, бәхетле киләчәк юрау ята. Мондый балага арыслан да, кеше дә зарар китерә алмас, аңа хәтта пычак та

Мәчет. Норлат районының Кычытканлы авылы.

Кырык көн дәвамында бала тапкан әни кеше үзе дә, аның сабые да күз өстендәге кашка әйләнә, аларны һәрдаим кайгыртып, алар өчен борчылып торалар. Чөнки нәкъ менә шушы вакыт эчендә күз тиюләр дә, һәртөрле авырулар да якында гына йөри; бала тапкан хатын да, йөкле чагындагы кебек, әлегәчә «теге» һәм «бу» дөнья аралыгында яши дип санала. Күз тиюдән саклар өчен бу якларда яшәүче татарлар баланы алып кайтканчы ук кечкенә мендәр ясап куялар. Матурлап чигеп ясалган бу мендәр белән баланы имлиләр, күз тигән дип уйласалар, һәр почмагын серле сүзләр белән сабыйның эченә тидереп-тидереп алалар. «Минем үземнең кайнәм әни бик гыйлем иде. Шул менә кечкенә мендәр ясаган иде. Кечкенә мендәр ясап куй, бала елый торган була ди. Балага күз тисә, еласа, «Аятелкөрси» укып, мендәрнең дүрт почмагын да баланың корсагына тидереп, «Каян килдең, шунда кит, кемнең күзе тигән, шунда кит» дип әйтәсең. Изрәп йоклый иде бала шуннан соң. Мендәр ясаганда, кечкенә мендәр ясыйсың инде. Каз мамыгыннан. Бала үскәч, зур мендәргә өстисең аны» (Миңнегулова Люция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы).

Күз тия дип борчылганга, баланы кырыгына кадәр чит кеше күзенә күрсәтергә атлыгып тормыйлар, күрсәтмиләр дә. Яшь әнинең хәлен белергә килгән кеше, бәби яткан бүлемгә, бик теләсә дә, үрелеп карый алмый: «Кырыгына кадәр баланы чит кешегә күрсәтергә ярамый. Кырыгына хәтле тигән күз бетми диләр». Шуңа күрә ана белән баланы кырык көн үткәнче мөмкин кадәр чит-ятлар белән аралаштырмаска тырышалар, алар өчен аерым бүлмә дә әзерлиләр. Алда әйтеп үткәнчә, ул бүлмәне явыз көчләрдән саклау өчен, саклау магиясенең төрле формалары кулланыла.

Теге яки бу гаиләдә бәби туса, яшь ананың хәлен белергә, аны котларга килү, саулыгын кайгырту якын кешеләре өчен язылмаган бер бурыч булып тора. Хәл белергә берәү дә буш кул белән килми, һичшиксез, сыйнигъмәт белән килә. Чистай районында әлеге йола «Бәбәй туе», Норлат районында «Бәбәй ашы», дип атала һәм бүгенге яшәештә дә зур урын алып тора. «Бәбәй туе үткәрәбез диләр инде. Якын туганнары, туганнарның балалары киләләр. Менә шунда бәбәй бәлеше алып киләләр атап» (Миңнегулова Люция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы). «Исем кушканнан соң, әбиләрне чакырып Ясин укытканнар. Әбиләр киленнәр белән торган бит инде. Шул киленнәре атна саен җома көнне бәби бәлеше пешереп килә торган булганнар. Җома көнне генә. Чиратка сала торган булганнар. Алып килгән кеше белән чәй эчә торган булганнар. Карабодай ярмасын бүрттереп, киптереп, тарткычтан тарттырып, шуннан пешерә торган булганнар. Ит булса, ит тә куша торган булганнар» (Сабирова Гөлмиҗиһан Мирсәет кызы, 1930, Хисамова Алия Насыйх кызы, 1975, Кычытканлы авылы). Бүген, әлбәттә, кучтәнәчкә карабодай бәлеше килми, әмма камыр ашы әзерләү традициясе саклана. Бәби тапкан яшь әни кучтәнәчкә килгән бу ризыкларның һәммәсен дә авыз итеп карарга тиеш. Йоланың төп максаты – ырукардәшләр тарафыннан баланың кабул ителүе, үз кеше булып китүе.

Бәби туганнан соң үткәрелә торган йолалар арасында «Исем кушу» аерым бер игътибарга лаек. Исем үзе дә сакраль мәгънәгә ия. Ул үзенең «хуҗасын» саклый, аның җанына калкан булып тора кебек. Шуңа күрә татарларда яңа туган баланы озаклап исемсез тоту куркыныч санала, балага беренче көннәрдә үк, һәрхәлдә, кырыгы тулганчы, ничек тә исем кушарга омтылалар. Исеме булмагач, балага кеше күзе тияргә, явыз көчләр зыян ясарга мөмкин дип санала, бары тик колагына азан әйтеп исем кушкач кына Аллаһы Тәгалә аны саклый, яклый дигән ышану яшәп килә. «Җиде көнгә хәтле исем кушарга кирәк. Исемсез торырга ярамый. Кем табын төзи. Якыннарын чакыра. Дүрт бала таптым. Дүрт балага да өйдә куштырдым исем. Мулла килеп исем куша. «Исем кушу мәҗлесе» дип атала инде. Туганнарың килә мәҗлескә. Бүләкләр алып килә. Бәбәй бүләге дип, гаиләдә кемнәр бар – барысына да бүләк алып килә. Кызның әнисе тәмле иттереп бәбәй бәлеше пешереп алып килә иде. Йөзем салып, дөге, кабак белән бәбәй бәлеше. Иң беренче бәбәй тапкан әни кабырга тиеш. Бәбәйгә каптыралар, авызына тидерәләр. «Баллы булсын, татлы булсын, тәмле телле булсын» дип» (Миңнегулова Лю-

ция Харис кызы, 1953, Каргалы авылы). «Өч көннән ары тормасын диләр иде. Кайткач ук кычкырта идек. Менә күршенең каенатасы бар иде. Шуңа кычкырта идек. Аннан мәҗлес җыясың инде. Бәби бүләге, сәдака алып киләләр иде. Бәлеш тә пешереп кертәйем» (Халиуллина Нурҗиһан Шәймордан кызы, 1926, Бикүле авылы).

Бүген татарларда исем кушу йоласы, ислам динен тотучы башка төрки халыклардагы шикелле үк, бер үк канунга нигезләнеп

Бала мендәре. Чистай районының Татар Баганалысы авылы. Клуб музее.

башкарыла. Мендәрдә яткан сабыйны, башын кыйблага каратып, өстәл өстенә куялар. Мулла «Аллаһу әкбәр!» дип өч тапкыр азан әйтә, аннан, баланың башта уң, аннан сул колагына иелеп, әкрен генә аның исемен кабатлый. Бүгенге көндә Чистай районының кайбер авылларында исем кушу мәҗлесен мәчеттә үткәрә башлаганнар. Бу хәл безне бераз аптыраштa калдырды.

Татарларда ир баланы сабый чакта ук сөннәткә утырту йоласы бар. Сөннәт — гарәп теленнән кергән сүз, традиция, гадәт дигәнне аңлата. Ә менә баланы сөннәтләү, сөннәткә утырту беркадәр таррак мәгънәгә ия, ул малайларны мөселман гадәте буенча физик пакьләндерүдән гыйбарәт.

Сөннәтләү – һәр ир баланың тормышында шактый зур урын алып торган, аны шартлы рәвештә булса да чын ир-егет исемлегенә керткән мөһим бер вакыйга ул. Элек-электән халык арасында даны чыккан сөннәтче бабайлар булган. Кендек әби шикелле үк, ул да хөрмәткә һәм ихтирамга лаек заттан саналган, аңа бүләк-күчтәнәчләр китергәннәр, илтифат күрсәткәннәр. Чөнки аның бик җаваплы һәм саваплы, шул ук вакытта бик катлаулы эш башкарганын яхшы аңлаганнар: сөннәтче бабай кулында – баланың сәламәтлеге, киләчәктә нәселне дәвам итүе. Сөннәтче бабайга 99 баладан артык сөннәтләргә ярамаган да әле, чөнки йөзенче баланың ирлек көче бетә дип исәпләгәннәр. Безнең көннәрдә дә ир баланы сөннәтләү үз әһәмиятен җуймаган. Борынгыдан килгән гадәт буенча, сөннәткә утырту балага 1, 3, 5, 7 яшь тулганда башкарыла, чөнки 2, 4, 6 һ.б. җөп яшь тулганда үтәлгән гамәл баланың үлеменә китерәчәк дип ышана халык. Хәзерге заманда әлеге эш сөннәтче бабайлар кулына түгел, ә тәҗрибәле табиблар кулына тапшырыла. Чистай районында бу йоланы кунаклар чакырып, сөннәт боткасы пешереп, зурлап бәйрәм итәләр. «Малаема да сөннәт боткасы үткәрдек. Оныгыма да үткәрдек. Чәй куябыз, чәй янына камыр ризыгы пешерәбез, ботка пешерәбез. Йә карабодай боткасы, йә дөге боткасы, йә тары боткасы. Кем ничек ярата. Туганнарны чакырабыз. Киленнең әти-әнисе килә, тирә-күрше килә. Бер адәм баласы да буш килми» (Закирова Саимә Лотфулла кызы, 1947, Кызыл Болгар авылы).

Бала тууга бәйле йола-гадәтләрне барлап чыккач, бер нәрсәгә инанасың: еллар, гасырлар дәвамында аларның байтагы онытылган, югалган, үзгәреш кичереп, башка төсмер алган. Әмма асылы шул ук калган. Һәр йола сабый баланың «яңадан тууына», җәмгыятьтә үз урынын алуга, анда әдәп-әхлак кагыйдәләре тәрбияләүгә хезмәт итә. Заман белән бергә йолалар онытылып бара дисәк тә, шунысы сөенечле: сабыйның беренче көннәреннән үк аңа үзгә бер игътибар күрсәтү, туган-тумачаның моны уртак бәйрәм буларак кабул итүе, үзара ярдәмләшеп, кунакларга йөрешеп аралашуы, өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәт татар халкы өчен бүген дә җуелмас рухи кыйммәтләрнең берсе булып кала.

Ләйлә Хәсән кызы ДӘҮЛӘТШИНА,
филология фәннәре кандидаты,
Республика традицион мәдәниятне үстерү
үзегенең бүлек мөдире

«Кыштыр-кыштыр», «Чыштык»...

Чистай районы авылларыннан без бу якларда гаять бай җыр, бию традицияләре булганлыгына сокланып; шул ук вакытта аларның элеккеге күңелле, матур елларның бер кайтавазы рәвешендә өлкән буын кешеләренең күңелләрендә генә сакланып, тормыштан китә баруларына күенеп тә кайттык. Шунысы мөһим: әлеге төбәктә безгә халыкта сакланган байтак музыка үрнәкләрен, җыр-биюләрне язып, аудио һәм видеоформатта теркәргә мөмкин булды.

Заманында атаклы мәчетләре, мәдрәсәләре белән дан тоткан, татар дөньясына бик күп зыялы шәхесләр үстереп биргән як бу. Информантлар безгә хәтта көчләп чукындырылган авыллардагы халыкның да ислам дине тотудан туктамавын, берәр йортта качып җыелып, хәтта базга төшеп, намаз укыганнарын сөйләделәр. Совет чорында да үз диненнән бизмәгән халык. «Бабайларга мәчеткә йөрергә ярамый иде. Бер өйгә җыелалар иде ураза вакытында. Без, балалар, Тәравих әйткәннәрен качып тыңлап тора идек. Әбиләр дә, кичен чыгып утыргач, дин турында сөйләшәләр иде. Гайбәт сөйләмиләр иде», – дип искә алды Татар Баганалысы авылында яшәүче Шәрифуллина Рузалия Фаил кызы. Элекке әбиләр гарәп язуында «Мөхәммәдия», «Бәдәвам», «Йосыф кыйссасы» кебек китапларны көйләп укыган. Иске Роман авылында халыкка дин сабакларын өйрәтүче «ак әбиләр» булган. «Сак-сок» бәетен, мөнәҗәтләрне дә яратып башкарганнар. Шунысы куанычлы, татар халкының китапларны көйләп уку кебек үзенчәлекле матур традициясе бүгенге көндә дә яши һәм әле яшьләргә дә тапшырыла бара. Моңа дәлил итеп Татар Сарсазы авылында өлкәннәрдән өйрәнеп мөнәҗәт әйтүче Хәснетдинова Гөлшатны китерергә була. Дәү әниләр әле дә нарасый сабыйларны «Аллаһу, Аллаһу» дип бишек җырларын көйләп йоклата.

Мәҗлесләргә килгәндә, элек кыска көйләр белән беррәттән озын көйләрне дә яратып җырлаганнар. Һәр авылда да тирән моң белән «Кара урман», «Рамай», «Гөлҗамал»ларны башкаручы талантлы апа-абыйлар булган. Кызганыч, хәзер андый борынгы көйләр инде әкрен генә тарихка китә бара. Шулай да, Уракчы авылында сигезенче дистәсен ваклаган Закирова Әлфия Гыймран кызы (1942 елгы) безне «Гөлҗамал», «Шахта» җырларын башкарып таң калдырды.

Элеккеге туйларда кода-кодагыйларга багышлап җырлаганнар, кара-каршы такмак әйткәннәр. Хәер, кара-каршы җырлардан башка чистайлыларның бер мәҗлесе дә узмаган. Кызыл Болгар авылында көз көне күп йортларда тутырма пешереп мәҗлес җыйганнар. Шунда бер пар һәрвакыт «Алдыйсың – алдама» дигән шаян җыр белән халыкның кәефен күтәргән.

Кук-күгәрчен, күгәрчен,
Җиргә төшә җим өчен.
Алдыйсың – алдамыйм, валлаһи,
Җиргә төшә җим өчен.
Таһир үлгән Зөһрә өчен,
Мин үләм сезнең өчен.

Ә кичләрен яшьләр «Кызлар яны» җыйганнар. Кызлар бәлеш пешереп көткән, егетләр гармун белән җырлап килеп кергән. Монда «Татумы-сатумы», «Агыш», «Йөзек салыш», «Каеш сугу», «Станок», «Гөлбану», «Әйләнеш» кебек җырлы-биюле уеннар уйнаганнар, такмак әйтешкәннәр. Татар Баганалысы авылында такмакны асылына туры китереп «төртмеш» дип атаганнар.

Инде биюләргә килгәндә, бу якларда элеккеге заман апа-әбиләре «шуытып» биегәннәр. Аны төрле авылларда төрлечә әйтәләр – «Шома бию», «Кыштыр-кыштыр», «Чыштык», «Ышкытып»... Ләкин асылда сүз бер төрле бию турында бара. Аны бары тик хатын-кызлар биегән. Алар аякларын иплән кенә, югары күтәрмичә, шома итеп вак-вак атлап барганнар. «Шома бию»не күп очракта ялгыз биегәннәр. Уракчы авылындагы Закирова Әлфия (1942 елда туган) истәлекләреннән: «Әни дә, әбиләр дә, әтинең сеңелләре дә гел шулай «чыш-чыш-чыш итеп» бииләр иде. Кулларын билләренә куеп, әкрен генә әйләнеп».

Аңлавыбызча, «Шома бию» XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына хас булган. Ә менә

кырыгынчы-алтмышынчы елларда туганнар яшьлектә «Чүгеп» биегәннәр. Шунысы кызык, әлеге элемент ирләр биюенә хас булса да, хатын-кызлар да чүгеп биегән. Кем белә, бәлки бу күренеш сугыш чоры белән бәйле рәвештә, ягъни ир-атлар юклыктан, алар урынына кара-каршы биюдә хатын-кызлар басарга мәҗбүр булганнан килеп чыккандыр?

Татар Баганалысы авылында яшәүче Әнәс Гыйләҗев сөйләгәннәрдән: «Безнең авылда кич белән алтышар җирдә гармун уйный иделәр. Дөньяның ул вакыттагы матурлыгы – аны беркем дә аңлатып бетерә алмас. Музыкант иде халык. Туйларда дүртәр сәгать халыкны биетеп гармун уйный идек. Иң почет кеше егетләрдән гармунчы иде. Каршы чыгып биюләр була иде кичке уеннарда. «Чыштык»ка да биеде апалар – аякның үкчәсе белән тыпырдатып бию. «Барыня»га да биеделәр». Әнәс абый безгә үзенчәлекле бию көйләрен дә башкарды. Аларның берсе «Хуҗа көе», икенчесе «Бочка». Бу биюләрне карап тору гына да үзе бер мавыктыргыч манзара булган: «Гармунчы биючене беренче аккордлар биреп үртәп тора иде, биюче аяк белән тыпырдатып чыгып баса. Мишәр малайлары аңа чүгеп биергә бигрәк тә ярата иделәр. Тыпырдап киләләр дә, чалып-чалып аякны, китереп чүгәләр. Шундый матур килеп чыга иде. Әле клубларда укучылар да билләренә кызыл тасма бәйләп бии иделәр. Шушы бию әкрен генә бетте». «Бочка»га кызлар белән егетләр бер-берсенә кара-каршы да чүгеп биегән икән.

Нарат Елга авылы халкы да чүгеп биергә шул кадәр яраткан, хәтта бәби табар вакыты җиткән хатыннар да кичен дәртле көйләргә чүгеп-чүгеп биеп, икенче көнне тупырдап торган балалар тапканнар! Ә гармун булмаса, кубызда уйнап биегәннәр, һичъюгында үзләренә-үзләре такмаклап торганнар. Иң мөһиме, күңелендә дәртең булсын, чөнки җыр-биюләрсез Чистай халкы яши алмаган.

Каргалы авылында яшәүче Дәүләтшин Шәүкәт Габидулла улы да төрле төр гармуннарда үз авылларында һәм тирә-якта башкарылган уникаль дәртле бию көйләрен уйнады, аңа кушылып Каргалы апалары үз биюләрен күрсәтте. Шәүкәт абый башкарган тагын бер үзенчәлекле көй – «Каргалы көе». Монда шушы як кешеләренең бар рухы, матурлыгы, шат күңеле чагылган кебек.

Татар Сарсазы авылында Мусин Салих Сәйдәш улы белән аралашу да гармунчы күңеленең иң нечкә кылларын аңларга ярдәм итте. Ә инде сәнгати күңелле музыкант кешенең авыл җирлеге башлыгы булуы сарсазылылар өчен аерата отышлы хәл.

Чистай районының Бахта авылы.

Иске Роман авылының «Мәйсәрә» ансамбле җитәкчесе Мифтахова Тәнзилә Мингатовна да егетләрдән кимен куймады. Баянын күтәреп, берьюлы уйнап-биеп тә күрсәтте!

Бахта авылы турында да күңелдә үзенә бер матур хатирәләр уелып калды. Бүгенге көндә дә гөрләп яшәгән, тырыш, эшчән халык гомер иткән бу авылда үзләренең борынгы гореф-гадәтләрен, җыр-биюләрен саклап яшиләр. Агеева Мария Петровна башкарган «Безнең балакаем сездә лә кала...» кебек туй җырлары, никрут җырлары, Ванифатьева Нионила күрсәткән бию үрнәкләре безнең өчен бер ачыш булды.

Гөлназ Гыйльфан кызы ГЫЙЛЕМҖАНОВА,
Үзәкнең фәнни хезмәткәре

«Гармун алыйк әле, дускай...»

Халык уен кораллары арасында күңелебезгә иң якыны гармун, дисәк, барыбыз да килешер, мөгаен. Заман үзенекен таләп итсә дә, бу уен коралының урыны һәрчак түрдә.

Норлат һәм Чистай районнары авылларында җәйге экспедициядә йөргәндә, мине халык музыка уен коралларының бу төбәктә бүгенге көнгә сакланыш дәрәҗәсе, популярлыгы, ягъни бу уен коралларына хәзерге мөнәсәбәт кызыксындырды.

Авыллардан тыш, безгә Норлат шәһәренең Кама аръягы тарихы төбәк музее белән танышырга насыйп булды. Бу музей кызыклы экспонатларга гаҗәп дәрәҗәдә бай булып чыкты. Миңа аеруча татар гармуннарына багышланган күргәзмә ошады. Ул Норлат шәһәренең танылган гармунчысы Зәйнуллин Сәид Гобәйдулла улына багышланган. Күргәзмәдә гармуннарның ниндие генә юк: өч телледән алып сигез теллегә кадәр кечкенә концерт гармуннары; гармуннарның барысы да уйнарга яраклы хәлдә.

Шулай ук бу музейда татарларга гына хас ике рәтле квадрат төймәле ак гармунга тап булдым, ул гармун үз чорында Норлат нефтьгаз табу идарәсенең җитәкчесе булып эшләгән Хуҗин Марат Мөхлис улыныкы булган. Бу уен коралы атаклы оста А.С.Голованов тарафыннан ясалган. (Казанда әлеге останың фатирына баргач, кызы: «Әтиемнән менә нинди кешеләр гармун ясатып алган!» – дип, нәкъ менә Хуҗин Марат Мөхлис улының визит карточкасын күрсәткән иде.) Норлат районы Самара өлкәсенә якын булгач, данлыклы оста Гали Гәрәев ясаган гармунга да тап булдым. 1960 елда ясалган гармунның тавышы үзгәрмәгән, саф килеш сакланган.

Норлат районының Курмыш авылында яшәүче, гомере буе тарих фәне укыткан Алишев Ирек Исхак улы (93 яшь) венский, тальян, ике рәтле гармуннарында уйнап сокландырды.

Бурметьево авылында яшәүче Миңнекәева Саимә Сәмигулла кызы (1941 елда туган) яшьлекләрендә, гармун булмаган чакта, авыз белән уйнап биюләрен искә төшерле:

Дыел-дыел-дыел-ди-та-ти-на-на,
Дыел-дыел-дыел-ди-та-ти-на-на.
Аттылдитә, аттылдитә, аттылдитә-ти-на-на,
Аттылдитә, аттылдитә, аттылдитә-ти-на-на.

Авыл гармунчысы, һөнәре буенча тракторист Гомәров Гариф Сафиулла улы (1941 елда туган) безгә тальянда бу авылга гына хас кызлар биюләре көйләрен («Чыштык», «Парлы», «Культур») уйнап күрсәтте.

Күлбай-Мораса авылында гомере буе сыер савучы булып эшләгән Баһаветдинова Суфия Нургали кызы (1933 елда туган) белән аралашканда, бу җор телле апаның табигатьтән килгән сәләтләренә сокланып туя алмадык. Суфия апа камыштан тукымалар тукый, кул белән чигә, им-том итә, кубызда оста уйный һәм теттереп бии... Кубызда уйнау нәселдән килә икән: әбисе дә, әнисе дә уйнаган.

Урта Чаллы авылында Галимова Зәйнәп Хөҗәт кызы (1925 елда туган) авыз белән «гармун уйнап» күрсәтте:

Килә-килә-килә-гөр-гөр,
Килә-килә-килә-гөр-гөр,
Килә-килә-килә-гөр-гөр,
Килә-килә-килә-гөр-гөр,
Ком-ба-гөр-гөр-ком-ба-ком-ба,

Ком-ба-гөр-гөр-ком-ба-ком-ба,
Ком-ба-гөр-гөр-ком-ба-ком-ба,
Ком-ба-гөр-гөр-ком-ба-ком-ба.

Шул авылның мулласы Миңгалиев Минсәгыйт Галимҗан улы (1940 елда туган) гармунда бик оста уйный икән. Тальянын ул бүгенге гармун ясау остасы Айрат Харисовтан эшләтеп алган. «Биеткәндә көйне кешесенә карап уйный идем, бию рәвешенә, холкына карап», – ди Минсәгыйт ага. Минем гармунчы икәнлегемне белгәч, берничә көй уйнатып алды. Аннары минем гармунда үзе дә уйнап карады да: «Менә бу гармун минем кулыма ята, элекке мастерлар кулы белән ясалган җиз телле чын гармун бу синең», – диде.

Менә шушы Минсәгыйт бабай, Саимә, Суфия, Зәйнәп әбиләр кебек энҗе бөртекләрен халык арасыннан күбрәк эзләп табып, видеотасмаларга теркәп куясы иде – буыннан-буынга тапшырып калдырасы рухи мирасыбыз никадәр баер иде!

Чистай районы авылларында йөргәндә дә матур табышларга юлыктык. Каргалы авылында яшәүче Дәүләтшин Шәүкәт Габидулла улы (1957 елда туган) гармуннарның бар төрләрендә дә уйнап күрсәтте (венский, вараксин, ике рәтле гармун, тальян, баян).

Нарат Елга авылында «халык гармуннарны махсус Сарман районына барып эшләткән», дип әйтүчеләр булды.

Бахта авылында Азеев Гавриил Григорьевич (1941 елда туган) белән очраштык. Ул һәр гармунының тарихын шулкадәр җылы итеп, аерым бер кыйссага әйләндереп сөйләде, үзенә генә хас техника белән халкыбызның бик күп көйләрен уйнады.

Кыскасы, халкыбыз арасында гармунга түрдән урын биреп, әлеге уен коралын үзенең алыштыргысыз гомер юлдашы иткән кешеләр байтак әле. Яшьләр арасында да гармунга булган игътибар торган саен арта бара. Соңгы елларда даими уздырылып килүче Фәйзулла Туишев исемендәге республика гармунчылар бәйгесендә яшьләрнең елдан-ел күбрәк катнашуы да шушының ачык дәлиле. Бүгенге көндә, шөкер, гармун, баян катнашында узган концертларның, бәйрәм-мәҗлесләрнең дәрәҗәсе арта бара. Бәс, шулай икән, галиҗәнаб Гармун ышанычлы адымнар белән киләчәккә атлый дия алабыз.

Дамир Алмаз улы ГАБДРАХМАНОВ,
Үзәкнең фәнни хезмәткәре

Миңнекәева Саимә Сәмигулла кызы

Алишев Ирек Исхак улы

Баһаветдинова Суфия Нургали кызы

Миңгалиев Минсәгыйт Галимҗан улы

Гафур СӨНГАТОВ

Авыр басканчы, җиңел калкыр

Татар телендә әйберләр авырлыгын белдерүче үлчәм берәмлекләренең кулланылышы

Халыкның тормыш итү рәвеше, яшәү шартлары үзгәрә барган саен, гасырлар буена телебездә кулланылып килгән лексик берәмлекләр дә җуела бара. Шуңа күрә халыкның көндәлек тормыш итү рәвешенә бәйле атамаларны теркәп калдыру төбәкне комплекслы өйрәнү юлында гаять актуаль. Тормыш-көнкүреш лексикасын, һөнәрчелек терминнарын, терлекчелек, игенчелек, урманчылык тармакларына караган сүзләрне тикшерү төбәкнең социаль-икътисадый үзенчәлекләрен ачыкларга, традицион һәм яңа күренешләрне билгеләргә мөмкинлек бирә.

Әле бернинди махсус җиһазлар булмаган заманда да адәм баласына һәрдаим үлчәргә тиешле әйберләр һәм күренешләр белән очрашырга туры килгән. Һаваның һәм суның җылылык-суыклык дәрәҗәсен, ара ераклыгын, нәрсәнеңдер күләмен, авырлыгын мөмкин кадәр төгәлрәк билгеләү кешегә көндәлек эшчәнлеген нәтиҗәлерәк, сыйфатлырак оештырырга ярдәм иткән. Кырларны иңләп-буйлап үлчәгән игенче дә, малын, кош-кортын үстерүгә-карайтүгә бөтен көчен куйган терлекче дә, коралының зурлыгы, ныклыгына бәйле сугышчы да – һәммәсе үзләренә кирәкле үлчәү-исәпләү алымнарын, чараларын кулланганнар.

Кеше элек-электән төрле әйберләрне үлчәү-хисаплау өчен көндәлек тормышта кулланган сүзләр төркеме, иҗтимагый мөнәсәбәтләр катлаулана һәм фән-техника үсеше кызуланган саен, яңа берәмлекләр һәм атамалар белән баеп барган. Хәзерге көндә үлчәү, хисаплау, төгәл сан мәгълүматы алу өлкәсендә кулланыла торган барлык күрсәткечләр, берәмлекләр һәм сүзләр системасын һәм шуларны өйрәнүче фәнне метрология дип йөртәләр.

Метрология – үлчәү һәм фикер, өйрәнү дигән мәгънәләрне белдерүче грек сүзеннән

Халыкта «карамысла» дип атала торган, җиңелрәк әйберләрне үлчи торган ике тәлинкәле үлчәү (Норлат шәһәрендәге Чулман аръягы региональ музее)

оешкан атама. Әлеге фән хәзерге вакытта үзенең тикшерү өлкәләре һәм бурычлары белән аерылып торган берничә тармакны берләштерә. Бер яктан ул – эталон булып хезмәт итәрлек үлчәм берәмлекләрен һәм аларның атмаларын булдыручы, фәнни һәм гамәли максатларга ирешерлек методика тудыручы фән. Үлчәү, санау-исәпләү юнәлешендә башкарыла торган төрле фәнни һәм гамәли эшләрне, ягъни метрологияне, берничә төргә аералар: теоретик метрология, тарихи метрология (башлыча акча төрләрен, атамаларын тикшерә), кануный метрология (бу өлкәдәге кагыйдәләрне, нормаларны, дәүләт тарафыннан куелырга тиешле таләпләрне тикшерә һәм булдыра), гамәли метрология (үлчәү алымнарының һәм чараларының тормышның төрле тармакларында кулланылышын өйрәнә). Икенче яктан, метрология төрле үлчәм берәмлекләрен тарихи үсештә тикшерүче, аларның атамаларының килеп чыгышын, бер-берсе белән мөнәсәбәтен ачык-

лаучы фән. Шушы өлкәләрдә кулланыла торган, әйләнешкә кертелгән лексиканы барлау, анализлау юнәлешендә соңгы елларда лингвистик метрология дигән төшенчә дә кулланыла башлады.

Әйберләрнең күләмен һәм зурлыгын, азлыгын-күплеген, авырлыгын белдерүче тел берәмлекләре татар теленең сүзлек составындагы иң борынгы лексик-семантик төркемнәргә карый. Элекке үлчәм берәмлекләренең күбесе телнең төрле тармакларында хәзер дә актив кулланылалар. Бу мәкаләдә без шул халык метрологиясе турында сөйләрбез.

Билгеле булганча, халык авыз иҗаты әсәрләрендә кешеләрнең бик борынгы чорлардан алып яшәү, тормыш итү рәвеше чагылыш таба. Шунлыктан фольклор текстларында борынгыдан килгән үлчәм берәмлекләренең еш кулланылуы бик табигый. Матур әдәбият әсәрләрендә һәм төрле стильләр чагылыш тапкан матбугат телендә, лексиканың башка тармаклары кебек үк, метрологик лексика да яңа сүзләр белән байый, алынмалар хисабына тулылана бара.

Авырлык – предметның физик сыйфаты, ул әйбернең үлчәүгә салып билгеләнә торган үзлеге [2, Т.1, б.12]. Бу урында кешелек җәмгыятендә әйберләрнең авырлыгын конкрет күрсәтә торган үлчәү барлыкка килгәнче үк, аны чамалап (күтәреп карап) яки башка әйбер авырлыгы белән чагыштырып билгеләгәннәрен дә искәртергә кирәк. Теге яки бу әйбернең, төрле җисемнәрнең авырлыгын белдерүче сүзләр метрологик лексиканың төп тематик төркемнәреннән берсе булып торалар. Предметларның үзлегеннән чыгып аларны берничә яссылыкта карарга мөмкин:

1) каты, чагыштырмача эре һәм данәләп санала торган предметларны белдерүче үлчәм берәмлекләре;

2) сыек җисемнәрне белдерүче сүзләр;

3) сибелмәле, вак һәм бөртекле бертөрле предметларның авырлыгын белдерү өчен кулланыла торган лексика.

Мәгълүм ки, халкыбызның тормыш-көнкүрешенә, этнографиясенә караган, милли һәм төбәк үзенчәлекләрен чагылдырган күп кенә сүзләр, шул исәптән үлчәү-исәпләүне белдергәннәре дә, кулланылыштан төшеп кала бара. Әйтик, җирне аршынлап та, «күз күреме кадәр» дип тә үлчәгәннәр, имана белән санаганнар; май күләме йомарлам белән, чәй күләме әчмуха белән исәпләнгән; әйбернең авырлыгын кадаклап һәм потлап үлчәгәннәр һ.б. Бу сүзләрне без хәзер бик сирәк кенә өлкәннәр авызыннан ишетә алабыз, фольклор телендә күрәбез яки әдәби әсәр укыганда гына аларга юлыгабыз.

Әйберләрнең күләмен, санын һәм авырлыгын белдерүче тел берәмлекләре иң борынгы лексик-семантик төркемнәргә карый. Мондый сүзләр, халыкның көндәлек тормышы белән турыдан туры бәйләнешле булганга, телнең актив кулланылыштагы лексикасына керәләр, ягъни барлык тармакларда да һәрдаим кулланылалар. Мәсәлән, мәкальләрдә авыр, җиңел сүзләре дә, үлчәм берәмлекләре дә очрый: авыр таш, кузгатсаң, җиңеләя; Идел суы илле батман. Батман – башлыча сибелүчән-чәчелүчән әйберләр өчен күләм яки авырлык үлчәме – ун-унике кадак, дүрт пот, ун пот [2, Т.1, б.133], ягъни бу сүз төрле җирдә төрле авырлыкны яки күләмне белдерә ала.

Татар халкы борынгыдан ук туганнар, күршеләр белән дус-тату яшәүне иң изге, күркәм эшләрнең берсе итеп санаган, алар белән аралашу әдәбенә зур игътибар биргән. Күршеләрдән савыт-саба, эш кораллары яисә бурычка акча, азык-төлек алып тору да гадәти хәл саналган. Үлчәү авылда аерым кешеләрдә генә булган, шунлыктан сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы авыр елларда бурычка биреп торган ипине һәм башка азык-төлекне уклау, табагач яки махсус таяк белән үлчәгәннәр. Уклауны бер башыннан тотып, икенче башына ризык эленгән һәм авырлык тигезләшкән урынга кирт ясалган. Бу күренеш Тау ягы авылларында да, Чулман аръягында да киң таралган булган. Бу хакта, мәсәлән, Апас районы Борнаш авылында 1929 елда туган Сөләйманов Хәкимҗан Галимҗан улы, Нурлат районы Киекле авылыннан 1942 елгы Мөхетдинова Мөнәвәрә Мирзаян кызы һ.б. өлкәннәр сөйләде. Апас районы Әҗем авылыннан 1938 елгы Бикчәнтәев Хәлим Габдрахман улы болай дип искә ала: «Көянтәне уртасыннан тота да, ипине бер башына элә, ит, бәрәңге... Бер ягына гер асасың. Табагач белән дә эшлиләр иде. Табагач башына тот-

кан җиргә киртек ясап куя». Ике тәлинкәле, бер ягына герләр куела торган үлчәү күп төбәкләрдә «карамысла» дип аталган, су китерә торган көянтә (күәнтә, күәндә) исә үз исеме белән калган. Бу әйберләр үлчәү өчен элегрәк көянтәнең үзен файдаланудан күчкән булырга тиеш. Өлкәннәр сөйләвенчә, әйберләрне көянтә белән дә үлчәгәннәр, туры агачтан ике башына ыргак куеп махсус үлчәү дә ясаганнар. «Үлчәү» сүзеннән тыш, күп авылларда бизмән, кантыр исемнәре киң кулланылышта булган. «Герәмәңкә» сүзе үлчәү исеме буларак Апас районының Шыгай вылында искә алынды. 1926 елгы Камалиева Хәмсәнә Низами кызы сөйли: «Ул менә башына тимер белә ыргак ясап куя иде эти безнең. Сызымнары барые инде аның. Теләсә нинди агачтан була герәмәңкә».

Соңгы елларда үткәрелгән экспедиция материалларына караганда, татар авылларында пот, кадак, әчмуха кебек авырлык үлчәме берәмлекләре актив файдаланылган. Мәсәлән: «Дүрт йөз грамм инде – бер кадак. Ярты кадак ике йөз грамм була. Хәзер кечкенә чәйләр бар бит, 50 граммлы. Менә бер әчмуха шуның хәтле була» (Бикчәнтәев Хәлим Габдрахман улы, Апас районы, Әҗем авылы). «Әчмуха» – сөйләм теле сүзе, кадакның сигездән бер өлеше, 50 граммга тигез [2, Т.3, б.689]. Кадак берәмлеге «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә сөйләм теленә хас сүз дип күрсәтелгән, ул – 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге [2, Т.2, б.16]. Галимнәр «кадак» атамасын бизмәннең үлчәү таягына кагылган кечкенә кадакларны күзаллап әйткәннән килеп чыккан дип саныйлар [1, Т.1, б.336]. Пот – русча пуд сүзеннән; метрик система кертелгәнчегә кадәр кулланылган һәм 16,3 килограммга бәрабәр булган иске авырлык үлчәү берәмлеге [2, Т.2, б.34].

Халык авыз иҗаты әсәрләрендә халыкның акылы, дөньяга карашы, өмет-хыяллары, бик борынгы чорлардан килгән ышанулары, гореф-гадәтләре, гомумән, яшәү, тормыш итү рәвеше чагылыш таба. Әйтик, әкиятләрдә һәм мәзәкләрдә терлек асрау, иген игү, сәүдә итү, һөнәрчелек һ.б. хезмәт төрләре киң яктыртыла, шунлыктан аларда элекке үлчәм берәмлекләренең дә күпләп кулланылуы бик табигый. Фольклорның чәчмә әсәрләре телен анализлау күрсәткәнчә, аларда иң еш кулланылучы авырлык үлчәме берәмлеге – пот сүзе. Әкиятләрдән берничә мисал китерик: .... абзарда симез үгезең бар, суйсаң биш «пот» май чыгар, аңардан симез нәрсә булсын, – ди [«Өч килен»]; шуннан соң Гыйфрит йөз потлы гөрзиен алды да, егеткә берне китереп бирде, ди [«Өч дус»]; шуннан соң, дию пәрие алтмыш потлы гөрзиен алып егетнең баш түбәсенә берне биргән иде, ди, егет муеныннан җиргә батты, ди [«Өч дус»]; миңа унбиш потлы гер ташы койдырып китерт, ди [«Алтын алма»] һ.б. Татар теленә пот берәмлеге белән бергә «подаука» сүзе дә кергән, ул ашлык, он сала торган зур чиләкне аңлата. Мәсәлән: бай аңа бер подаука он биреп җибәргән, ди» («Хезмәтче Хритон»). Мәзәкләрдә: ...бу малае 10 пот урынына 12 пот сала [«Урлашудан биздергән»]; иң әйбәтен генә сайлап ун пот бодай орлыгын кышка дип чокырга күмеп куйган идем [«Зур аерма юк»]; менә сиңа фәлән пот икмәк... [«Фатиха»]; бер пот он алып кайткан [«Ходай үзеңә бирми шул»]; мин бер куян аттым, бер пот мае булыр [«Күпер эрегән»] һ.б.

Циферблатлы түгәрәк үлчәү.
(Норлат шәһәрендәге Чулман арьягы региональ музее)

Мәзәкләрдә «кадак» үлчәм атамасы «пот» берәмлегенә каршы куелып та, үзе генә дә кулланылырга мөмкин. Мисаллар: ярты пот

булмаса да, ун кадагы бик бар иде [«Күпер эрегән»]; поты түгел, кадагы да юк бит [«Ичмасам сөйләшеп калыйк»]; Хуҗа базардан өч кадак ит алып кайткан да хатынына бәлеш пешерергә кушкан; мәченең авырлыгы нәкъ өч кадак булган [«Өч кадаклы мәче»] һ.б. Гыйбрәтле әкиятләр төркеменә керүче «Алтынбай» исемле әсәрдә татар телендә совет чорында кулланылышка кергән, йөз килограмм авырлыкны белдерүче центнер сүзе урын алган: өч сарайдан өч центнер алтын алып, бу өч ел буе сатуда йөри.

Предметның авырлыгы аны күтәрергә күпме көч китүе белән билгеләнергә мөмкин. Мәсәлән: бер дә бер көнне, балыкка баргач, кармагын салган иде, моның кармагына эләкте, ди, бик авыр бер нәрсә. Шундый авыр, аран өстерәп чыгарды кырыйга [«Балыкчы белән Гыйфрит»]. Биредә аран – көчкә генә мәгънәсендәге диалекталь сүз. «Балыкчы карт» әкиятендә дә шундый мисал бар: Бабай ауны тартып чыгарыйм дисә, чыгара алмый: авы бик авыр һ.б.

Авырлык үлчәм берәмлекләренең матур әдәбият телендә кулланылышына күз салыйк. 19 гасыр ахыры – 20 гасыр башында татарларда киң таралган сүзләр хәзерге татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе, татарның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, бәйрәм-мәҗлесләрен тормышчан һәм тулы тасвирлаган олуг әдибебез Гаяз Исхакый әсәрләрендә чагылыш тапкан. Әдипнең «Кияү» хикәясендә түбәндәге мисаллар бар: как-төшкә биш кадактан артык май китмәс; ярты пот, утыз кадак булса, йитеп торыр; потлы капчык ак он, ун кадак кына дөге, йимеш һ.б.

20 гасырның икенче яртысына караган әсәрләрдә дә, хәзерге әдәбиятта да үлчәм берәмлекләре киң кулланылыш табалар. Классик язучыбыз Ә. Еники иҗатыннан мисаллар: ...кыштан ук потлап шикәрен ташып куя [«Күсия ханым»]; онны әйткән дә юк, махсус сандык алып, шуны өч килолы каплар белән дыңгычлап тутыра [«Күсия ханым»];...өйгә дә бер өч кило балык алып кайттым [«Бөке»] һ.б.

Халыкчан җанлы телле әсәрләре киң катлау укучы тарафыннан яратып укыла торган күренекле әдибебез М. Мәһдиевнең «Кеше китә – җыры кала» повестеннан бер өзек китерик: «Шәйхиләрдән алачак ипи: өч кадак, ике чирек, бер әчмуха, бер кайчы, бер йозак авырлыгы... Хәдичәгә бирәсе солы оны: сигез кадак, бер чирек, бер богау йозагы...» дигән чуарланган дәфтәр бөгәрләнеп янды». Биредә авыл кешеләренең алачак-бирәчәк әйберләрен ни рәвешле исәпләп барулары ачык сурәтләнә. Әдипнең күзәтүчәнлеге, гади авыл кешеләренең тормыш-көнкүрешен үз тәҗрибәсеннән чыгып белүе «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда да ачык чагыла. М. Мәһдиев бу әсәрдә үлчәм берәмлеге граммның сыек җисемнәр күләмен белдерә башлаган чорын тотып алган һәм үз хис-тойгыларын укучыга болай җиткергән: «Буфетта эшли торган яһүд хатыны безгә кырлы кечкенә стаканнарга салып кызыл аракы бирде. Эчтек. Йөз граммы сигез сум туксан тиен, диде. Бер унлык, тагын ике өчәр сумлык. Бер унлык, тагын өчәр сумлык, тагын бер сум сиксән тиен акча бирдек. Күңелне күтәрәсебез килде, ләкин берни дә тәэсир итмәде. Тукта, нинди йөз грамм? Каты әйберләр үлчәве бит ул! Сыек әйберне алай гер белән үлчиләрмени? Безнең авылда майны гына шулай гөрәнкәләп үлчиләр иде. Йөз грамм... Бу сугыш әллә нәрсәләр китереп чыгарды. Сыек әйберне кайсы җүләре шулай гер белән үлчи инде?»

Җирле сөйләшләр материалларын, әкият һәм мәзәк текстларын, әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында авырлык мәгънәсен чагылдыра торган сүзләрнең киң кулланылганлыгы ачыкланды. Авырлыкны белдерү өчен нигездә махсус сүзләр – үлчәм берәмлекләре файдаланыла. Алар телнең барлык стильләрендә дә чагылыш табалар һәм мәгънәне конкретлаштырып, әйтеләсе фикерне үтемле итүдә зур роль уйныйлар.

Әдәбият

1. Әхмәтьянов Р. Татар теленең этимологик сүзлеге. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. Т.1. – 540 б; Т.2. – 568 б.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. Т.1. – 476 б.; 1979. Т.2. – 726 б.

Чыганаклар

Еники Ә. Саз чәчәге. Казан: Тат. кит. нәшр., 1956. – 95 б.

Исхакый Г. Зиндан.– Казан: Татарстан кит. нәшр., 1991. – 672 б.

Мәһдиев М. Әсәрләр. Казан: Мәгариф. 2005.– 271 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 китап. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. – 407 б.

Татар халык иҗаты. Мәзәкләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979.–382 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр.– Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. –591 б.

Равил ӘМИРХАНОВ

Печән базары

Калаларны кала иткән тарихи корылмалар, халык күңеленә сеңеп калган истәлекле урыннар бар. Мәсәлән, Парижны Эйфель манарасыннан аерып күз алдына да китереп булмый. Ул аның визит таныкламасы. Нью-Йорк «Азатлык» статуясы белән данлыклы, Лондонны Изге Павел соборы бизәп тора. Тулы бер мәмләкәтләрнең символына әверелгән һәйкәлләр дә хәтсез. Хеопс пирамидасы Мисырны гәүдәләндерсә, Кытайны мәшһүр Кытай стенасы күз алдына китереп бастыра.

Шөкер, безнең Казаныбыз да ким-хур түгел. Ул да бөекләр арасында. Париж, Лондон, Пекиннар кебек үк, аның да үзенә генә хас чын йөзе формалашкан. Рәхмәт ата-бабаларыбызга, шәһәрнең урынын да сайлый белгәннәр, төзеп тә күрсәткәннәр.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, шәһәребезнең йөзек кашы булып Сөембикә манарасы калкып чыккан. Тик шунысы да мәгълүм, Печән базары дип аталган борынгы сәүдә-сәнәгать комплексы кайчандыр тагын да зуррак популярлык белән файдаланган. Көнчыгышта гына түгел, Европада да аны яхшы белгәннәр. Хәзерге көнгә кадәр ул җуелмыйча халык күңелендә кадерләп саклана. Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасындагы төп вакыйгалар, мәсәлән, шушы базарда бара. Һәм һич тә очраклы түгел. Бу – Хәтер!

Иртә берлән кайнамакта бу базар:
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.
Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Әйдәгез, без дә Хәтер йомгагын сүтә-сүтә Печән базарыбызның тарихын барлап чыгыйк.

...Моннан бик күп вакытлар элек Идел белән Болак арасында болынлыклар җәйрәп яткан. Яз көне исә ул җирләр тоташ су дәрьясына әверелгән. Җәен монда көтү көткәннәр, печән хәзерләгәннәр.

Шәһәр үз рәвешенә кергәч, булачак Печән базары мәйданы яугирларның хәрби осталыкларын арттыру буенча күнегүләр ясау урынына әйләнгән. Җыен һәм Сабан туе чорларында анда төрле-төрле ярышлар үткәрелгән, ярминкәләр ачканнар, халык кәефсафа корган, ял иткән. Аларны манзара кылырга дип монда Олуг бәкләр, Бөек ханнар килгән. Шуңа күрә рус елъязмаларында әлеге урынны «Патша болыны» дип атаганнар.

Казан ханлыгы оешканнан соң, хәзерге Киров урамының XVIII гасырдан алып 1935 елга кадәр Мәскәү урамы дип йөртелгән өлешендә Кәрәеш бистәсе барлыкка килгән. Ханлыкка нигез салган Олуг Мөхәммәд аны үзенең Кәрәеш атлы бәгенә бүләк иткән, имеш. Бистәнең исеме шуннан килә. Ул койма белән әйләндереп алына, әмма шәһәр сызыгына керми, мөстәкыйль тормыш кичерә. Бистәдә халыкка риваятьләргә кергән Әтүч мәчете хезмәт күрсәтә. Әтүч үзе Казанның беренче воеводасы була. Ә мәчете ким дигәндә XVI гасыр азагына кадәр тора. 1566-1568 еллар Язу кенәгәсендә ул «Посад Казанской» бүлегендә телгә алына. Чөнки бу вакытта бистә шәһәр хакимиятенә карый инде. Әлеге Аллаһ йорты «Патша кенәгәсе»ндә дә чагылыш таба. Чөнки Иван Грозныйның ставкасы шуннан ерак түгел урнашкан була.

Алгарак китеп булса да әйтик, бүген Киров урамында балкып утыручы Нурулла мәчете элеккеге Әтүч мәчете урынына салынган, һәм XVIII гасырның беренче унъеллыкларында нәкъ менә шуның тирәсендә Печән базары барлыкка килә.

Барлык билгеләр шуңа ишарәли, Печән базарының мәйданы хәзерге Г. Камал урамы тирәсеннән башланып, Париж Коммунасы урамы белән төгәлләнгән булырга тиеш. Көньяк чиге – Киров урамының уң ягы, ә төньяк чиге – бензин салу станциясе һәм Киров бакчасы артындагы Столбов урамы.

XIX гасырда яшәгән тарихчы Н. Загоскинның язып калдыруынча, базар 16300 квадрат метр мәйдан биләгән. Бу аның чәчәк аткан чорына туры килә. XVIII гасыр башында исә сату урыннары элекке Мәскәү урамындагы бер зур булмаган күл янына урнаша. Күлне 1832 елда гына күмәләр.

Барысы да 1722 елның маенда Бөек Петрның Казанга килүеннән башлана.

Зур кунакны каршы алу уңаеннан Михляев йорты белән рәттән кечерәк кенә мәйданда урнашкан ат базарын әлеге күл янына күчерәләр. Патшага күрсәтәселәре килмәгән, күрәсең. «Ат аунаган җирдә төк кала», ди. Тиздән бу базар да печән белән каплана. Шуңа ишарә итеп булса кирәк, тора-бара халык аңа Печән базары дигән исем тага.

Базар әкияттәгечә ай үсәсен көн үсә. Дилбегә буе сузылган бер катлы лабазлар, складлар, ләфкәләр, яңа кварталлар үсеп чыга. Тәрәзәләре булмаса да, ат башы кадәр йозаклы авыр тимер ишекләре була ул корылмаларның. Эчләрендә ни генә юк: тире, күн, аяк киеме, мех, йон, он, ярма, тимертомыр һәм башка җаның теләгән бөтен кирәк-ярак. Киров бакчасы артындагы ул лабаз-складларның хәрабәләрен теләгән кеше бүген дә күрә ала.

Печән базарының көнбатыш чигендә танылган галим, Казанның мактаулы гражданины Карл Фуксның йорты утырган. Бу йортның, әлбәттә, башта күршесе Апанаев мөсафирханәсеннән аермалы буларак, сәүдәгә бернинди катнашы да булмаган.

Апанаев йорты XIX гасырның беренче яртысында ике каттан тора. Беренчесендә, гадәттәгечә, сәүдә рәтләре урнаша, икенчесендә номерлар җиһазландырыла. Соңга таба бу ике йортны гомуми өченче кат тоташтыра. Шулай итеп, зур кунакханә барлыкка килә. Бу комплекс Печән базарының кәрван-сарае ролен үти.

Апанаев мөсафирханәсе күршесендәге бер катлы лабазлар XX нче гасырның җитмешенче елларында да исән-сау иде әле. 1973 елда аларны бульдозер белән пыранзаран китереп, «Татгаз» үзенә административ бина корып куйды. Бертуган миллионер Юнысовларның складлары әле бүгенгә кадәр сакланган (Киров урамы, 66 нчы йорт). Шунда ук үз вакытында бик дәрәҗәле булган «Амур» кунакханәсе, Болак арты Почта-телеграф конторасы (эре сәүдәгәр Усмановның элекке йорты)... Купецлар, промышленниклар аннан депешалар җибәргәннәр. Ә 1888 елдан башлап контора башлыгы титуляр советник Яковлевның рөхсәте белән телефоннан да шалтырата алганнар. Үз чоры өчен бу бик зур уңайлыклардан саналган.

Риваятьләргә караганда, Печән базарының төньягында (Киров бакчасы арты) борынгы татар зираты булган. Бу зират турында рус ельязмаларында да мәгълүматлар бар. Аерым алганда, «Патша кенәгәсе» язганча, Иван Грозный Шаһгали ханга «Болак артындагы зират» яныннан Казанны камый башларга боерган.

Базарның үзәк урыны булып, әлеге дә баягы, Печән мәйданы саналган. Тарихчы һәм мәгърифәтче Каюм Насыйриның билгеләп

үтүенчә, XIX гасырның соңгы чирегендә монда ике йөздән артык кибет эшләгән. «Базарда әти-әнидән кала барысын да табып була», – дип мактанганнар сәүдәгәрләр. Ул чакта Апанаевлар, Юнысовлар, Усмановлар, Хөсәеновларның исеме телдән төшмәгән. Базар яны чәйханәләрендә һәм трактирларда мал-туар, пушнина, йон, галантерея товарлары сату буенча эре-эре килешүләр төзегәннәр. Ерак Персия, Кытай кебек илләр белән дә алыш-биреш иткәннәр. Базарда көнозын ыгы-зыгы тынмаган.

1845 елда (кайбер мәгълүматлар буенча 1849 ел) архитектор А. Песке проекты белән корылган Җәмигъ мәчете (хәзер ул «Нурулла мәчете» дип атала) бик табигый рәвештә сәүдә мәйданы комплексына кереп урнаша. Шуның белән Казанның иҗтимагый-сәүдә үзәге сыйфатында Печән базары формалашуы төгәлләнә. Монда татар милли йөрәгенең тибеше тоемлана. Күрәсең, шуны истә тотып, кайбер тарихчылар элекке Мәскәү урамының көнчыгыш өлешенә «Мөселман карагруһчыларының оясы» дигән тамга сукканнар. «Эт өрә тора, бүре йөри тора» дигәндәй, мәчетебез хәзер икенче яшьлеген кичерә. Иншалла, аның гомере әле бик озын булыр.

«Печән базары, сәүдә урыны булу белән бергә, Европа белән Азия гореф-гадәтләре, мәдәнияте һәм төрле мәнфәгатьләрнең үзара аралашып очрашкан, искелек белән яңалык көрәшен чагылдырып килгән бер урын буларак та истәлекле.

Егерменче йөздән башлап Казанның татар өлешенә төшкән иҗтимагый тормышының, әдәби, мәдәни хәрәкәтенең җеп очы шушы мәйданга килеп тоташкан. Китапчылар, китап кибетләре, басмаханәләр, нәшриятлар, гәзитә-журнал идарәләре шушы мәйданда булган. Татарга театр уеннары, концерт, лекцияләр шунда уздырылган» (Исмәгыйль Рәми, Рәис Даутов, «Әдәби сүзлек», 2001 ел.)

Тарих тәгәрмәче әйләнүен дәвам итә. Елларны еллар алыштыра, ниһаять, тормышның астын өскә әйләндереп ташлаган унҗиденче ел да аяк баса. Үктәбер инкыйлабы үз тәртипләрен урнаштыра. Күп тә үтми трамвайлар йөрүдән туктый, аннан соң сууткәргечләр сафтан чыга. Кибетләр, ләфкәләр ябыла, урам сатучыларының да кайсы кая китеп югала. Печән базары чүп-чар белән тула. Чөнки 1899 елда шәһәр башлыгы С. Дьяченко тарафыннан төзелгән чистарту бригадасы таратыла. Казанның Балык мәйданы, Зур Проломная урамы сәүдә үзәкләре дә шундый ук язмышка дучар булалар.

Яшәү өчен кирәк булган иң кирәкле нәрсәләр: ипи, тоз, сабын, дарулар җитешми. Егерме беренче елгы ачлык хәлне тагын да кискенләштерә. Шуңа күрә 1921 елда хөкүмәт хосусый эшмәкәрлекне торгызырга мәҗбүр була. Печән базары да иркен сулыш алып куя. Җылы яңгырдан соң чыккан шытымнар шикелле, бер-бер артлы кибетләр калка. 1922 елда трамвай йөри башлый. 1925 елда сууткәргеч җанлана. Хәтта Болак тамагында күптәннән онытылган «Ташаяк» ярминкәсе капкаларың ача. Тарихчы һәм археолог Н. Калининның мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1926 елда Печән базарында сатып алучыларга 285 кибет товар тәкъдим итә. Хәтта Казанның иң озын сәүдә урамы булып саналган Зур Проломная урамында да кибетләр саны 225 тән узмый. Балык рәтләрендә – 160.

Кызганычка каршы, НЭП озак яшәми. Шулай да базар тартыша-тырмаша, тернәкләнергә омтыла. Чөнки сәүдә – татарның канына сеңгән шөгыль. Аңа ат ничек якын булса, сәүдә дә шул кадәр үк кадерле. Ләкин дөнья инкыйлабы турында аһ орган большевиклар милли үзенчәлекләр белән санлашып тормыйлар. Аннан соң, стихияле базарны түгел, дәүләт сәүдәсен үстерергә кирәк! Моның нәрсә белән беткәнен безнең буын белә инде.

...Сәясәт үзгәрә. Шуның белән бергә татарның милли горурлыгы булган Печән базары да яшәүдән туктый.

Бу язманың башында Париж, Лондон кебек дөньякүләм күренекле шәһәрләр телгә алынган иде. Аларда Эйфель манарасы, Изге Павел соборыннан тыш та тарихи һәйкәлләр бик күп: урамнар, биналар, бакчалар, урманнар, елгалар... Хәзер бөтен җиһанда «Инглиз үләне» дип даны киткән ишегалды үләнен генә дә, мәсәлән, инглизләр гасырлар буе кадерләп саклыйлар, үзләренең милли горурлыгы дип саныйлар.

Совет чоры тарихка битараф булды. Безнең үзебезнең дә мәнсезлегебез баштан ашкан. Әйтик, милли яшәешебездә тирән эз калдырган Печән базары исеме кайда рәсмиләштерелгән соң? Ким дигәндә, шул Киров урамына гына булса да әлеге күңелгә якын исемне бирергә ярыйдыр ләбаса!

Исән калган корылмаларны реставрацияләү әмәлен дә табасы иде...

Раилә ХӘЯЛИЕВА

«Берзаман бардым Печән базарына, – Шунда мин таптым азык язарыма...»

2013 ел. Милли җанлы иҗади татар яшьләренең яңалыкка омтылып, дәрте ташып торган чоры.

Апрель. Социаль челтәрләрдә: Бөтендөнья татар яшьләре форумының Казан бүлеге активистлары Казанның Париж коммунасы урамында, «Нурулла» мәчете янында шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 100 ел тулу уңаеннан «Тукай 100е» акциясе кысаларында «Печән базары» дип исемләнгән чара оештыра, дигән хәбәр таралды. «Печән базары»нда кем теле шул катнаша ала, әмма монда килүнең шарты бар: «Печән базары»на килгән һәркем, XX йөз башында яшәгән татар образына туры китереп киенеп килергә тиеш иде.

Чыннан да ул елны «Нурулла» мәчете янындагы мәйдан чуклы ак шәлләр бөркәнгән, калфак, читек, чигүле камзул кигән кызлар, ханымнар, яшел, кара бәрхет түбәтәйле егетләр белән тулы иде. Кайберәүләр бу чарага дип, махсус, милли стильдә киемнәр дә тектереп кигән. Һәркемнән күтәренке бәйрәм рухы, шатлык, милли горурлык хисләре аңкый. Әнә, мәчет янында агачтан гади генә сәхнә дә оештырып куйганнар. Анда яшь шагыйрьләр сикереп менеп ялкынлы шигырьләрен сөйли... Күңел читендә Тукай, Әмирханнар турында истәлекләр, XIX йөзнең яңа карашлы яшьләре оештырган гүзәл кичәләр, милли хәрәкәтләр турында хатирәләр яңара. Шөкер! Безнең заманның милли үзаңлы татар яшьләре Печән базары рухын уятырга тырыша, Париж коммунасы урамы татар рухы белән тулган иде. Кайнар чәй, өчпочмак, алыш-биреш, җанлы аралашу... Үзара сөйләшүчеләр бер-берсенә «туташ», «әфәндем» дип эндәшергә тырышты. «Печән базары»ндагы үзенчелекле типажларны күзәтү аеруча кызык иде. Әнә, авылдан шәһәрне күрергә, кызыл билле прәннек алырга килгән кызлар-апайлар, пөхтә итеп киенгән гимназисткалар, чая гына алыш-биреш итүче сәүдәгәрләр, үзләрен бик иркен тотучы ялкынлы йөрәкле шагыйрь әфәнделәр, татар басмаларыннан килгән кыю газитчеләр, нәширләр... Кем генә юк, Печән базары шаугөр килде! Ярминкә буйлап яшь шәкертләр «Аң» журналын таратты. Бу санда шагыйрь Габдулла Тукайның үлемен хәбәр иткән язма, Печән базары турында мәкалә һәм Тукай турында урыс телендә кызыклы фактлар урын алган иде.

Беренче «Печән базары» Тукайга дога кылу һәм «Туган тел» җырын бергәләп башкару белән тәмамланды. Үткәрелү вакыты берничә сәгатькә генә сузылса да, киләчәктә яңа милли чаралар оештыруга этәргеч бирә торган вакыйга булды ул. Милли бизәкле киемнәрне кулланылышка кертүгә, милли ризыкларыбызны рекламалау, Иске Татар бистәсенең тарихына игътибарны юнәлтергә

тырышу, мәдәни кыйммәтләребезне популярлаштыруга зур юл ачты.

«Иртә белән кайнамакта бу базар,
*Анда да монда да кызадыр сәүдәләр.»**

Алдагы елларда «Печән базары» инде һәркем көтеп ала торган җәйнең бер ямьле бәйрәменә әйләнде. Катнашучылар елдан-ел арта барды, чараның диапазоны киңәйде. Милли стильне кулланып иҗат итүче дизайнерларның төп сату һәм тәҗрибә урыны булып хезмәт итә башлады. Биредә махсус заманча тегелгән милли киемнәр, сирәк китаплар, интерьер бизәкләре, сувенирлар һәм тагын башка бик күп кызыклы һәм кирәкле әйберләрне табарга була; аш-су осталары, фотографлар, рәссамнар үз иҗат җимешләрен күрсәтә, сата ала. Күргәзмәләр эшли, концертлар куела, иҗади бәйгеләр оештырыла. Базарның урыны да үзгәрә – ул яңартылган Татар бистәсендә уздырыла башлый. Аннан Черек күл паркына күчә һәм инде ул яңа татар мәдәнияте фестивале буларак формалаша.

«Кариэм, иткел канәгать барына,
Итмәсәң – әйдә Печән базарына!»

Быел да Черек күл паркында «Печән базары» бик зурлап узды. Бик күп халык җыелган иде. Гадәттәгечә һәркем милли стильдә киенергә тырышкан, заманча парк XX гасыр башы төсмерен алган иде. Күпләрнең аралашу, күрешү (бу чарага махсус чит илләрдән дә кайталар хәзер!) урыны, өметле татар яшьләренең сулышын үзенә сеңдергән заманча «Печән базары» фестивале белән тулырак таныштырыр өчен без Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе урынбасары, «Печән базары» фестивале оештыручысы Гүзәлия Гыйниятуллина белән Черек күл паркында очрашып сөйләштек.

– Гүзәлия, быел «Печән базары» инде алтынчы тапкыр уздырылды. 2013 елда узган «Печән базары» белән бүгенгесенең аермасы шактый...

– Һичшиксез! Хәзерге «Печән базары» ул – Казан шәһәрендә уздырылучы ачык татар чараларының берсе. Башлангыч елларда «Печән базары»на ун дизайнер килгән булса, быел 100 дизайнер катнашты. Алар арасында Казаннан гына түгел, Мәскәү, Башкортостан, Пермь, Ижау, Финляндия, Бали утрауларыннан килгән, үз өлкәсендә уңыш казанган, чит ил тәҗрибәсен дә туплаган татар дизайнерлары бар иде. Быелгы «Печән базары»ның төп үзенчәлеге – башкорт, себер, әстерхан татарларының биюләре буенча мастер-класс булды. Егетләр-кызлар рәхәтләнеп татарча биергә өйрәнде. Шулай ук лекция мәйданчыклары бик көчле эшләде. Казандагы татар архитектурасы, җәдидчеләр, милләт өчен янып-көеп йөргән, тарихта якты эзен калдырган күренекле хатын-кызларыбыз,

Казандагы сулыклар темасын күтәргән кызыклы лекцияләр булды. «Гыйлем» берләшмәсе химия, физика фәннәре буенча татарча лекцияләр уздырды. Татар кызлары өчен «Татар стайл» мәйданы эшләде, акустик татар музыкасы, заманча рәссамнарның инсталляциясе тәкъдим ителде. Милли ризыклар сатыла торган зонада себер кызлары чияшәңгә, башкортлар шәңгә пешереп күрсәттеләр. Фестиваль Казанда узган Бөтендөнья татар яшьләре форумы көннәренә дә туры килде, шунлыктан чит илдә яшәүче татарларыбыз да катнашты.

– «Печән базары»ның беренче елларында милли бизәкле киемнәр, бизәнү әйберләре сатып алу, милли стильдә иҗат итүче дизайнерларның кызыклы табышларын күрергә

килә идек. Соңгы елларда, сату нокталары күбәйсә дә, дизайнерлар эшчәнлегендә алга китеш сизелми кебек. Сез оештыручылар үзегез нинди фикердә?

– Килешәм. Татар дизайны ул – күлмәк яки футболкага лалә чәчәген төшерү белән

генә чикләнми. Кызганычка каршы, бездә әлегә шулай кабул ителә. Беренчедән, татар дизайнерлары өчен үсәргә мәйданчыклар бик аз. Икенчедән, алар өчен уку-укыту оештырырга кирәк дип уйлыйм. Безнең «Җәдидфест», «Акыл фабрикасы» кебек яшьләр яратып йөри торган башка чараларыбыз да бар. Бәлки шунда дизайнерларыбызның белемен күтәрүне оештырырбыз.

– Тагы бер четерекле сорау бирәсем килә, Гүзәлия. «Печән базары»нда милли әйберләрне заманчалаштырып күрсәтү максат итеп куелган. Фестиваль турында сөйләгәндә фуд-корт, дизайн-маркет, бию for you, стайл кебек безнең колак ишетеп ияләшмәгән сүзләр кулланасың. Менә шулай европачылыкка тартылып асылыбызны онытмабызмы?!

– Татар телен – әби-бабай янында гына сөйләшә торган авыл теле, татар дөньясы ул – чәкчәк, өчпочмак дип кенә күз алдына китерүчеләр бар. Безнең татар культурасы – ул авыл гына түгел, шәһәрдә яшәүче татар яшьләре дөньясы да әле.

Татар телен, татар дөньясын популярлаштыру өчен актуль эшләр башкарырга, заман яшьләре телендә сөйләшергә кирәк дип уйлыйм мин. Безнең принцип: барлык актуаль форматларны «татарлаштырырга» тырышу. Татарларга хас булган нәрсәләрне яңартылган форматта тәкъдим итәбез. Киләчәктә «Печән базары» бөтен дөнья өчен татар мәдәниятен таныта торган этнофестиваль булып үсеп җитәсенә ышанам.

Оештыручыларның хыяллары зурдан, «Печән базары»н елдан-ел киңәйтү, Россия төбәкләрендә дә уздыру нияте белән яши алар. Ә мин унтугызынчы гасырда Казанның зур сәүдә үзәге булып торган, даны дөньяга танылып Кытайларга барып җиткән Печән базарының рухы һаман да яшәвенә ышанам. Әнә бит, Казанда, нәкъ элеккеге урынында татар яшьләре яңадан уятып җибәргән «Печән базары» фестивале инде Чаллы, Пермь шәһәрләрендә дә уза башлады. Хәтта Канада татарлары да быел «Печән базары» уздырырга җыена дип ишеттек! Татарстанның Мөслим районында да үзәк базарны «Печән базары» дип атап йөртәләр икән.

Татар халкында һөнәрчелек, сәүдә итү эше элек-электән үк киң таралыш алган. Үз тырышлыклары белән хәләл акчаларына милләтен үстерү, мәгърифәтле итүне төп максатлары итеп куйган күренекле эшмәкәрләр арасында Апанаевлар, Юнысовлар, Акчуриннар, Рәмиевлар бар. Бүгенге татар байлары арасында да югалып барган тарихи ядкарьләрне торгызучы, татар мәктәпләре ачучы милләт уллары, химаячеләр уянсын иде! Аларның милләткә иң кирәк чагы!

«Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Ну, Печән базары халкы күңеле шат!»

Фоторәсемнәр интернет челтәреннән алынды.

*Күпләр Печән базары турында Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын укып белә. Шагыйрь шул рәвешле татар халкы тарихында озак еллар дәвамында яшәп килгән бу күренешне мәңгеләштерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Язмада әлеге поэмадан өзекләр кулланылды.

Илсөяр ИКСАНОВА, Гөлсинә ХӘМИДУЛЛИНА

Сәфәр чык

Себер татарлары белән кызыксынуыбыз Казан дәүләт университетында укыган еллардан башланды. Искиткеч зыялы яраткан укытучыбыз, үзе Себер тумасы, танылган тел галиме, профессор Диләрә Гариф кызы Тумашева саз эчендәге авылларда гомер кичеп ятучы себер татарлары, аларның көнкүрешләре, себер сөйләше турында кызык-кызык мәгълүматлар җиткереп куя иде. Аннан инде Себер ханлыгы тарихын өйрәнү, тарихи язмышыбыздагы фаҗигаи уртаклыклар безнең бербөтен, бүленмәс халык икәнлегебезне яшь аңыбызга сеңдереп куйды. Тагын бер Себер тумасы, затлы галимәбез Флора Ваһап кызы Әхмәтова-Урманче белән танышу халкыбызның гаҗәеп тирән байлыгына – зур өлеше Себер якларында сакланган дастаннарыбызга алып керде. Бер чорда укып йөргән студент дусларның Төмән, Тубыл якларына татар теле укытырга китеп барулары исә ерак Себер белән араларны тагын да якынайткандай итте. Тик себер татарлары белән без чын-чынлап «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивальләрендә генә аралаша башладык. Һәм, бу якларда әле без белмәгән, без күрмәгән никадәр рухи байлык сакланганлыгын аңлап, таң калдык. Ул халык авыз иҗаты, төйдерүләр, музыкаль фольклор, йола-гадәтләр... Даими укучыларыбыз хәтерлидер, Себер якларындагы үзебезне сокландырган табышлар белән басмабыз битләрендә (алар арсында Көнбатыш Себер татарларының музыкаль фольклорын җыйган Илгиз Шәфикъ улы Кадыйровның кызыклы табышлары аерым игътибарга лаек) һәрдаим уртаклашып килдек.

2009 елда Төмәндә үткән «Түгәрәк уен» фестивале вакытында Төмән, Тубыл җирләрен бер барып күргәч, күңелдә бу якларга яңадан иркенләп килү теләге калды. Ниһаять, дистә

тык Себергә...

елга якын вакыт үткәннән соң, безнең ниятебез тормышка ашты. Фестивальләрдә аралашып, инде якын дусларыбызга әйләнгән Төмән өлкәсе Түбән Тәүде районы Тарман авылы ханымнары янына киттек. Рәсми итеп түгел, гадәти кунак булып барып, Себер авыллары тормышын эченнән күрәсебез килде. Күрдек. Күрдек кенәме?! Гаҗәеп ачышларга юлыктык без бу якларда. Бу ачышлар яраткан шагыйребез Хәсән Туфан биографиясендә әлегәчә ачыкланып бетмәгән серләр белән бәйле...

Безгә шундый матур дөньяны ачкан Екатерина (Мәргубҗамал) Әхмәтҗановага аерым рәхмәт! Безне үз йортына сыендырып кунак иткән Разия Муллакова һәм аның бертуган апасы Фәүзия ханымга мең-мең рәхмәтләр! Халкыбызның борынгыдан килгән кунакчыллыгын раслап, өйдән-өйгә кунакка йөрткән, мул табыннар корып каршы алган, күңел байлыклары белән бүлешкән Кафия Балдашова, Зөлфирә Абдеразакова, Зөлфирә Хәмидуллиналарга рәхмәт хисләребез чиксез! Төмән телевидениесеннән «Очрашулар» тапшыруының мөхәррире Ләйсән Фазлуллинаның килеп, сәяхәтебез турында тапшыру эшләп китүе үзе безнең өчен көтелмәгән бер очрашу булды. Бер күрешү бер гомер, дип, армый-талмый татар мәдәниятенә хезмәт итүче Ильяс Бакиев белән Юлдаш Кәбиров йөзләгән чакрым араны узып, Ялутор районының Аслана авылыннан ук килеп җиттеләр. Чынлап та, бер гомер яшәп кайткандай булдык Себер якларында. Тарманның аккошлар төшкән күлләре, бу күлләрнең алтынсу табан балыклары, якты урманнары, «пичиннәр-җеннәр яшәгән» серле атаулары... барысы, барысы күңелгә якты хатирәләр булып кереп калды.

Тарман авылының атаклы балыкчысы
Таһиров Харис

Тарман-Саз

Бирегә килеп беренче нигез казыгы кагучылар яшәү урынын сайлаганда ялгышмаган: авылның буеннан-буена мул сулы, балыклы күлләр тезелеп киткән; кул сузымында гына – киек җанварларга, төрледәнтөрле җиләк-җимешкә, гөмбәгә бай урман. Авылның икенче атамасы – «Саз». Шушы ике атаманы бергә кушып караганда, авыл исеме «сазлыктагы тар коры җир» булып чыга, дип аңлаттылар.

Риваятьләргә караганда, авылга якынча 440 яшь. Иң башта биредә бер-берсеннән якын гына урнашкан өч авыл – Түбән, Урта һәм Югары Тарман (башкача әйткәндә, Түбән, Урта һәм Югары Саз) авыллары барлыкка килә. Тора-бара бу авылларны башка атамалар белән атый башлыйлар: Эскеле, Кирәет (кабилә исеменнән) һәм Аргы авыл. Бүгенге көндә бу авыллар бер-берсе белән кушылып беткән һәм нәтиҗәдә гомуми озынлыгы 12 километрга сузылган зур авыл хасил булган.

Авыл тирәли тезелеп киткән күлләрнең саны башта унике булса, хәзер сигезе генә калган, башкалары кипкән. Әлеге күлләр борын-борыннан табан (карась) балыгы белән дан тота, бу балык бүгенгә кадәр тарманлыларның табынында иң затлы һәм кадерле сый булып тора. Күлләр авыл халкын эчә торган су белән дә тәэмин итә: күпчелек халык, көзен күлдә боз каткач, бозны кисеп махсус чаннарга тутырып куя да шуны эретеп эчә. Әлеге суны «боз су» диләр.

Өлкән буын әйтүенә караганда, элек, язларын күлләргә исәпсез-хисапсыз кыр казлары, кыр үрдәкләре очып килгән, халык шуларны аулап арба-арба төяп кайта торган булган.

Авыл халкы үзен себер татарлары, җирле тел белән әйтсәк, себрәкләр дип саный, себер шивәсендә сөйләшә. Шул ук вакытта, авылда «казанлы тугымнар» да бар. Шуларның икесе 20 чакрымлап ераклыктагы Казанка авылыннан килгән (бу авылга XX гасыр башында Казан якларыннан күченеп килгән халык нигез салган) ике оста куллы кеше – Фәйзуллин

Гариф белән Кәлимуллин Гәрәй нәселләре. Төп чыгышлары Татарстанның Кайбыч районыннан. Беренчесен Тарманга бик оста тимерче булганга чакырып китергәннәр. Җир биргәннәр. Гарифның тимерчелек алачыгы күл буенда булган. Мәктәп музеенда Гариф тимерче кулы белән ясалган нәфис җиз комган да саклана. Бу кешедән тагын истәлек булып Гариф юкәләре һәм ул казыган кое да калган, аны хәзер дә «Гариф коесы» дип йөртәләр.

Гомумән, Казан ягыннан бу тирәләргә зыялы-укымышлы, бик күп төрле кәсеп-һөнәрләргә ия уңган-булган халык күченеп килгән.

Тарманда бүгенге көндә меңгә якын кеше яши. Шунысы куанычлы, халык саны елдан-ел арта бара икән. 2002 елда унберьеллык ике катлы мәктәп ачылган. Татар теле факуль-

Авыл иртәсе.

татив рәвештә генә укылса да, балалар бик матур итеп татар телендә (себрәкләр телендә) сөйләшә. Урамда очраган кеп-кечкенә балаларның да «Яхшымысез!» дип исәнләшеп үтүләре безнең өчен бик күңелле күренеш булды. Бу инде гаиләләрдә татар мохите хөкем сөрә дигән сүз.

Авылның ике башында ике мәчет балкып тора. Урманда йөргәндә, урман эченә кадәр ишетелгән моңлы азан авылның иминлеген хәбәр итеп торган якты бер аваз булып тоелды.

Тик шушы кадәр зур, мәдәниятле, бөтен Россия күләмендә танылуга ирешкән «Саз» фольклор ансамбле эшләп килгән авылда Мәдәният йорты булмауга гына аптырадык. Авыл уртасында иске клуб бинасы моңаеп утыра. Ансамбльнең репетицияләре мәктәп бинасында үтә. Район хакимияте бу мәсьәләне якын киләчәктә хәл итәр дип ышанабыз.

Авыл тарихына кагылышлы риваять-хикәятләрне дә телдән-телгә сөйләп, хәтердә саклыйлар тарманлылар. Авыл тирәсендәге Түш капка, Исәнәк, Кубаклы бил, Ишмә, Сыер төшеш, Бикмәле уймат дип аталган урыннарны күрсәтеп, әлеге атамаларга бәйле әллә никадәр кызыклы мәгълүмат сөйләп алды Катя (күптәнге дустыбыз Екатерина-Мәргубҗамал Әхмәтҗанованы без үз итеп «Катя» дип йөрибез). «Бикмәле уймат» дигән җирләре чынлап та бигрәк шомлы булып тоелды. Авылдан ерак та түгел түгәрәкләнеп үскән бу агачлык адаштыргыч урын икән, исеме дә «бикләп куя» дигәннән килеп чыккан. Шуңа анда бер кеше дә керми, хәтта терлек-туар да ул тирәне урап үтә, диделәр.

Катя-Мәргубҗамал

Авылдашлары Катя (фотода ул үзе пешергән камыр ризыклары белән) турында: «Аяклы энциклопедия ул безнең», – дигәннәр иде. Энциклопедия генә түгел, үзе бер дөнья ул Катя. Серле-тылсымлы, моңлы-дәртле, якты-сагышлы дөнья. Яшьлегендә бик нык укырга теләп тә, хыялының тормышка ашмый калуын үзе әрнеп сөйләсә дә, аны күбрәк белгән саен, язмышның бу чишелеше дөрес булгандыр, мөгаен, дип уйлап куясың. Авылыннан чыгып киткән булса, кайда булыр иде, нинди булыр иде ул бүген? Ә аннан башка авыл нинди булыр иде? Тарман авылының гаҗәеп кызыклы мифологиясен, йола-гадәтләрен, халык авыз иҗатын аның кебек итеп җыеп, туплап, сәхнәгә алып менүчесе табылыр идеме? Юк, ул шушы җирдә яшәр, шушы җирнең хәтерен саклар өчен яратылган шәхес. Аның сер белән өртелгән шәхси дөньясы, олыгайган көнендә ислам диненә килү тарихы, күрәзәчелек, имчелек сәләтләре ачылуы... үзе бер сәхифә. Сөйләсәң, кеше ышанмаслык, әмма хак бу сәхифәне әлегә без пәрдә артында калдырып торыйк. Һәм сүзне Катяның үзенә бирик.

– 1952 елның 16 маенда Салехард шәһәрендә туган мин. Әби-баба туфрагыннан еракта дөньяга килүем әниемнең язмышы белән бәйле.

Әнием Сәгыйдә дүрт яшендә тома ятим калган. Биш бала – өч кыз, ике ир бала була алар. Туганнары балаларны кайсын кая урнаштыра, әниемне икетуганы Рәйхана мама үз гаиләсенә сыендыра. Алар Уралга, хәрби заводка эшкә китәләр, әнием шунда үсә. 16 яше тулгач, заводка эшкә керә. Шунда Казан ягыннан килгән Әхәт исемле егет белән танышып, кавышалар. Озак та үтми Бөек Ватан сугышы башланып, Әхәт абыйны сугышка алалар. Әнием йөкле булып кала, авыр эштән корсагы төшә. Соңгы хатында Әхәт абый: «Бик каты сугышка кереп барабыз, Сәгыйдә, моннан исән калабызмы белмим, исән кайтсам, сине кулымда гына йөртер идем, туган илемә – Казанга алып кайтыр идем», – дип яза. Шуннан ул хәбәрсез югала.

Әни туган якларына кунакка кайткач, кире Уралга китәргә күңеле тартмый. Салехардта эшләүче икетуганы Солтанетдин бабай да авылга кайткан чак була. Ул: «Әйдә, Сәгыйдә, алып китим мин сине Салехардка, анда туклык, балык заводлары күп», – дип, аны үзе белән алып китә. Әнием шунда әтием белән таныша. Әтием Александр, Ленинградтан килгән, машинист ярдәмчесе булып эшли.

Мин туганнан соң, Рәйхана маманың («апа» дигәнне аңлата. – ред.) сугышта «хәбәрсез югалган» дигән ире кайтып төшә. Әсирлектә булган икән. Ул: «Сәгыйдә килсен, Әхәт белән әсирлектә бергә булдык, аның әйткән әманәтен тапшырасым бар», – ди. Әни барып җитә алмый, бабай үлеп китә. Нинди әманәт булгандыр, билгесез. Бары Әхәт абыйның илгә кайтмыйча, чит җирдә өйләнеп калуы гына мәгълүм.

Миңа бер яшь тулгач, әтинең биредәге эше бетә. «Монда бик суык, без җылы якка күченик. Син туганнарыңа кунакка кайтып тор, мин барып эшкә урнашыйм да сезне килеп алырмын», – ди ул әнигә. Авылга кайткач, туганнары: «Токымга оят ясап, урыска кияүгә баргансың!» – дип әнине бик нык сүгәләр. Шактый вакытлар үтә, әтидән бер хәбәр дә юк. Ник безнең белән бер дә кызыксынмый икән, дип борчыла әни. Бервакыт, туганының баласы ниндидер хат белән уйнап утырганны күреп ала. Хатның эче генә, конверты юк. Алып караса, әтинең хаты. «Ни булды, нигә сездән бер җавап та юк?..» – дип өзелеп яза әти. Әтидән килгән хатларның барысын да утка ташлап барганнар әнинең туганнары. Безне эзләп авылга килгән әтине, «Монда андый хатын юк!»

дип алдап җибәргәннәрен дә әни соңыннан гына белә.

Әни башка кияүгә бармады, мин шушы авылда үстем. Әбием миңа икенче исем, мөселман исеме биргән: Мәргубҗамал. (Әмма ул исемгә мин чын-чынлап олыгайган көнемдә генә ия булдым, Уфа мәчетендә азан әйттереп, үземә исем куштырдым. Тик монысы аерым тарих.) Мәктәпне бетергәч, бергә укыган кызлар кайсы кая укырга киттеләр. Минем дә укырга керәсем килә иде, әнинең сүзеннән чыга алмадым. «Мин сине берүзем тәрбияләдем, читтә йөрергә дип үстермәдем», – диде әни. Мине, оештыру сәләтемне белеп, клубка эшкә чакырдылар. «Читтән торып укырсың»,– диделәр. Мәдәни-агарту училищесында бер генә ел укып калдым, мине урладылар. Очрашып-сөйләшеп йөргән егетем дә түгел иде, шулай да кире кайтыр юл юк. Өйдәгеләр дә: «Кем белән каралгансың, шуның белән аклан», – гына диделәр. Шулай итеп, уку турындагы хыялларым тормышка ашмый калды, гомерем буена үзем белән бара. Шулай да иремә рәхмәтле мин, әйбәт балалар үстердек.

Ә фольклор белән кызыксынуым... Мин тумыштан фольклорда үстем. Безнең күршедә Мөҗип бабай (Мөҗибулла) белән Хөсни әби бар иде. Мин гел аларга керә идем, чөнки әби шулкадәр кызык итеп, төрле хикәятләр сөйли иде миңа. «Әйдә, кызым, керосин әрәм итмик», – дип, утны сүндерәләр дә ятабыз. «Кичә нимәне гапләдем әле?» – дип, ялгап сөйләп китә иде әби. Ул аларны әкият кебек, матур итеп сөйли: «Бер әби белән бабайның Колчак исемле уллары була. Аны косык суккалыкка (чикләвек җыярга) җибәрәләр. Шунда циялеккә (җиләклеккә) килеп чыга бу. Инәм ашасын әле, җыйыйм бераз, ди. Чиләге тула. Инде каяска койыйм (капчыкка салыйм) дисә, агачлар арасыннан төшкән кояшта капчыкның шәүләсе бик зур булып күренә дә малай, аю чыкты дип куркып, өенә йөгерә. Йөгергәндә гөлҗимеш куагына эләгеп киемнәре ертылып бетә. Кайтып керсә, әти-әнисе чәй эчеп утыра. Сәкегә кайтып ава бу.

– Ни булды, балам? – диләр моны күреп.

– Аю чыкты, аю белән көрәштем, – ди.

– Бала бик курыккан, бар, Хәлби маманы чакыр, имләсен, – ди әнисе әтисенә.

Хәлби маманы алып киләләр. Имли. Имләп төзәтә алмый.

– Нидән курыккан, шуның йоны кирәк, аю йоны кирәк, – ди.

Карт китә урманга. Бара. Аңлый, үзенең йөгеннән, шәүләдән курыккан бала. Кайтып сөйләсәң, оят. Токымга оят. Нишләргә? Кайта-кайта уйлана. Кайтып җитсә, халык җыелган, моны көтәләр. Карт әйтә:

– Хәтәр көрәш булган, алыптай аюга очраган, Колчак җиңгән ди. Колчакның батырлыгы турында берәү берәүгә өсти-өсти сөйләп, хәбәр саңгырау Зөлкарнәй бабайга барып җиткәндә, аю ике балалы ук булып куя.

– Ай хәтәр аюга очраган! – ди Зөлкарнәй бабай.

Шуннан боларның токымына Аю исеме ябыша».

Әбидә китаплар да бар иде. Элек билгеле бер кешеләрдә җыелып, көйләп китап укулар булган. «Ай матур көйләде, күзгә яшьләр килде», – дип сөйләшә торган булганнар. Күбрәк «Сак-Сок»ны, «Йосыф китабы»н көйләгәннәр.

Кечкенәдән кызыксынучан булганга, мин бөтенесен дә күңелемә сеңдерә барганмын инде. Шул гомер буена җыйган байлыкның кирәге чыкты бит. Инде мин лаеклы ялда идем. Клубыбыз юк. Мәдәни чаралар барысы да мәктәптә генә үтә. Безгә сәнгать җитәкчесе булып Җәгъфәр Касыймов эшкә килде. «Катя,

Тарман авылының «Саз» фольклор ансамбле. Л. Фазуллина фотосы.

син клубта эшләгән, кешеләрне беләсең, булышып кына җибәр», – диде. Шулай итеп, яңадан мәдәни тормышка кереп киттем. Без, мәдәни тормышта катнашып йөргән бер төркем, «Саз» фольклор ансамбле булып оештык. 2009 елда Төмәндә узган Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивалендә мәктәп балалары белән катнаштык. Анда әле нәрсә күрсәтергә кирәклеген бик үк белеп тә бетермәгәнбез. Фестивальдән күп нәрсәне аңлап кайттык. Мин шуннан үзебезнең яктагы такмакларны, табышмакларны (без лагап дибез) җыя башладым. Күп нәрсәләрне исемә төшереп, сценарийлар яздым. Ансамблебез белән без аларны сәхнәләштердек. Баксаң, безнең өчен гадәти булган көнкүрешебез себер татарлары фольклорын өйрәнүчеләр өчен үзе бер табыш икән!

2014 елда ансамблебезгә сәнгать җитәкчесе булып искиткеч талантлы музыкант Әбүзәр Миңнебаев килде. (Аның турында журналыбызның 2017 елның 4нче санынннан укый аласыз. – Ред.) Ул әби-бабаларыбыз борынгыдан уйнаган музыка уен коралларын торгыза башлады. Аның үз куллары белән ясаган кылкубыз, ятаган кебек уен коралары репертуарыбызны бермә-бер баетып җибәрде. Мине дә ятаганда уйнарга өйрәтте. Ятаганга кушылып башкара торган «Шәмчираг» («Шәмчырак») җырыбызны белгечләр дә бик кызыксынып кабул итте.

«Шәмчираг» җырына бәйләп, Катя безгә себер татарларындагы тулы бер туй йолалары системасын сөйләп бирде.

«Шәмчирагның янганыннан янмаганы яхшырак...»

– Әнием туйларга йөргәч, мин бик күп туй йолаларын үз күзләрем белән күреп үстем, почмакта утырып, күзәтә идем. Менә бер күренеш гел күз алдымда тора. Кыш көне иде. Караңгы төшә башлаган чак. Кияү йортыннан чыгып, кияүнең туганнары кыз ярәшергә юнәлде. Берничә ир-ат кулында утлы чыралар – шәмчираглар. Алар караңгыда һаваны яктыртып, сихри бер балкыш биреп баралар. Бер ир-ат гармунда «Шәмчираг» көен уйнап бара, аңа кушылып җырлыйлар. Кыз йортының ишегалдына кергәч, утлы җиде чыраны җиде кар көрте өстенә кадап куйдылар. Алар ялкынланып янып бетәргә тиеш. Кемдер килеп сүндермәсен өчен (бусы бик начар фал!), бер ир-ат шәмчирагларны саклап тора. Шәмчираглар кавышасы парның тормыш символы дип кабул ителә.

Кызны ярәшкәннән соң, негә (никах) була. Негәдә кияү кәләшенә бүләк – кияү мерәсе бирә. Кияү якныкылар пилцә (балан бәлеше) алып килә. Аны кияү якның җиңгәләре тапшыра, кызның ике җиңгәсе кисә. Пилцәнең өсте

каплаулы була, өстендә бүләк – яулыкмы, оекбашмы ята. Бүләкне алган җиңги: «Пилцә ачып алдым бүләкне, менә күрең», – дип биеп күрсәтә. Пилцә булгәндә аның көйләп әйтелә торган бик озын такмагы булган, шуңа күрә пилцә әйтмәле оста кешеләрне сайлаганнар.

Пилцә киләде, пилцә киләде,
Өере-өере пилцә килә,
Өере-өере пилцә килә,
Теләгәненә өеп бирә.
Бирмәгәннең күзе төшәр.
Ун тиен акчасын аяп,
Күченергә оят...

Бу пилцәне бөтен кеше дә аз гына булса да авыз итәргә тырыша. Бигрәк тә, өйләнмәгән балаларга каптырырга тырышалар, өйләнсен дип. Олылар гомерләрен, яшьлекләрен озайту өчен каба, пилцәгә тормыш көче салынган, дип ышаналар.

Никахтан соң кыз үз өендә кала, кызны алып китәсе көн билгеләнә. Аны Күцен аш (күчен – күчеп китә торган) дип әйтәләр. Никах узгач, кыз өендә дус кызларын җыеп Пулыш

үткәрәләр. Монда кәләшкә бүләкләр алып киләләр. Кызлар җырлыйлар, уйныйлар. Без инде күбрәк мәхәббәт җырлары, шаяртып, киявең тегеләй, киявең болай, дип төртмәле җырлар җырлый идек. Шунда инде кәләш ятаган алып, «Шәмчираг»ны җырлый, кызлар аңа булышалар:

Шәмчирагның янганыннан
янмаганы яхшырак,
Кыз баланың булганыннан
булмаганы яхшырак.
Иген иктем, чәчмә чәчтем,
арышларым урмадым,
Атам-инәм мөешендә
беразда да тормадым...

Бу – кыз баланың язмышына сагышланып, туган йортыннан аерылу җыры.

Аннан кодалар Куцен ашка киленне алырга киләләр. Куцкә килүчеләрне ишектән ял сорап бушаталар. Безнең якта капчык белән кедр чикләвеге бирәләр, бала-чагага да «Кияү бүләге» дип чикләвек өләшәләр. Кыз алырга килгән һәркемне өйдә кискән токмачлы аш белән сыйлыйлар, аны «Күцен аш эчү» диләр.

Киленне мөгәтәк (чегән кибеткасы кебек арба) белән алып китәләр. Дәрәҗәле ике җиңги кызны уртага алып утыра, артта нугәр егетләре белән кияү утыра. Кызга, «Утыргач, бер дә артка карама», – диләр. Борылып караса, кире кайта, дигән ышану бар. Куч киткәндә (кызны алып киткәндә), учак ягып, кияү белән килен утырган атны ут аша үткәрәләр. Уттан чистарып чыгып, яманлыклар калсын, дип. Ул инде уттан курыкмый утәргә өйрәтелгән атлар була. Кайвакыт атның күзен дә бәйләгәннәр. Без дә шулай уттан үттек. Хәзер инде уттан үтү юк, килен машина белән төшә.

Кияү йортында кызны каршы алырга әзерләнәләр. «Кәтәгә терәү» башлана – эш бүленә. Кияүнең анасы туганнарын җыя да, «Син сыерны алып чыгарсың, син килен җилписең, син туйда аяк уенын башлыйсың, син башлап җырлыйсың...», – дип кәтәгә тери.

Килен төшкәндә, мылтыктан аталар. Мылтыктан ату хәзер дә бар. Килен капкадан кергәч, бер кеше сыерны алып килә, килен сыерга таяна, сыерның җылысын тоя. Бу инде, сыер синең туендыручың, син монда хуҗабикә, дигән сүз. Килен сыерның мөгезенә яулык бәйли, сыерны алып килгән кеше яулыкны бүләк итеп ала.

Бер абруйлы олы апа алдан ястык әзерләп тора, палас суза. Ишек төбендә ике яшь кыз, уртадан әз генә ертып куелган тукыманы (ситец) ике ягыннан тотып торалар. Килен паластан барып, ястыктан атлап чыгуга, тукыманы шарт итеп ертып алалар: килен яңа тормышка аяк басты, дигәнне аңлата. Анда инде әлеге абруйлы апа, такмаклар әйтеп, яулык белән киленне җилпи. «Олыны олы ит, кечене кече ит, рәхимле бул! Парлы аякларың белән гомер ит! Өйгә бәрәкәт алып кил!», – дип, җилпеп, яманын калдыра. Килен җилпү теләсә кемгә эләкми, кадерле бер кешегә генә тапшырыла.

Килен төшкәч, тагын Күч ашы була, аны «Каршылау куч ашы» диләр.

Туй бер көн була. Монда кодалар каракаршы авыл көйләрен җырлашалар.

«Яшел яулык яшьләргә,
Килешә тигән төсләргә.
Төшләремдә сезне күрдем,
Насыйп булган күршергә», – дип, туй якныкылар килгән кодаларга җырлыйлар. Аннан каршы як җавап бирә. «Яр-яр»ны туйларда күмәкләп җырлыйлар:

«Сыктама, дустым, сыктама,
Туең булыр яр-яр.
Саман сылап оештырган
Өең булыр яр-яр...»

Элек бик матур итеп гармуннар уйнап «Шәмшәрифкәй»не җырлыйлар иде. Тәрәзәләр ачык, без – бала-чага – тыңлап йөрибез. Берәү башлап җибәрә, башкалар күтәреп ала. Җырлап алгач, аяк уены (төйдереп бию) була. Башлап җырлаучыга да, аяк уенын башлаучыга да аерым бүләк бирелә. Яулык атып бию була, яулыкны тоткан кеше биеп китә. «Аю уен» дип, дөбердәтеп бию бар иде.

Туйлар узгач, килен ягында да, кияү ягында да Түргеннәй йөриләр: якын туганнарын, туйда булышкан кешеләрне алып кодалар кунакка йөрешә. Монда инде кияү белән килен йөрми, алар өйне карыйлар.

Катя безгә тагын бу яктагы уеннар, уен кораллары, Тарман зиратында җирләнгән изге затлар-яхшылар, имчеләр, Әптәнәләр турында гаҗәп кызыклы мәгълүматлар сөйләде. Алар турында киләсе саннарыбызда укырсыз.

«Ахманым-Урманбашым»

Себрәкләр белән аралашканда әледән-әле казанлылар турында сүз чыккач, безнең казанлыларны, ягъни якташларыбызны да күреп китәсебез килде. Екатерина Әхмәтҗанованың Тарманнан 50 чакрым ераклыктагы Ахман авылында бик якын танышлары бар икән, ул безне шунда алып барырга булды.

Авыл халкы кырылып бәрәңге алып ятканга, машина табу шактый четерекле мәсьәлә булып чыкты. Алай да, берәү үз машинасында илтеп куярга ризалашты тагын. Урман эченнән салынган юлның күп өлеше шактый начар, сикәлтәле булуга карамастан, як-яктагы мәһабәт наратларга, күз камаштыргыч төсләр белән балкыган корама аланнарга хозурланып бара торгач, Ахманга барып җитүебезне сизми дә калдык.

Вакыт әле иртә, авыл халкы хуҗалыктагы иртәнге эшләрен карый булыр, урамда кешекара күренми. Бара торгач, капка төбендәге тракторы тирәсендә йөренүче ир-атны күреп, себрәкләрчә сәлам бирәбез: «Яхшымысез!» Катя көлеп җибәрә: «Полар пит сеснекеләр, «Исәнмесез!» тияргә кәрәк!» Бөтен килеше, йөз-кыяфәте белән безнең яклардагы авыл агайларын хәтерләткән бу кеше, Казан артына хас телдә, укытучы Гөлнур апа Хәйруллинаның йортын өйрәтеп җибәрде.

...Капка төбеннән үк башланып киткән түтәлләрдәге көзге чәчәкләргә сокланып, ишегалдына үтәбез. Болдырда безне, яше шактый өлкән булуга карамастан җитезлеген җуймаган гәүдәле, мөлаем йөзле, кызларныкыдай нәфис тавышлы апа каршы ала һәм гөлдер-гөлдер килеп эчкә алып кереп китә.

Тәрәзә төпләрендә янып торган яраннар. Идәнне тутырып җәйгән паласларны, «ялгагына» туктап калган тегү машинасын күргәч, күз алдына ерак балачакта калган дәү әниле өйләр килеп басты.

– Мин Гөлнур Әкрәм кызы Хәйруллина булам, – дип сүз башлады хуҗабикә. – 1937 елда Эске авылында туганмын. Бабайларым Казан ягы кешеләре. Әтием ягы Кайбыч районының Кошман авылыннан. Әниемнең бер ягы Башкириядән, икенче ягы шулай ук Казан ягы дип беләм. Алар башта Киндерлегә килеп утыралар. Аннары Сәләхетдин бабайны Эскегә мулла итеп җибәрәләр.

Һөнәрем буенча укытучымын. 38 еллык педагогик стажым бар. Тубыл педагогия училищесын тәмамлагач, өч ел Эскедә укыттым. Аннары урыслаштыру сәясәте башлангач,

Себергә Казан ягыннан тегүчелек һөнәре дә килгән.

Эскедәге җидееллык мәктәпне яптылар да бабалаларны урыс авылы Чугунаевога җибәрделәр. Мин Ахманга килеп башлангычта укыта башладым. Һәм шушы авылда тормышка чыгып, төпләнеп калдым. Хәзер бу авыл миңа туган авылым кебек инде. Бик яратып яшәдем, табигатен, кешеләрен... Бу хисләрем «Ахманым-Урманбашым» дигән китабымдагы шигырьләремдә, хикәяләремдә дә чагыла. (Гөлнур апаның «Балан ачыны?» дигән хикәясе белән 55 биттә танышырсыз. – ред.)

Биредә яшәү чорымда авылның тарихы белән дә байтак кызыксынырга туры килде. Ахман бу тирәдәге иң борынгы авыл. Аңа 1720 елда нигез салына. Беренче фараз буенча, авылга урыс яулап алуларыннан соң качып килүчеләр нигез салган. Икенчесе буенча, бирегә халыкны күчереп утыртканнар. Башлап себрәкләр авылы булган дип санала. Аннары Свердловск өлкәсе аша бу тирәләргә казанлылар килгән. Бездән кул сузымында гына Свердловск өлкәсенә керүче Салаер, Тәгән дигән татар авыллары бар. Казанлылар Ахман өстенә ишелеп торган калын урманнарны күргәннәр дә: «Менә монда икән ул урман башы», – дип шаккатканнар. Шуннан Урманбашы дигән икенче атама да барлыкка килгән. Ә Ахман атамасын «ак ман, ак су» дигән мәгънә белән бәйләп аңлаталар. Авыл уртасыннан Ахман елгасы ага, чыннан да бик чиста, саф сулы елга.

Күчеп килгәннәр белән аралашып яши башлагач, себрәкләрнең теле йомшарган, казанлыларныкы бераз катыланган. Уллар

өйләндереп, кызлар бирешеп уртак тормыш белән көн күрә башлаганнар. Килгән халык үзе белән дин, аң-белем, бик күп һөнәрчелек (тимерче, тукучы, тегүче, ташчы, мичче һ.б.) төрләре алып килә, шул ук вакытта алар себрәкләрдән Себернең кырыс шартларында көнкүреш итәргә, табигать байлыкларыннан файдаланырга, аучылыкка өйрәнә.

Авыл зурая. Колхозларны эреләндерү чорына хәтле ул аерым хуҗалык булып торган. Урман төпләп, чәчү җирләрен арттырганнар. Тырыш, намуслы хезмәт белән көн күрә ахманлылар. Авыр эшләрне бергәләп, өмә ясап башкарырга тырышалар. Шул ук вакытта, динен дә саклап кала халык. Бездә мәчет булмаган. Бер йортны мәчет итеп җайлаштырып, шунда гыйбадәт кылганнар. Даими рәвештә Коръән ашлары үткәреп, никах укытып, улларын сөннәткә утыртып яшәгәннәр. Әле менә сөенечле хәбәр бар: Түмән янындагы авылдагы (ул авыл инде шәһәр эченә кереп беткән) мәчетне сүтеп, безгә күчерергә җыеналар.

Безнең Түбән Тәүде районына казанлыларның зур күпчелеге 1921 елгы ачлык чорында килеп төпләнәләр. (Гомумән исә, Казан татарларының Себергә күпләп күченүе XX гасыр башында, Столыпин реформасыннан соң башлана. Чукындырудан качып килүчеләр бик күп була.) Минем кайнанам белән кайнатам – Фатыйма белән Шиһап Хәйруллиннар – Кайбыч районының Мөрәле авылы кешеләре. Алар да шул ачлык елны кузгала. Кайнанам сөйли иде: «Вагоннарга төялеп, Иркутски ягына юл алдык. Кайбыч районының Мөрәле, Кошман, Чәчкаб авылларыннан байтак кеше җыелдык. Сәяхәтебез ике айга сузылды. Бераз барабыз да туктыйбыз. Кайчагында туктап икешәр көн торабыз. Шәһәр тирәсе булса, таралышып хәер сорашабыз, ирләр баерак гаиләләрдә эшләп алалар. Кайбер вагоннарда тиф авыруы башланды. Солдатлар мәетләрне, авыруларны носилкаларга төяп алып чыгып китәләр. Әгәр авыруларны яшереп калдырганны белсәләр, поездны тупикка куялар, ул чагында икешәр атна торабыз. Минем килендәшем дә авырый башлады. Кайнатам иртәгесен госпитальгә хәлен белергә барса, килендәшем инде үлеп киткән. Аның балалары да безгә калды хәзер... Ачлык җелеккә төште. Менә берзаман вагон тирәсендә казахлар күренә башлады. Гаҗизләнгән халык шуларга буй җиткән, үсмер кызларын сата башлады...Ул кызларның илереп елаганнарын ишетсәң...» Менә шул михнәтләрне кичеп, 5 балаларын югалтып, Байкал тирәсенә килеп урнашалар алар. Ә абыйлары Минхаҗ Ахманга килеп төпләнеп, колхоз рәисе булып эшли башлаган булган. Минһаҗ, урыс арасында ятмасыннар дип, боларны үз янына чакыртып алган.

Себергә күченү тарихын Гөлнур апа шигъри юлларга да салган:

Егерме бернең афәтле ачлык елы
Тарихка фаҗига булып кереп калган.
Үле гәүдәләр өстенә ятып аналар
Кан аралаш ачы яшьләрен койган.
Калган җаннарны саклау өчен бабайлар
Күчеп килгән Себер дигән кырыс җиргә.
Урман-суның күплегенә куанганнар,
Әзерәк булган игенчегә тик җир генә.
Җиң сызганып керешкәннәр алар эшкә,
Агач кисеп, тамыр төпләп җир ачарга.
Маңгайлардан
кайнар тирләр аккан җиргә,
Уңдырышлы туфрак белән кушылып бергә...

Шунысын да әйтергә кирәк, килгән казанлыларга караш төрлечә булган. Мәсәлән, минем туган авылым Эскедә җирле себрәкләр аларны кертмәс өчен сәнәкләр белән каршы чыкканнар. Нурмөхәммәт бабай әйтә иде: «Үзем авылга керттермәдем, ә аннары кызымны казанлы Гыйлаҗ Хәмидуллин улына бирдем», – дия иде. Алты ир бала белән килгән була Гыйлаҗ Себергә. Алар Чугунаевода урыслар арасында яшәп алалар да барыбер Эскегә күченәләр. Өч улы сугышта ятып кала...

Бирегә килеп ач үлемнән котылып калсалар да, туган якларын бик сагыналар иде. Эскедәге балачагым искә төшә. 1943 елның кышы. Өстәлдә сукыр лампа. Әби мичкә тәгәрәтергә бәрәңгеләр юып куйган, инде кабак турый. Түрдә кайсы сәке читенә, кайсы урындыкка утырып кул эше эшлиләр. Әнием ак сарык йоныннан шәл бәйли. Маһигөл әбинең үги кызы Миңҗамал апа йон эрли. Фәрхинур апа оекбаш тоткан. Зәкия апа перчатка бәйли. Аннары әбием килеп, сүс эрләргә тотына.

Бәйрәм кичләрендә клубка җыелгач, әлеге ак шәлләрдән клуб эчләре ямьләнеп китә. Күңелләре китек булса да, кайгыларны бергә

күтәреп яшәделәр. Мәһигөл әбинең мөнәҗәте истә калган:

Ахырзаман җитә диләр, ниләр булгай?
Дөньяга төрле-төрле афәт тулгай.
Галимнәр чыгыр эчеп зина кылып,
Аннан артык нәмә хәрәм, ниндәй булгай?

Табышмак әйтергә бик һәвәс иде аннары әбием. Дөньяларның асты-өскә килгәнче арада хатлар йөреп торды. Аннары элемтәләр өзелде.

Ә менә кайнанам белән кайнатам Ахманнан Мөрәлегә кайтып йөрделәр, минем мәктәптә каникулым башлануга чыгып китәләр иде. Аннары, Мөрәледән кайнанамның апасы Кәримә әби килеп йөри иде. Умартачы әби. Бер елны моның кортлары күршеләрнең умартасыннан бал ташыган. Күршеләре зарлангач, әби умартасын сатарга мәҗбүр булган. «Берзаман кортларым буш ояга яңадан кайтып керделәр бит!» – дип көлә-көлә сөйләгән иде.

60нчы елларда мәктәп, кибет, клуб, медпункт, почта, хәтта саклык кассасына кадәр бар иде бездә, хәзер берсе дә калмады. Бүген авылда 33 хуҗалык. 1000 гектарга җиткән чәчү җирләренең дә бик аз өлеше генә игелә. Яшьләр калага китеп бара. Авылның киләчәге ничек булыр – моны әлегә әйтеп булмый. Бушап калган йортлар турыннан узганда аларның бакыйга күчкән хуҗалары белән сөйләшеп узам... Күңелдә истәлекләр яңара, йөрәкне әрнетеп, вакытында сорап калырга өлгермәгән сораулар калка... Шөкер, әлегә нык хуҗалыклы гаиләләр дә бар барын. Күпләп мал-туар асрыйлар, урманга җиләккә, гөмбәгә йөриләр, аучылык итәләр. Табигать биргән нигъмәтләрне Түмән базарына алып баралар. Иренмәгән кешегә яшәргә була...

...Гөлнур апа үз уйларына бирелеп туктап кала. Кайнанасының күзенә карап, һәр җөмләсен «әйе, энкәй!», «дөрес, энкәй!» дип җөпләп утырган Мәдинә килен (олы улы Рависның хатыны) сүзгә кушыла:

– Менә шулай авылыбызның киләчәге өчен янып-көеп яши безнең тынгысыз энкәй. Тарихыбызны, авылыбыз кешеләренең якты исемнәрен мәңгеләштерү өчен бер-бер артлы китаплар чыгара. 2015 елда авылыбызда зур вакыйга булды – мәктәбебезнең 100 еллык юбилеен бәйрәм иттек. Анысы да энкәйнең инициативасы белән булды. Әзерлек барышын, төрлесе төрле елларда мәктәптә укып чыккан кешеләрне җыюны да контрольдә тотты энкәй. Мәктәп инде күптән ябык булса да, ахманлылар һәм бездә укып чыккан күрше авыллар өчен шулкадәр тансык һәм кадерле очрашу булды ул! Күпме истәлекләр яңгырады, югалган элемтәләр яңарды. Кемнәр генә юк иде халык арасында: укытучылар, табиблар, фән, сәнгать әһелләре... Күбесе энкәй укытып чыгарган кешеләр. И ул көннең матурлыгын белсәгез! Сәхнәне мәктәп янында, ачык һавада көйләгән идек. Оештыру эшләрендә авылыбызның бик тә булдыклы егете, энкәйнең укучысы Инсаф Нигъмәтуллинның ярдәме зур булды. Тирә-якны шау чәчәкләргә күмдек. Кичтән яңгыр иде, иртәгесен ялтырап кояш чыкты. Безнең бәйрәм барышында һава чалт аяз торды да, бәйрәм тәмамлангач кына яңгыр сибәли башлады. Ходайның рәхмәте диминни дисең инде моны!

– Туктагыз... Мәктәп дигәннән... И-и, кызларым, иң кирәклесен сөйләргә онытып торам ләбаса! Шагыйребез Хәсән Туфан кереп-чыгып, кунак булып йөргән йорт ләбаса безнең мәктәп!

...Менә шунда инде безнең өчен һич көтелмәгән әр-яңа кыйсса башлана...

Кайчандыр бу бинага киләчәктә атаклы шагыйрь булып танылачак Хәсән атлы егет килеп йөргән...

«Калдыр, йөрәк, онып үткәннәрне...»

– Хәсән Туфанга керешкәнче, авылыбызның мөхтәрәм кешесе Гомәр Усманов турында сөйләргә тиеш булам, – дип дәвам итте Гөлнур апа. – Мин

Шагыйрьнең 1923 елгы фотосы.

бу мәгълүматларны бездән 15 чакрымдагы Казанка авылында яшәүче 90 яшьлек ветеран укытучы Нәркәсападан алдым. Нәркәс апа Гомәр бабайның оныгы, Кайнәт апа кызы була. Ә Кайнәт апа – үз вакытында яшь Хәсәннең йөрәгендә гыйшык уты кабызган кыз!!!

Безнең өнсез калуыбызны күреп, Гөлнур апа яңа дәрт белән дәвам итә:

– Гомәр үзенең гаиләсе белән (хатыны Фагыйлә, уллары Мәлик һәм Рәфикъ, кызлары Кайнәт һәм Сара) 1911 елда Апас районыннан чыгып китеп, Свердловск өлкәсендәге Медный руднигына эшкә килеп урнаша. Үзе бик укымышлы, зирәк һәм искиткеч дини булуы өстенә, күп һөнәрләр белә, оста ташчы була. Медныйда тиз арада эшчеләр арасында хөрмәт казана, алдынгы карашлы яшьләр, хәтта эре промышленниклар белән аралаша.

Революциядән соң алар Төмән губернасы, Велижан өязе, Ахман авылына, ягъни бирегә күчеп киләләр. Гомәр биредә шәп итеп йорт сала, хуҗалык торгыза. Улы Рәфикъ бездән 6 чакрымдагы Усман авылына нигез сала. Шәхси хезмәткә корылган хуҗалык булдыра, тегермән корып җибәрә.

Хәзер төгәл генә әйтүе кыен, күрәсең, каядыр 1918-24 еллар арасында яшь Хәсән-Хисбулла безнең Ахманга килеп чыга. Шагыйрь биографиясендә «1914 елда ул Ахман авылында җир алып урнашкан абыйлары янына барып, бакыр колчеданы руднигында эшли» диелә, әмма бездә бакыр рудниклары юк! Аннары, Хәсәннең Гомәр Усманов гаиләсе белән аралашканы төгәл билгеле, ә алар, әйткәнемчә, безгә революциядән соң гына күчеп киләләр. Хәсән Туфанның яшь чагында, «Галия» мәдрәсәсендә укыганда каникул вакытларында Урал заводларында эшләве, 1918-24 елларда Себер мәктәпләрендә балалар укытуы турында мәгълүматлар бар. Кайнанам авызыннан әллә ничә мәртәбә «аннары авылга Хәсән килде» дигәнен ишеткәнем булды, әмма сүзнең шагыйрь Хәсән Туфан турында барганын белми идем бит! Каршы яктагы йортка күрсәтеп, «Хәсән шунда яшәде» дигәне дә булды. Монда ачыклыйсы нәрсәләр күп, мин бик нык эзләнәм. Кайнәт белән дуслык ничек башланган соң? Нәркәс апа сөйләвенчә, Хәсән Гомәр Усмановның улы Мәлик белән бик дус булган. Ахманга килгәндә үзешчән сәнгатьтә катнашкан, спектакльләрдә уйнаган. Менә яшьләр «Галиябану»ны куярга әзерләнәләр икән, ә Галиябану роленә кеше юк. Хәсән Мәлик янына килгәч, гөлләргә су сибеп йөрүче бик тә чибәр кызны күреп таң кала. Чыннан да, искитәрлек чибәр иде Кайнәт апа! Мәликкә: «Синең бит Галиябану роленә менә дигән сеңелең бар икән, ник аны күрсәтми йөрисең?» – ди. Кыз байтак ялындыргач кына риза була. Әлбәттә инде, Хәсән-Хәлил Галиябану-Кайнәткә гашыйк була.

Себер халкы су коенырга биек ярата. Ахманнар да шулай. Елгабызда Буранкыш дигән урын бар, шунда су коеналар бездә (минем үземнең дә туган авылым Эске суында коена торган урыным бар иде). Бик тә диндар Гомәр бабай, су коеныр өчен, кызларына кеше күзеннән яшерен урын әзерли, куперчек сала. Авылда «Гомәрнең кызлары яшеренеп су коеналар икән» дигән хәбәр тарала. Хәсән өчен дә кызык бит инде бу! Бер дә бер көне ул, фотоаппаратын асып, Буранкышка юнәлә. Теге урынны таба һәм куак артына посып, фотоаппартын көйләп куя. Тирә-як тып-тын. Менә берзаман каршыдагы куаклар арасыннан көймә йөзеп чыга. Көймәдә – Кайнәт. Кинәт, Хәсәннән куркыпмы, балаларын ияртән үрдәк йөзеп чыга. Кайнәт, сискәнеп, торып басарга калкына, һәм шул мизгелдә Хәсән аны фотога төшереп тә ала...

Бу фото Кайнәт апаның гаилә альбомында озак еллар саклана. Әмма ул Казанка авылында яшәгәндә мәктәптә янгын чыгып, мәктәп

тә, Кайнәт апаның өе дә яна, бөтен архивы юкка чыга. Беләсе иде, Хәсән Туфан архивында калмады микән ул фото?

...30-еллар башында Гомәр Усмановлар өчен кара көннәр башлана. Гомәр белән олы улы Мәликне Төмәннең төньягына, Уват районына сөрәләр. Йортларын тартып алып мәктәп ясыйлар (мәктәп бинабыз әле дә исән, Гомәр ясаган йөзлекләренә кадәр тора әле), башка милекләрен туздыралар. Башта Янбай мәдрәсәсен, аннары укытучылар курслары тәмамлаган Кайнәт белән сеңелесе Сара Омски өлкәсенә киткән була, сөрген срогы беткәч, алар әтиләре белән Мәликне үз яннарына алып кайталар. Әниләре Фагыйлә Омск өлкәсенең Ибаркуль (Чибәркүл? — ред.) авылында үлеп кала. Гомәр карт Ахманга кайта, сеңелесе Мәхмүзә тәрбиясендә яшәп, Ахманда бакыйга күчә. Авыл халкы аны бик зурлап соңгы юлга озата.

Кайнәт төрле елларда өлкәнең Тарман, Акъяр, Яңавыл, Ялутор, Аслана авылларында укыта, Хәлил Якубов дигән кешегә кияүгә чыга, дүрт бала таба. 1937 елда Ахманга кайта, аннары безнең мәктәпне Казанкага күчерәләр. Кайнәт апа озак еллар шунда татар теле, химия, биология укыта. Завуч, директор, хәтта колхозда хисапчы эшләрен башкара. Исәпсез-хисапсыз җәмәгать эшләрен тарта. Үзе гомер азагына кадәр Татарстандагы хәлләрдән хәбәрдар булып яши, язучылар белән хатлар алыша. Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен Кайнәт Гомәр кызы Якубова Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Ул 1991 елда 88 яшендә Казанка авылында вафат була.

Гомәр Усмановның балалары: Хәсән Туфанны гашыйк иткән Кайнәт (сулда утырган), Сара, Рәфикъ (сулда), Мәлик.

Гөлнур апа әйтүенчә, Хәсәннең Ахманда туктала торган йорты шушы нигездә булган.

Еллар узгач, Кайнәтнең абысы Мәлик Казанга килгән җиреннән Хәсән Туфан янына керә. Туфан аңа ачылмый, Ахманны искә төшерә башлагач: «Ярар инде, Мәлик, үткәннәрне яңадан актармыйк», – дип кенә куя. Мәликнең бик нык хәтере кала. Менә хәзер, элек яшерен булган фактлар ачыла төшкәч, Хәсән Туфанның ул чакта чишелеп китмәве аңлашыла...

...Алгарак китеп шуны әйтик: без киткәннән соң Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде районында ныклап торып казанлыларның нәсел тамырларын эзләү, Хәсән Туфан йөргән сукмакларны барлау башланды. Димәк, алда безне кызыклы яңа ачышлар көтә дип ышанып калабыз!

...Әлегә без Мәдинә килен белән авылга орынып кына торган урманга юл алдык. Һәм бу сәяхәтебездә Себер урманы серләрен генә түгел, Мәдинәнең теләсә кайсыбызны таң калдырырлык дәрәҗәдә кызыклы һәм бай күңел дөньясын да ачып кайттык. Себер язмаларының дәвамы киләсе санда дөнья күрер.

Самаврлы табыннан башладык...

Октябрь аенда Балтач районы Мәдәнияты йортында яңа иҗат сезоны башлануга багышланган бик матур чара булып узды. Әлеге чараны истәлекле һәм кызыклы итү өчен озак уйландык. Уйлана торгач, без аны «Чәй бәйрәме»ннән башлап китәргә булдык. Әлбәттә, бүген көнкүрешебезгә кыю рәвештә үтеп кергән термопотлар ярдәмендә түгел, ә чын самавырлар белән. Шул вакытта бездә самавырлар күргәзмәсе оештыру хыялы да туды. Тик ул самавырларны каян алырга? 1990-елларда, авыл өйләренә газ тоташтыру сәбәпле, халык тулысынча диярлек чәйнеккә күчте бит. Чорлар дәвамында көнкүрешебезнең аерылгысыз юлдашы булган самавырларның кирәге калмады – аларның кайсы караңгы бүлмәгә, кайсы чормага, кайсы өй асларына күчте. Арада кадере беткән самавырын өйдән-өйгә йөрүче чегәннәргә 1-2 килограмм сары өрек җимешенә алыштырып җибәрүчеләр дә булды.

Әмма, «чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга», дигәндәй, ныклап керешкәч, халыкта әле самавырларның шактый күләмдә сакланганлыгы ачыкланды. Аларның һәрберсе безнең кулга үз тарихы белән килеп керде.

Субаш мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе Фаезова Эльмира, мәсәлән, җирлеккә керүче өч авылны бетереп эзли торгач, Поч-Сосна авылыннан 1 литр су сыешлы бик нәфис самавыр табып алды. Ул Нурлыхода Нәбиеваның әнисе Галиябану Таҗетдиновага (1909 елгы) кияүгә чыкканда Фатыйхов Гарифҗан тарафыннан бирелгән туй бүләге. Самавыр Чепья базарыннан сатып алынган. Аны 1885 елда Грецов М.А. ясаган.

Борбаш мәдәният йорты директоры Хөсәенова Рәзилә:

– Эзләнүләр вакытында нинди генә самавырлар очрамады. Без Борбаш авылында иң зур самавырны сайлап алдык. Аның хуҗасы – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт. «Балалар башлы-күзле булгач, кода-кодагыйлар

да ишәеп китте. Түгәрәк өстәлләребез тагын да зурайды, бәйрәмнәрдә милли татар ашлары белән табын әзерләү, хәл сорашып чәй эчүләр күркәм гадәткә әйләнде. Шулай бер очрашуда күңелемә «безгә зур самавыр җитми икән» дигән уй керде. Әллә уемны сизделәр, әллә Ходайның «Амин!» дигән сәгатенә туры килде, 55 яшьлек юбилеема шушы самавырны бүләк иттеләр. Гомер уртамның якты истәлеге, кадерле бүләге бу», – дип аңлатты Җәлил хәзрәт самавырның йортына килеп керү тарихын.

Сәрдек авыл клубы мөдире Низамова Рәйхана:

– Үзебезнең авылдан җиз самавыр таба алмагач, янәшәдәге 12 йортлы Иске Пукшинер авылына киттем. Булмады бугай инде, дип, соңгы өмет белән ахыргы йортка керсәм, Файзуллин Рамил: «Бар ул миндә, нишлисез аның белән?» – дип елмайды. Күршесе исә: «Саталардыр, бик кыйммәт торалар бит алар», – дип җаваплады. Эшнең нидә икәнен аңлатып, самавырны күтәреп чыгып киттем.

Минем табыш 1893 елда Тула шәһәрендә Алексей һәм Иван Баташевлар тарафыннан ясалган булып чыкты.

Әлеге эзләнүләр нәтиҗәсендә, күргәзмәбездә, көмеш, бакыр, җиз йөзлекләрендә нур балкытып, 40 самавыр «парадка» чыкты. Аларның күбесе музейга куярлык чын сәнгать әсәре иде.

Бәйрәмне агач күмере белән куелган ун литр су сыешлы никель баһадир «ачып җибәрде». Аның көр тавышына берәм-берәм башкалары кушылды.

Зәңгәрсу эскәтерләргә телеңне йотарлык ризыклар – әле генә табадан төшкән коймак, өчпочмаклар, кабак, балан бәлешләре, бөккәннәр, кош теле тезелде. Әлбәттә, иң абруйлы ризык чәй иде. Халыкка копор чәе (Иван-чәй), мәтрүшкә һәм бөтнек, сары мәтрүшкә һәм гөлҗимеш пешереп ясалган чәйләр тәкъдим ителде.

Ике сәгатькә сузылган чәй йоласының дәвамы булып, тамаша залы үз ишекләрен ачты, һәм зур иҗади илһам белән әзерләнгән театральләштерелгән концертыбыз башланып китте.

«Мәңге яшә, сәхнә дигән тәхет!» дип исемләнгән иҗат концертында мәдәният үзәгендә эшләп килүче төрле түгәрәкләрнең эшчәнлеген күреп сокланмаслык түгел иде. «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклор фестивалендә, «Гөслә-фест», «Крутушка» регионара этник фестивальләрдә, «Этномириада» халыкара конкурс-фестивалендә, «Безнең йорт – Татарстан» республикакүләм этнокультура фестивалендә катнашып лаеклы урыннар яулаган «Орчык» гөсләчеләр ансамбле, «Җомга көн кич белән», «Чабата биюе» һәм «Үзбәк биюе» коллективлары, Инструменталь ансамбль, «Ветераннар клубы», «Баянчылар ансамбле», Нәфис сүз һәм Халык театры коллективлары әзерләгән өзек көчле алкышларга күмелде.

Районыбыз мәдәният хезмәткәрләренә, иҗат коллективларына яңадан-яңа иҗади идеяләр һәм аларны тормышка ашыру юлында уңышлар, илһам, дәрт телибез!

Гөлнара Гадел кызы ГАРИПОВА,
«Балтач үзәкләштерелгән авыл клублары челтәре» муниципаль бюджет оешмасы методисты,
Лилия Марат кызы ЗАКИРОВА,
Балтач мәдәният үзәге методисты

Фотода: Яңгул Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ләйлә Габделхакова белән Гөлнара Гарипова.

Гали РӘХИМ

Борынгы төрекләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

«Китабе Коркыт»та һәрбер хикәя халык җырчысы (узан) исеменнән сөйләнә. Бу җырчы хакында «Кулҗә купыз күтәреб илдән илә бәкдән бәкә узан кезер әр җумырдин әр нәкесен узан белүр» («Кулына кубыз тотып, җырчы илдән илгә, бәйдән бәйгә йөри. Ирнең гайрәтлесен һәм куркагын җырчы белә»), – диелә.

Бу хикәяләрнең кайчан ясалуын төгәен әйтеп булмаса да, профессор Бартольд аларның Солтан Баязид беренче заманыннан (1389-1402) да соң җыелмаган (бергә оештырылмаган) булуын дәгъва итә.

Дини буяуга буялган, каһарманы да гарәп булган «Мәнәкыйбе Сәед Баттал» күбрәк гали (олы) сыйныф – баһадир, әмир, солтан, хәлифә, кайсар, вәзирләрнең хәятен сөйләсә, «Китабе Коркыт»та без «чобан» (көтүче) сыйныфында тасвирны күрәбез. Бу сүзебезне исбатлар өчен «Китабе Коркыт»тагы бер хикәянең хөласасын (нәтиҗәсен) алыйк:

«Бер вакытта, үзе юк чакта, кяферлар Казан бәенең йортын талап, аның ун мең куен алып китмәкче булдылар. Коралсыз көтүче (чобан) ике борадәре (бертуганы) белән берләшеп дошманны җиңделәр. Бер вакытны Казан бәй кайтып көтүчене орышырга тотынды. Чобан исә аңа шулай дип җавап бирде: «Бәем, агам, Казан! Нигә миңа ачуланасың! Әллә синең йөрәгеңдә иман юкмы? Алты йөз кяфер минем өстемә килделәр. Минем ике кардәшем дә үлделәр. Мин өч йөз кяферне үтердем һәм аларга синең симез куйларыңны бирмәдем. Өч урыннан яралы булдым. Минем кара башым бөгелде. Мин ялгыз калдым. Минем гаебем шундамыни? Бир син миңа күк атыңны, бир озын сөңге, бир ак калкан, бир кара булат, бир үзеңнең калчаныңнан уклар, бир каты җәя – мин аларны үтерермен, үземнең арка һәм йөземнән кан агызырмын!» Казан ачуланып китте. Чобан да аның артыннан китте. Бераз баргач Казан аңа әйләнеп әйтте:

– Кая барасың син, углым чобан?

– Агам, Казан! Син йортыңны алыр өчен барасың, мин үз кардәшләремнең үчен алыр өчен барам.

– Углым, чобан! Ач мин, синдә ашарга бер-бер нәрсә юкмы?

Чобан бәйне туйдырды. Соңра Казанның башына шундый уй килде: «Әгәр мин көтүче белән бергә барсам, башка угыз бәйләре мине сүгәрләр һәм чобаннан башка Казан кяферләрне җиңә алмас иде, диярләр». Шуннан соң Казан көтүчене бер агач янына чакырып китереп: «Бу агачны тамыры белән алып ташла. Әгәр шуны эшләмәсәң, сине бүреләр һәм кошлар ашарлар», – диде. Көтүче агачны тамыры белән алып, аркасына күтәреп, Казан бәенең артыннан йөгереп куып җитте. Казан сорады:

– Бу нинди агач, чобан?

– Агам, Казан! Син кяферләрне җиңәрсең, карының ачар. Бу агачны яндырып, мин сиңа аш пешерермен.

Казанга бу җавап бик ошады. Кяферләрне җиңгәч, Казан көтүчене зур дәрәҗәле кеше ясады».

Менә мондый халык хәятен тасвир иткән хикәяләрне без сугыш китапларында бик сирәк очрата алабыз.

Әсәрдә дини фанатизм да ул кадәр күп түгел. Мондагы сугышлар да күбрәк кяферлар белән булса да, борынгы төрекләрдә булганча, сугышның үзенә табыну әсәре дә бар. Сугыш эшендә үзен күрсәтеп ат казанмаган егеткә Коркыт бабай бер вакытта да ат кушмый. Егетләр исем алыр өчен «баш кисәргә, кан түгәргә» тиешлеләр. Коркыт китабындагы каһарманнарда исламга мәхәббәт тә алай ук юк. Мәсәлән, атасыннан разый булмаган угыл яисә ханнан нәразый (риза булмаучы) бәй һәрвакытта: «Христианнар арасына китәрмен, аларның кулын үбәрмен», – дип куркыта. Батырлар дуңгыз ите ашамасалар да, аракыны бик сөеп һәм ачыктан-ачык эчәләр. «Китабе Коркыт»та иске төрекләрнең мәҗүс гадәтләре дә очрый. Без анда бөтен төрек халыкларында изге хисапланган «күрд» (бүрене) хөрмәтләүне күрәбез. Мәсәлән, бер урында: «Күрд йөзе мөбарәк», – диелә. Шулай ук: «Хәсән илә Хөсәеннең хәсрәте – су, Гайшә илә Фатыйманың нәкяһы (үлүе) – су», – дигәннән мөселман изгеләре белән бергә мөкаддәс (изге) суга да хөрмәтне күрәбез. Шулай ук Деле Дөмрел, ант иткәндә, гареш, көрси белән бергә: «Җир таныкбулсын! Күк таныкбулсын!», – дип төрекләрдә мөкаддәс булган җир һәм күкне гуаһлыкка (шаһитлеккә) чакыра.

«Китабе Коркыт»та без Гареб (көнбатыш) рыцарьләрендәге хатын-кызны хөрмәтләүне дә очратабыз. Хикәятләр эчендә Деле Дөмрел исемле бер батырның үлем фәрештәсе Газраил белән көрәше хакында хикәя бар. Сугышның ниһаятендә, Газраил җиңеп, Дөмрелнең күкрәгенә менеп утырып, җанын алмакчы була. Дөмрел, Тәңрегә мөрәҗәгать кылып, котылдыруны сорый. Дөмрелнең сүзе Тәңрегә хуш килеп әйтә: «Я, Газраил, Деле Дөмрел җаны җиренә җан булсун (тапсын). Анун җаны азат улсун», – ди. Дөмрел карт атасы белән карчык анасына: «Минем өчен җаныгызны бирегез», – дип мөрәҗәгать кыла. Ләкин Дөмрелгә атасы да, анасы да бер бәһанә (сәбәп) табып, җаннарын бирмиләр, «Җан газиз», – диләр. Өметен кискән Дөмрел хатыны белән күрешергә генә миһләт (кичектерү) сорап: «Яд (ят кеше) кызы хәләлем (хатыным) вар, андан минем ике угланҗыгым вар, әманәтем вар асмарларым (тапшырам) анларә, андан соңра минем җаным аласын!», – ди. Шуннан соң ул: «Хәләле янына килде, әйдер, билүрмисен нәләр улды: күк йөзендән ал (кызыл) канатлу Газраил очыб килде, агҗә минем күксеме (минем ак күкрәгемә) басуб кунды, тынлу минем җанымны алур улды. Бабама (атама) вир дидем җан, вирмәде, анама вардым, җан вирмәде, дөнья ширин (дөнья татлы) [...]».

«Китабе Коркыт»ның телендә игътибар итәргә тиешле нокта – асылда җәнүб (көньяк) төрекчәсе булуы белән бергә анда башка төрек телләре (мәсәлән, татарча) белән уртак сүз һәм сарфи (морфологик) формаларның очравыдыр, хәзерге әдәби госманлыча да алар урынына башка сүзләр һәм формалар истигъмаль ителә.

Борынгы төрек халык әдәбиятында гадәттә була торган һәртөрле төрләр: баһадирлар дастаны (богатырский эпос), әкиятләр һәм риваять (легендалар), көлке анекдотлар һәм мәсәлләр, табышмаклар, мәкальләр һәм сүз җилемнәре, җырлар, шаман теләкләре һәм тылсымнары, хәтта ибтидаи драматик әсәрләр – әлбәттә, һәркайсы булгандыр.

Төрек халыклары шикелле күчмәле һәм сугышчан халыклар арасында һәрвакыт баһадирлар дастаны (хыялый яки ярым тарихи батырларның каһарманлыклары хакындагы поэмалар) халык әдәбиятының иң көчле һәм таралган бүлекләреннән була. Хәзердә дә әле без борынгы замандагы төсле тормыш белән тора торган төрек кавемнәрендә бу нәүгъ (төр) әдәбиятның куәтле булганын күрәбез. Мәсәлән, хәзерге кара кыргызлардагы Манас исемле батыр хакындагы дастаннарны бу төрле (төр) әдәбиятның иң яхшы нәмунәләреннән (үрнәкләреннән) хисапларга мөмкин. Аның башыннан үткән төрле вакыйгаларны сөйли торган җырлар озын бер тезмә (бер группа) тәшкил итеп, җырчы «акын»нар тарафыннан бәгъзән озайтылып, бәгъзән кыскартылып, төрле калыпларга сугылып җырланалар. Әле күптән түгел генә күчмәле, сугышчан халык булган башкортларда, әле дә булса, ярым тарихи, ярым хыялый батырлар хакындагы дастаннарның калдыклары сакланып, карт бер йырчылар тарафыннан көйләнәләр*. Менә шуларга кыяс (охшатып) караганда, борынгы төрекләрдә баһадирлар дастанының бик нык хөкем сөргәнлеген чамаларга мөмкин. Сугыш һәм баһадирлар бөтен идеалын тәшкил иткән халык өчен батырлар хакындагы әдәбиятның иҗтимагый әһәмияте дә була: үтмештәге (элекке) батырларның батырлыкларын тыңлау яшь сугышчыларның канын кыздыра, гайрәтләрен арттыра, дастандагы батырлар төсле булырга кызыктырадыр. Борынгы угыз төрекләренең дастаннарыннан бер кадәресе югарыда сөйләнгән «Китабе

Коркыт»та сакланып калган. Ләкин андагы дастаннар нәсер белән язылган[1]. Гадәттә исә баһадирлар дастаны, күбесенчә, көйле формага салынган була.

Борынгы төрекләрдәге әкияткә килсәк, аларның электә ничек булганын без белмибез; чөнки төрек әкиятләре борынгы заманда язылып алынмаганнар. Ләкин халык әдәбиятында әкият кыйсеменең (өлешенең), гомумән, бик мөхафәзәкар (саклаучы) бер гонсыр булып, күп әкиятләрнең бик аз гына үзгәреш белән борынгы заманнардан бирле сөйләнеп килүләрен чамаларга мөмкин. Борынгы көлке анекдотлардан бер кадәресе, шактый заман элек язылып алынганга, бераз мәгълүм. Ул да булса Хуҗа Насретдин латыйфәләредер. Аның хакында әсәребезнең икенче бүлегендә озын сөйләнәчәк. Табышмаклар һәм бераз мәкальләр исә «Команмәҗмугасы» [дип] аталган 14 нче гасыр кульъязмасында сакланып калган[2].

Бу хакта беркадәр мәгълүмат һәм мисаллар шул ук бүлектә бар.

Гомумән, күчмәле халыкларда лирика эпоска (риваяге) караганда түбәнрәк, арт пландарак тора. Төрек халкы исә авыр, сабыр табигатьле бер халык булып, аның торган төп ватаны да каты табигатьле, могтәдилдән (уртачадан) салкынрак җирләр булганга, лирика тудырырга артык мөсәгыйд (уңайлы) булмагандыр. Шулай да төрек халкы үзенең кайгы-хәсрәтен, куаныч-сөенечен, гыйшык-мәхәббәтен һәрвакытта җыр белән сөйләргә яраткан. Моны безгә хәзерге кыргызларның һәм шәркый Себер төрекләренең җырлары бик ачык күрсәтәләр; әмма сәлҗүк, госманлылар шикелле җылы һавалы, матур табигатьле мөнбит (уңдырышлы) җирләргә килеп утырганнары исә бу төр әдәбиятны тагы да тәрәкъкый иттергәннәрдер (үстергәннәрдер). Госманлыларның хәзерге халык әдәбиятлары шуны күрсәтә.

Шаман диненең догалары булган теләкләр һәм һәртөрле серле җөмләләрне, имтом иткәндә, кеше һәм мал эченә урнашкан явыз көчләрне (рухларны) куганда укыла торган вәзенле (ритмлы) сүзләрне дә халык әдәбиятыннан хисаплыйлар. Шаман динендә булган халыкларда бу төрле (төр) «әдәбият» бик куәтле булганга, борынгы төрекләрдә ул хәзергегә караганда да киңрәк булгандыр, дип уйларга мөмкин. Кыргыз-казакъ баксыларында җен һәм авыру куалый торган, тасвири һәм матур телле арбауларның булуы безгә шуны күрсәтә.

Хәтта безнең Идел буе татарлары арасында да бик иске (архаик) телле, бәгъзән аңлашылмастай сүзләр һәм әллә нинди борынгы рух һәм тәңре исемнәре белән тулган имләү сүзләре сакланып калгалаган.

Драматик (ягъни диалоглы, кара-каршы әйтешә торган) әсәрләр булса, алар халыкта күбрәк бик садә (гади), бездәге шамакай уеннары «алырым кош – бирмәм кош», «күктә, күктәниләр бар» уеннарында әйтелә торган сүзләр шикелле генә нәрсәләрдер. Мондый уеннарның хакы да тәрәккъый итә төшкәннәренең Анатолийда госманлыларда һәм хәзерге кыргызлар арасында саклап калуы моның бер әдәбият һәм сәнгате нәфисә (нәфис сәнгать) тармагы булганлыгын күрсәтәдер.

Утраклыкка күчү, язу сәнгатенең таралуы, дин һәм аның руханилары тәэсире белән бара торгач, төрек халыкларында халык әдәбияты кимергә тотынды. Яңа шәраит (шартлар) астында халык, акрынлап үзенең идеологиясен үзгәрткәне шикелле, әдәбиятын да алмаштыра, үзгәртә башлады. Әүвәлге мәҗүс каһарманнары – Гали, Хәсән, Хөсәен мөселман изге һәм батырларына әйләнделәр. Әүвәлге шаман догалары мөселман диненчә булган төрки догаларга алмаша башладылар. Тәңреләр Аллага һәм мөселман изгеләренә әверелделәр; шаманның ролен дә мулла алды. Кыргызлар әйтмешли, «кара сүзләр» бетә башлап, «китап үлән»гә әйләнделәр. Ләкин төп, әсаси аһәң (нигез аһәңе) калды. Халык арасына таралган төрле мөселман хорафаты, легенда һәм әкиятләре үзләре акрынлап тәмсил ителделәр (ассимиляцияләнделәр), төрекләштеләр. Язма әдәбият куәтләнгәнче, матбугат туганчы, халык әдәбиятының эволюциясе менә шулай барды.

(Җәяләр эчендәге аңлатмалар филология фәннәре кандидаты Айдар Гайнетдиновныкы)

---

* Башкортлар үзләре моңа шулай диләр.

[1] В.М. Жирмунский, «Коркут Китабы»ның сәнгати формасын анализлаганда, анда «угыз» былиналарга хас булган прозаик хикәяләр һәм көйләп сөйләнә торган өстәмәләр белән чиратлашуы турында әйтә. (Кара: Жирмунский В.М. Огузский героический эпос и «Книга Коркута»// Книга моего деда Коркута. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1962. – С. 143-144).

[2] Кодекс Куманикус (лат. Codex Cumanicus) – XIV гасыр башына караган (1303) куман телендәге язма әсәр. Ике бүлектән – италия (латин-фарсы-куман сүзлеге) һәм немец (куман-алман теле сүзлеге) – торган кульъязмада якынча кыпчак теле грамматикасына бәйле мәгълүматка (фигыль төрләнешләре, алмашлыкларның, сыйфат, исемнәрнең төрләнешләре һәм үзгәрешләре) ия булгаи 1300 сүз тупланган. «Кодекс»ка 47 төрки табышмаклар җыентыгы кертелгән.

Чыганак: Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр. – Казан: «Ихлас» нәшрияты, 2018, 192-204 битләр.

Куш тирәк

Әй, ишеккәем алды, әй, куш тирәк,
Әй, куләгәсе төшә баксага.
Әй, бәхеткәйдәрең, әй, булмаса,
Әй, сатып алып булмай икән аксага.

Әй, Агыйделкәй буйы йөрегәндә,
Әй, бер таш табып алдым беләүгә.
Әй, хәсрәткәемде сөйләрийем,
Әй, үдем кешек тагын бирәүгә.

Әй, Агыйделкәй буйы тугайдарда,
Әй, туры ла басып килә йургалар.
Әй, күддәремде тутырып карар ыйым,
Әй, арабыдда киң-киң дәрйәлар.

Әй, ишеккәем алды, әй, бер түңгәк,
Әй, түңгәккәйе тулы йер йеләк.
Әй, йелкенә лә минең, әй, йәш йөрәк,
Әй, йелкенгәндә, миңә син кирәк.



Чиләбе өлкәсе, Кошак районы, Кошак авылында яшәүче Хәбибуллин Хәбибрахманнан (1911 елда туган) 1966 елда Фәрит Юсупов тарафыннан язып алынган. Бу жыр шулай ук Чиләбе өлкәсенең Кошак районына күрше булган Аргаяш районы, Колай авылында яшәүче Мәһинур Шәимовадан (1905 елда туган) язып алынган. Кара: Башкорт халык авыз ижады: йырзар, көйзәр. – Өфө: Башкортстан китап нәшрияты, 1983,74 бит.

Нурихан ФӘТТАХ

Сызгыра торган уклар

(Романнан өзек)

Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме

Елдырым бәк урдасы Күник карт авылыннан әллә ни ерак түгел иде. Урдага барып җитәргә бер-ике чакрым кала юлчыларны Бавыр көтеп тора иде.

– Хәбәрне әйттем, сезгә шушыннан ары бармаска кушылды, – диде ул кияү буласы кешегә.

Албуга үзенең алаена шунда туктап авыл корырга боерды. Туктау белән берәүләр төргәкле киезләрен сүтеп җиңел өй торгыза башладылар, икенче берәүләр атлар белән булашты. Туктаусыз чабып килгән атлар бик өшәнгәннәр иде. Атларны тиз генә утларга җибәрмәделәр, – кисәк кар ашап эчләренә салкын төшмәсен, авырмасыннар өчен аларны, өсләренә киез эчмәкләр каплап, шактый озак суытып тордылар. Ике-өч сәгать ач тотып суыткач кына аларны кешәнләп, тибенгә җибәрделәр. Атлар ашыгып куе үлән катыш кар кимерделәр – суы да, азыгы да бергә булды...

Кияү бүген кыз янына урыйн туйга бара иде. Туктау белән ул салкын өйдә үзенен юл киемнәрен алыштырды, аннан соң үзенең егетләренә бүләкләр өләште. Елдырым бәк кызына хәбәр алып барган, далада үзен каршы алган Бавырга кияү беренче бүләкне бирде. Бер савыт ук белән яхшы җәя күреп, Бавыр куанычыннан телсез өнсез калды. Юка сөякләр белән нygытылган, үгез сеңере, балык җилеме белән катырылган алыплар җәясен ул соңгы көннәрендә инде төшләрендә күрә башлаган иде.

Кыз янына барганда Албуга үзе белән егетләрнең бары уникесен генә – өйләнмәгәннәрен генә алды. Монда авылда калачак егетләргә, ирләргә баш итеп ул Тишек-Ташны билгеләде. Атларны, өйләрне бүген төнлә бик уяу сакларга кирәк булачак иде. Ник дигәндә, «дошман» яшьләре бүген аларга каршы теләсә нинди этлек ясарга мөмкиннәр иде.

Елдырым бәк урдасыннан бер чакрым чамасы читтә, бар ягы да ачык дала уртасында ялгыз өй корып куелган иде. Бу өйне әлерәк кенә – кияү килере турында хәбәр алынгач кына корып куйганнар иде. Кияүне, кияүегетләрне Бавыр туп-туры менә шул өйгә алып барды. Еракта өй күренү белән, кылавыз кире борылды. Ул кияү-егет түгел иде, шунлыктан аңа анда барырга ярамый иде. Кире озатканда Албуга аңа тагын ук тулы бер садак бүләк итеп бирде.

Бавырдан аерылгач, як-ягына карана-карана ул үзе генә китте. Кияү-егетләр, кияүдән бераз калышып, шулай ук якякларына каранып, әкрен генә арттан бар-

Кем без? Нинди кавем, нинди халык? Кайдан киләбез, юл башыбыз кайда? Каныбызда кайнаган дәрт, ашкыну, сагыш кайсы чорларның кайтавазы? Бу сораулар уйлана белгән бер генә кешене дә битараф калдырмаса да, әлеге сорауларга җавап эзләп, «энә белән кое казучылар» бик сирәк.

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе Нурихан Фәттах (1928–2004) нәкъ менә, тирән тамырларыбызны актарып, энә белән кое казучыга тиң. Аның тарихи романнарында сурәтләнгән чорларны җанландыру өчен никадәр чыганакларны табарга, анализларга кирәк бит! Ул чыганаклар белән эш итү өчен төрки телләрне, гарәп-фарсы, кытай телләрендәге үзенчәлекләрне чамалау кирәк. Ә бит Нурихан Фәттахның әсәрләрендә халыкның бөртекләп сурәтләнгән көнкүреше, йола-гадәтләре шулкадәр тере-җанлы, шулкадәр ышандыра, син үзеңне шул чорның эчендә итеп хис кыласың. Аның асылыбызны эзләп, тарихыбызның ерак төпкелләренә төшкән әсәрләре бик күпләрнең офыкларын киңәйтте.

Әдипнең 90 еллык юбилеен билгеләп үткән көннәрдә, Нурихан аганы яд итеп, укучыларыбызга «Сызгыра торган уклар» тарихи романыннан бер өзек тәкъдим итәбез. Анда безнең эрага кадәр хәзерге Монголия, Төньяк Кытай җирләрендә яшәгән борынгы төрки кабиләләрнең тормышы тасвирлана. Һәм ул тормыш безгә бик якын кебек...

дылар. Бу тирәдә кияү кешегә аеруча сак, уяу булырга кирәк иде.

Албуга Бавырдан аерылып бер йөз адым чамасы да китәргә өлгермәде, аты кинәт өркеп читкә сикерде. Албуга, ияреннән ычкынып, чак-чак кына җиргә мәтәлеп төшмәде – ярый әле аяклары өзәңгегә эләгеп калды. Иияр өстеннән инде егылып төштем дигәндә генә ул җир өстендә ниндидер карачкы күреп калды. Карачкы, бик җитез ыргылып, атның тезгенен тотып алды. Кияү ияренә кире җайлап утырды да бар көченә тезгенне үзенә тартты. Ләкин карачкы да ычкындырырга уйламады. Албуга аңа камчы белән сыдырмакчы булган иде, шулай да вакытында тыелып калды. Ачуын йотып ул бил каешындагы янчыгына үрелде. Аннан ефәк чүпрәккә төрелгән ниндидер каты нәрсә – таштанмы, алтыннанмы ясалган бизәнү әйбере алып, карачкыга:

– Мә, ал да шуны, юлыңда бул! – диде.

Атның тезгенен тотып алган карачкы көлүгә охшаш ниндидер өн чыгарып читкә тайпылды. Ул китү белән Албуга артыннан аның егетләре килеп җиттеләр. «Ярый әле, җиңел котылдым!» дип уйлады яшь кияү. Ләкин шул ук мәлдә каяндыр аяк астыннан дәррәү кубып, бер төркем кызлар килеп чыкты. Казлар сыман кыйгаклап кычкырган яшь кызлар, чыр-чу килеп, көлешеп, шаулашып, кияүне иярдән үк тартып төшерделәр – шаярып, әрсезләнеп аның биләгенә асылындылар, бил каешына тотындылар, бүләкләр салган янчыгын чишмәкче булып азапландылар. Кызларга әсир төшкән кияүне кияү-егетләр араламакчы булып карадылар, ләкин кызлар күбрәк иде, шаянрак, чаярак иде – кияү-егетләрне дә алар берәм-берәм атларыннан өстерәп төшерделәр. Атларны исә камчы белән сыдырып, һай-һулап далага кудылар.

Авылдан, урдадан читтәге ялгыз өйне, атаанага «әйтмичә», «качып-посып», яшь кызлар, яшь хатыннар корган иде. Киезләрне, кирәгәләрне, өй өчен кирәк булган барлык нәрсәне алар үзләре күтәреп алып килгәннәр иде. Хәзер алар менә шуның өчен кияүдән бүләк дауладылар. Билендәге авыр янчыгын кияү кулына алды. Кызларның берсенә ул беләзек, икенчесенә муенса, каптырма ише нәрсәләр бирде. Бүләген биргәндә кызларның әле кулына, әле беләгенә орынып алды, кайберсен шаяртып кочып алды, кайберсенең тун чабуын күтәрде. Кызларның шаяруларына кияү үпкәләмәгән кебек, аның шулай кул озайтуына да кызлар үпкә белдермәделәр. Киресенчә, кияүдән бүләк алган, тәненә кияү кулы тиеп киткән кызлар, ышану буенча, быел ук кияүгә – һичшиксез, бай кияүгә! – чыгачаклар иде...

Бу кызларның, хатыннарның барысы да Алтын-Бөртекнең апалары, сеңелләре һәм җиңгиләре иде. Элеккерәк елларда күргән чакларда алар бер дә алай шаян-усал түгел кебекләр иде. Баксаң, әнә нинди икән алар!

Кызлар җитәкләп, көлеп-шаярып кияүне ялгыз өйгә алып килделәр, ишекне ачтылар да барысы да як-якка тайпылдылар. Өй эче караңгы иде. Албуга керергәме-кермәскәме диебрәк торганда, кемдер шунда арттан төртеп җибәрде. Кияү, кыюланып, серле караңгылыкка атлады. Ләкин беренче адымыннан ук аяк астындагы нәрсәгәдер абынып китте, чайкалып китте. Егылмас өчен ирексездән ишек яңагына тотынды.

– Ух, үләм! – диде аяк астындагы кемдер бик каты ыңгырашып.

Тиз генә иелеп кияү аны күтәреп торгызмакчы булды.

– Ни булды? – диде ул.

– Үләм! Башыма таш төште! – диде идәндә, ишек төбендә яткан ниндидер хатын-кыз.

– Нинди таш?! – диде кияү шаккатып.

Якында гына тыңлап торган кызлар, яшь хатыннар бөтен даланы яңгыратып көлеп җибәрделәр. Шул ук мәлдә «үләргә яткан» хатын-кыз ике куллап кияүнең тун чабуыннан эләктереп алды.

– Бүләк! Бүләгеңне бир! – диде ул усал ысылдап, тешләрен шыгырдатып.

«Тагын бүләк!» дип уйлады кияү, шундук янчыгына тотынып.

– Саранланма, кыз янына җиңел генә керә алмассың! – диде идәндәге хатын-кыз.

Албуга бүләк биреп түргә узды. Ул арада өйгә кызлар кереп тулдылар, учактагы утны дөрләтеп җибәрделәр. Өй эче яктырып китте. Идәнгә ак киез җәелгән, киез өстенә, түргә, биек агач ятак куелган иде. Ятак өстендә, кабартылган ястык, мендәрләр арасында, яшел ефәк бөркәнеп, тып-тын гына кемдер утырып тора иде. «Алтын-Бөртек!» дип уйлады кияү, әледән-әле шул якка каранып. Аның тизрәк кызның бөркәнчеген ачасы, кәләшенең тулган айдай сылу йөзенә карап сокланасы килде. Ятак янына сакка баскан кызлар аны анда якын да җибәрмәделәр.

– Уф! Үтерәсез инде сез мине, кызлар! – дигән булды кияү зарланып.

Кызлар аны үтермәделәр, киресенчә, үлмәсен өчен аш-су әзерли башладылар – шундук киез уртасына ашъяулык җәйделәр, күп итеп табак-савыт китереп куйдылар. Аулак өйдә хәзер урыйн туй башланырга тиеш иде.

Кияү өчен түргә, ятак янына калку, йомшак урын җәйланды. Кияү утырасы урынның сул ягына, киез өстенә тезелеп кызлар утырды, уң ягына аның егетләре урнашты. Үзара такмаклар, тапкыр сүзләр әйтешеп яшьләр берберсен күзәттеләр, көлделәр, шаярдылар. Кияү ишектән кергәндә бусагада сузылып яткан хатын-кыз яшьләр арасында иң өлкәне иде. Табын әзерләү, утырышу – барысы да аның җитәкчелегендә, аның күзәтчелегендә башкарылды.

Табын әзерләнеп беткәч, гел елмаеп торган кысык күзле, ачык, ягымлы йөзле бу өлкән хатын Албуга янына килде. Бу вакытта кияү, үзе өчен җәйланган урынга да утыра алмыйча, кәләшенең йөзен дә күрә алмыйча, бер читтәрәк таптанып тора иде.

– Кияү! – диде хатын, Албуганың кулыннан тотып алып.

Барысы да тынып түр якка – кияү белән әлеге җиңги ягына карадылар.

– Ерак юл килеп син бик ачыккансың – эчең эчкә ябышкан, хәлсезлектән әнә кулларың калтырый, – диде җиңги, кысык күзләре белән генә елмаеп.

– Минем кулым хәлсезлектән калтырамый, җиңги. Минем йөрәгем ашкынып тибә – шуңа калтырыйдыр ул, – диде кияү оста телләнеп.

– Шулаен шулайдыр да, табындагы азыкларга ач бүредәй карыйсың, кияү, – диде җиңги.

– Сүзең хак, җиңги: мин ач бүре кебек сусадым, зарыктым. Бер кашык суга салып йотардай булдым гүзәлем Бөртегемне! – диде кияү чиктән тыш остарып.

Шулай дип әйтү белән, ул җиңгинең сузылган ак, матур кулына алтын алкалар салды. Ул шулай ук ятак янында «сакта» торган кызларга да бүләкләр бирде дә, чак-чак кына каушап, кызарып, үзенең Алтын-Бөртегенә якынайды, җиңги белән кызлар читкәрәк киттеләр.

– Яшь танамны бер ел күргәнем юк, байталымны бер ел тотканым юк! Аккошымны кемнәр ябып куйган? Ватам-кырам читлекләрен – чык иреккә, ташлан минем кочагыма, тутый кошым! – дип сөйләнә-сөйләнә кияү калтыранган куллары белән ефәк бөркәнчекне ачып җибәрде.

Ачып җибәрде һәм... чак-чак кына артына авып китмәде. Ефәк бөркәнчек астында аның «тутый кошы», «аккошы», гүзәл Бөртеге түгел, бәлки йөзен җыерчык баскан, тешләре төшеп, ияге шөшледәй очлаеп калган бер кортка утыра иде.

Шаян җиңги кияүне шундук арттан кочып алды, аны юри шап иттереп артына утыртты. Яшь кызлар, киресенчә, сикереп торып аны аягына бастырдылар. Кияү, ятак ягына борылып карарга да җирәнеп, сүзсез генә як-якка күз йөртеп чыкты. Әллә шунда берәр җирдә посып торамы соң аның ярәшелгән кызы?

– Эзлә, эзлә! – дип кычкырдылар усал кызлар, көлә-көлә.

Бөтен өй эче ду килеп торды. Кызлар, егетләр, бар нәрсәләрен онытып, бөгелә-сыгыла көлделәр, эчләрен тота-тота көлделәр. Ятак өстендә тыйнак кына утырып торган тешсез кортка да кеткелдәде. Яшь чакларын искә төшереп көлдеме ул, әллә соң башкаларга күңелле булган кебек, аңа да бу аулак өйдә бик күңелле иде микән?

Албуга түгәрәк өйне бер-ике мәртәбә әйләнеп чыкты да башкалар кебек үк көлә-көлә түргә, калку урынга килеп утырды. Алтын-Бөртек әле монда булмаска тиеш иде. Кинәт ул шуны төшенеп алды. Үзенең җиңел генә алдануы өчен аңа бик уңайсыз булып китте. Ләкин шул чаклы кызлар янында аңа һич тә күңелсез түгел иде.

Ашаганда шау-шу басыла төште. Кызлар «урлап» өйләреннән төрле тәмле азыклар, эчемлекләр – ит, каймак, эремчек, көлчә, кымыз ише нәрсәләр алып килгәннәр иде. Егетләр чыннан да ач бүреләр кебек ашадылар – алларына куйган бар нәрсәне ялт итеп кенә тордылар. Кызлар үзләре бөтенләй диярлек ашамадылар – бары кияү белән егетләрне генә сыйларга тырыштылар. Шулай бераз тамак ялгап алгач, барысы да дәррәү кубып, шаулашып тышка чыктылар. Албуга берүзе бер өйдә, учак янында утырып калды.

Кызлар, Алтын-Бөртекне «урларга» дип, Елдырым бәк урдасына киттеләр. Кызны «урлау» кыен булмады. Ата-анасына «сиздермичә», күзен бәйләп, баштанаяк бөркәндереп аны туп-туры бәкнең биек ак өеннән алып чыктылар да капка каравылы яныннан үттеләр һәм «кача-кача», «курка-курка» ачык даладагы аулак өйгә таба йөгерделәр. Өйгә килеп җитәрәк кызларга кияү егетләре «һөҗүм итте». Алтын-Бөртек өчен ике арада кыска гына «яу» булып алды. Кызлар җиңелде, кәләшне егетләр әсир төшерделәр. Кечкенә дүрткел киезгә утыртып, киезнең дүрт ягыннан күтәреп тоткан хәлдә, Елдырым бәк кызы Алтын-Бөртекне егетләр үзләренең бәкләренә алып килделәр. Ялгыз өйдәге кияү янына кызны шулай кул очларына күтәргән килеш алып керделәр. Алып кереп, аның каршысына, йомшак киезгә утырттылар да шундук кире чыгып та киттеләр.

Аулак өй янында яңадан күңелле шау-шу башланып китте. Төне буе далада яшьләрнең шат тавышлары, җырлары, такмазалары ишетелеп торды.

Кияү кызга үзе белән алып килгән бүләкләрен бирде. Кыз исә аны моннан бер ел элек чит ил сатучыларыннан алып калган һәм бары шушы көн өчен генә сакланып тотылган ят җимешләр белән, ит, кымыз, каймак белән сыйлады.

Алтын-Бөртек бар нәрсәгә исе китеп карый торган зур күзле, ак битле, таза, буйчан бер кыз иде. Күрешми торган бер ел арасында ул тагын да тулыланып, матурланып киткән иде. Тартынып кына кияү аның кара кашларына, ак кулларына карады. Кызның бар җире килешле, ягымлы һәм тансык иде. Аның юка йон киемнәреннән татлы исләр килә иде. Тик шулай да кияү кешегә бу таза гәүдәле, эре сөякле кыз янында бераз гына кыен, уңайсыз булды. Бик якын утырса да, ул аңа ничектер чит тоелды. Чин кызы Сөенечтәге кебек анда бер күрүдә бөтен тәнгә ут кабыза торган әчке дәрт тә, ялкын да юк иде кебек.

Аулак өйдә беренче очрашу, танышу бик кыска булды. Сиздермичә генә ишек ярыгыннан күзәтеп торган җиңги, яшьләрнең үзара сөйләшер сүзләре беткәч тә, кояштай балкып, җилләнеп өй эченә килеп тә керде. Килеп керде дә әле кияүгә, әле кәләшкә ипләп кенә сүз кушкан булды, ашарга-эчәргә кыстаган булды. Мондый эштә тәҗрибәле кеше буларак, яшьләрнең сүзсез-хәрәкәтсез утырып, бер-берсенә карата суынуларына ул юл куя алмый иде, билгеле. Чыннан да, җиңгәсе кереп уңайсыз тынлыкны бозгач та, Алтын-Бөртек җанланып китте.

– Кайтыйк инде, әти-әни югалтып ятадыр, – диде ул җиңгәсенә эндәшеп.

– Кайтырбыз. Таң атканчы утырмассың монда чит кеше янында, – дигән булды җиңги дә җиңелчә генә, артык хафаланмыйча гына.

– Нинди кайту ди ул! Кайтмагыз әле! – диде Албуга, кызның кулыннан тотып.

Кыз, йомшак кына каршылык күрсәтеп, кулын тартып алды, аягына басты. Кияү дә торды, кызның юлына аркылы төшмәкче булды. Җиңги кеше икесенең дә арасына керде дә бик тә ягымлы итеп, күңелләргә төшеп:

– Бүгенгә җитеп торыр! – диде.

Кызлар Алтын-Бөртекне атасы өенә алып кайтып киттеләр. Кысык күзләре гел елмаеп торган ягымлы җиңги табак-савыт

җыештырган булып, өйдә калды. Сиздермичә генә ул кияү-балакайны күзәтте. Нindирәк ул? Кызны яратамы, яратырмы? Холкы нинди — артык җебегән яисә, киресенчә, усал, холыксыз түгелме?

Албуга аның үзен күзәтүен бөтенләй сизмәде. Ул башын иеп сүзсез генә утырып торды. Аның бик нык сөмсере коелган иде.

Хәйләкәр җиңги табак-савытларын җыештырды да китәргә әзерләнә башлады.

— Тыныч йокы, тәмле төш, кияү-балакай! — диде ул ярым шаяртып.

Бары шунда гына кияү-балакайның йокысы ачылып китте.

— Туктале! — диде ул, җиңгинең кулыннан тотып алып, — ни... ничек соң? Нишләп болай булды әле бу?

— «Ни»мени? — диде җиңги көлеп. — Башта ук шулай диләр аны! Җиңгәң белән бер сердә булсаң, уңмый калмассың.

Бүләкләр тутырылган зур гына капчыгыннан Албуга хатын-кыз туны тартып чыгарды. Кеш тиресеннән тегелгән юка, җиңел тунны ул җиңгинең иңбашына салды.

«Качып-посып» кына алар Елдырым бәк урдасына киттеләр. Анда, бәкнең зур, биек өендә, ишектән кергәч тә уң якта калын киез белән бүлеп куелган бүлмәдә кияү белән кыз өчен күптән инде урын җәелгән иде. Ят өйнең бусагасын атлап кергәндә ишек сакчысы кортка «йоклап» калды, ләкин кияү аның янына үзенең бүләген калдырды. Өй эчендә ата-ана шулай ук берни белми «йоклап» ятты.

Кияүне таң атканчы уяттылар. Ата-ана күргәнче аны тизрәк өйдән чыгарып җибәрделәр дә даладагы аулак өенә озатып куйдылар. Боларның барысын да шул ук җиңги башкарды.

Таң атып көн тугач, Елдырым бәк янына кияү ягыннан кодалар китте. Алар арасында Адай да бар иде. Кодалар белән Елдырым бәк, Алтын-Бөртекнең әнисе калым турында, бүләкләр турында сөйләштеләр. Шунда ук туй турында да сүз булды. Кияүнең, тархан боерыгы буенча яуга баруын истә тотып, туйны киләсе елга кичектерергә дип килештеләр. Ашагач-эчкәч, ата белән анага кияү бүләкләрен тапшыргач, кодалар кайтып киттеләр.

Төштән соң Елдырым бәк яшьләр өчен ат чабышлары, төрле уеннар, узышлар ясады. Яшьләр күбесенчә көч сынаштылар — ук аттылар, сөңге ыргыттылар...

Кич Елдырым бәк кодалар өчен аш-су ясады. Кияү, боегып, зарыгып, ялгыз өендә утырып торды. Аңа аннан беркая чыгарга ярамый иде. Бары тик караңгы төшкәч кенә аның янына яңадан кызлар килде, җиңги килде. Шулай ук үзләре далада корган авылдан кияу егетләр килеп җитте. Аулак өйдә кичәгечә җыр-бию, уен-көлке башланып китте. Төн уртасында җиңги яшь кияүне тагын бәк өенә, кыз янына алып китте.

Икенче көнне иртән кияүне кыз яныннан чыгып килгәндә «угрылыкта тоттылар». Шундук аны далага, Алтын-Бөртек атасының малларын көтәргә җибәрделәр. Өченче көнне ул Елдырым бәкнең болындай өен җылыту өчен, аркасына капчык асып, далада коры тизәк җыеп йөрде. Шуннан соң учакка утын, чыбык-чабык ташыды. Өйдә бәк белән, бикә белән очрашканда, ничек тә аларның күзенә карамаска тырышты. Иң ахырда ул, алтын таста су җылытып, бәкнең аякларын юарга булышты.

Шулай итеп, бабай-әби йортында кияү йола кушканча эшләргә тиеш кара эшләрнең барысын да эшләп чыкты. Шуннан соң кодалар белән бәк арасында яңадан сөйләшү булды. Елдырым бәк яуга китүче киявенә, кызының бирнәсе итеп, тулысынча коралланган, өчәр аты, кушчысы булган йөз илле кешелек алай бирергә булды.

— Кызым үз өемдә калыр, — диде бәк. — Калымның калган өлешен түләп бетергәч, яудан исән-сау кайтса, үзенә алып китәр. Яудан кайтмаса...

— Алтын-Бөртек үземә булыр! — диде Адай ашыгып һәм, кирәкмәгән җирдә кысылуын шәйләп, үзе тагын кып-кызыл булды.

Елдырым бәк озын буйлы, киң күкрәкле алып бер ир иде. Аның янында Адай әле бала гына иде. Шулай да «бала»ның сүзен беркем дә уенга алмады. Елдырым бәк яшь угланга югарыдан иелеп бер карады да алтын касә белән буза бирде.

— Айак эчәбезмени, кода? — диде ул аңа.

— Эчәбез, кода-бабай! — диде Адай батыраеп.

Чыганак: Нурихан Фәттах. Сызгыра торган уклар. Тарихи роман. Беренче, икенче китаплар. Икенче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 254-263 битләр.

55

Гөлнур ХӘЙРУЛЛИНА

Балан ачымы?

Автобиографик хикәя

Алар хәзер икесе дә олы яшьтәләр. Җиденче дистәне ваклаганнарына да инде биш-алты еллар үтеп китте.

Туганнан алып бөтен гомерләре урман арасында үткәнгәме, алар тормышларын урманнан башка күз алдына да китерә алмыйлар. Беренче өлгергән җиләкләрдән башлап, иң соң өлгерә торган баланга хәтле алар урманда.

Әби җиләк җыя, ә бабай кечкенә үткен балтасы белән көрәк, сәнәк, тырмавыч саплары ясап, кипсен дип аларны агачларга сөяп куя. Икенче килүләренә алар кибеп, җиңеләеп калалар.

Ә инде җәйге яңгырлар үтеп китсә, китә гөмбә – ниндиләре генә юк: гап-гади каен, усак гөмбәләреннән тыш, нарат гөмбәсе, гөрәҗдә һәм инде иң атаклысы, гөмбәләр патшасы – ак гөмбә. Соңгысы бу тирәләрдә сирәгрәк очраса да, урыннарын белгәч, җитәрлек җыеп алалар. Әби аны тозлый, маринадлый, киптерә, туңдыра, кыскасы, телеңне йотарлык ризыклар әзерләп куя.

Каен, кура, нарат җиләге, мүк җиләге, карлыган инде җыеп урнаштырылган, бүген алар Кондызлар утравына балан җыярга баралар.

Баланга, гадәт буенча, берничә тапкыр көзге кырау төшкәч кенә барыла, ул чакта инде балан мөлдерәп пешкән, аңа татлы тәм кергән була.

Йортта эшләр беткәч, рюкзакларга ризыклар тутырып, көне буена чыгып китәләр алар. Әлбәттә, җәяүләп. Табигатьнең көзге матурлыгына сокланып, кинәнеп саф һава сулап әкрен генә атлауның үз рәхәте, үз хасияте.

Башта авыл артыннан агучы елга аша салынган басмадан чыгасы. Бу басма аларга бик тә кадерле, чөнки беренче тапкыр нәкъ шушы урында очраштылар бит алар...

Басма турына җиткәч, елның-елында кабатлана торган сөйләшү башланды:

– Карчык, исеңдәме, теге чакта монда ике жирда гына салынган иде? «Коткарыгыз, батам!» дигән тавышка йөгереп килсәм, син суда чупырдыйсың, ә яныңда чиләгең йөзеп йөри.

– Ә син, карт җүләр, миннән көләсең! Имеш, монда коенырга, йөзәргә бик җайсыз урын, үзе сай, җитмәсә, төнбоек, камыш; әнә теге башта – Буранкышта колачлап йөзәргә була.

Аннары, кычкырмадым да мин, билдән суда кем бата инде?

– Нинди карт җүләр, ул вакытта миңа егерме яшь! Ә син мин көлгәнгә ачуландың, кып-кызыл булдың... Шуннан... мин сине судан тартып чыгардым... «Әйдә ут ягабыз, кибенерсең, болай кая барасың!» – дидем.

– Ә мин синең күк йөзе кебек зәңгәр күзләреңә бактым... Алар шундый үз итеп, эчкерсез итеп карыйлар иде, ачуым да бетте, урманга карлыган җыярга баруым да онытылды...

Елга буйлап бара торгач, печәнлеккә килеп чыктык. Синауган каен буенда учак ягып җибәрдең. И күтәрелә миннән пар! Шулай итеп, тәки кибендем бит!

– Карчык, син суга егылмасаң, бәлки без очрашмаган да булыр идек. Ышанырлык та түгел, кырык алты ел үткән дә киткән... Биш улыбыз туган. Инде оныклар үсеп килә.

– Кырык алты ел... Ә калганы күпме икән?

– Әй, калганын белергә кирәкмидер.

Авылдан ерагайган саен табигать күренешләре үзгәрә барды. Әнә берәү печәннән кибән куйган, тирә-ягын киртәләп тә алган. Алга таба – вак каенлык. Һәр елның июль башында әби белән бабай шул каенлыкта мунча себеркесе бәйлиләр. Су буендагы юкәлектән ботаклар сындырып, себерке кырыена кыстыралар, уртасында – мәтрүшкә, карлыган ботаклары.

Бабай чабынырга бик ярата, башына башлык, кулларына тышмак киеп, ухылдыйухылдый чабына, әби себерке белән аннан калган парда гына бәргәләнеп ала.

Каенлыкны үтүгә, катнаш урман башлана. Каеннарга сары тәңкәләр асылган; әле кайчан гына җил искән саен куркып-калтырап җилфердәгән усак яфраклары бүген кып-кызыл булып, горур булып яналар. Көз тал, зирекләргә дә тылсымлы пумаласын тидергәләп, саргылт төс йөгерткән.

Шушы шактый озын сихри урманны үткәч, инде ничәмә еллар игелми яткан иксез-чиксез кырлар башлана. Атамалары нинди бит әле: «Өч нарат», «Миркүш», «Миңнегали җеге», «Орлы», «Мөлдер иген»...

– Менә бит, карчык, безнең бабайлар кул көче белән агач төпләп, урманнан кыр ясаганнар, иген иккәннәр. Ә без шул кырларны яңадан урманга әйләндерәбез – әнә, күрәсеңме, яшь агач басып килә.

– Картым, синең армиядән кайткач кукуруз үстергән кырың белән дә шул хәл бит. И-ии, халыкның исе киткән иде ул кукурузларга, яшь бамбук агачлары диярсең, валлаһи. Өлкә газетасыннан хәбәрче килеп язып та китте бит! Хәтерлисеңме, Әһлисафа апа, бозавын эзләп йөргәндә, шул кукуруз арасына кереп адашкан иде. Әтәч кычкыруын ишетеп кенә аңлый бит авылның кайсы якта икәнен...

Менә соңгы борылыш. Алда ачыклык башлана, янәшәдә елга. Совхоз сыерларын шул тирәдә көтәләр, загоны да бар.

Бабай сагышлы күзләрен як-якка йөгертеп ала. Сагышланырлык та шул. Ничәмә еллар ул үзенең газигында бирегә савымчыларны ташыды, сөтне илтеп тапшырды. Ул вакыттагы юллар! Унбиш метр саен машина бата, тәгәрмәч астына агач кисеп саласың, кайчак машинаны аркан белән савымчылар тартып чыгара.

Менә аларның тукталышы. Шактый ук уйсу урынның бер читендә әкәмәт юан, төптән үк ботаклы мәһабәт нарат тора. Арканны кәүсәсенә терәп утырсаң, коеп яуган яңгырда да чыланмыйсың. Бераз ял иткәннән соң, рюкзакларын нарат төбендә калдырып, биек абагаларны ера-ера, елга буена килделәр. Хәзер кондызлар елгага аркылы аударып салган бик юан, ботаклы усак аша теге якка чыгарга кирәк.

Әби алдан бара, бабай, мәзәкли-мәзәкли, аның артыннан:

– Карчык, карабрак чык, бу сиңа теге вакыттагы билдән су түгел, тартып чыгара алмам.

Әби дә төшеп калганнардан түгел:

– Һе, 20 яшьлек кызны ярдан торып кына бер кулың белән тартып алдың да хатынлы булдың. Җитмешкә җиткән карчыгыңны үзең төртеп төшермәгәең дип куркып барам әле.

– Сине төртеп төшерсәм, баланны кем җыяр да, балан бәлешен кем пешерер соң аннары?

Баланлы утрауга керер алдыннан тагын бер елганы кичәсе бар бит әле, нигә шулай борылма ясап ага торгандыр инде. Монысы аркылы көянтә кебек дугаланып торган тал ауган. Бабай әбигә ике озын таяк кисеп бирә, әби тал буенча сакланып кына аякларын кучерә-кучерә, аргы якка чыга. Олпат гәүдәле бабай тал аша чыгарга җөрьәт итми, арырак китеп, ауган чыршы аркылы чыга.

Суга иелеп үскән баланнарның кайсысы корган – һаман да шул кондызлар эше инде, тамырларына зыян китерәләр, утрауга таба канаулар казыйлар.

Кинәт колакка челтерәп аккан чишмә тавышы килеп керде. Баксаң, кондызлар елганы буган җирдә су өскә күтәрелеп, үзенә күрә шарлама хасил иткән икән. Әлеге күренеш кеше кулы тимәгән утраучыкка сихри бер ямь өстәгән.

Әби белән бабай бу серле манзарага бик озак карап тордылар. Тирә-як тып-тын. Төнлә эшләп арган кондызлар ял итә. Кошлар инде китеп беткән. Калганнары кеше күзенә чалынмаска тырыша.

Ике сәгать эчендә ике чиләк балан җыеп та алдылар. Кергән юл белән азапланып кире чыккач, карт нарат төбендә ял итеп алдылар. Бабай яшен сугып аударган каеннан тузлар, кайры, ботаклар җыеп килде, әби җәһәт кенә учак тергезеп җибәрде.

Үз гомерләрендә күпме учак якты алар... Печән өстендә шул учак янында җылынып ял итүләр. Корымланып беткән чәйнектә

мәтрүшкә, кура, карлыган яфраклары салып чәй кайнатулар...

Бабай термостан агызган чәйне эчкәндә тагын шаяртып алды:

– Карчык, теге вакытта карлыгансыз кайткач өйдәгеләргә нәрсә дип ялганладың син?

– Соң, «тулы чиләк карлыган белән суга егылдым» дип ялганларга үзең өйрәтеп куйдың ләбаса!

Бабай көлеп җибәрә:

– Кара инде бу хәтерне! Хәер, аптырыйсы юк, бик күп еллар үтте бит. Менә бу баланны да ничә еллар җыябыз бит инде. Исеңдәме, беренче килгәндә, зур наратка сыенып үскән каенны күргәч, кулларыңны чәбәкли-чәбәкли: «Син – нарат, мин – каен, – дип такмаклаган идең. – Нарат каенны җил-яңгыр тидерми саклый, алар да безнең кебек татулар», – дидең.

– Матур яшәдек без синең белән. Мәзәк сөйләп, елыйсым килгән чакта көлдерә идең бит син. Әнкәй мәрхүмә дә көләргә ярата иде бит, сиксән яшендә дә яшь кызлар тавышы белән челтерәтеп көлә иде. Ә әткәй сине: «Көлдермә әле шуларны, кеше ишетсә, җүләрләнгәннәр дип уйлар. Кара әле бу картлачын да, ничек айгылдый бит!» – дия иде. Аннары без тагын тыела алмый көләбез.

– Көлү гомерне озайта бит ул. Әнә әткәй, азрак көлгәч, сиксән биштә китеп барды, ә әнкәй сиксән тугызны тутырды. Ә син, гөлкәем, йөзне тутырырсың дип уйлыйм.

– Анысы Ходай кулында инде. Тик мин йөзгә житеп, саташып, җиңеләеп утыруымны теләмәс идем. Картым, алай да минем тормышка ашмаган бер хыялым калды: печәнлектә, үләннең иң йомшак, чәчәкле урынында туйганчы йоклау! Тәгәрәп-тәгәрәп... Яшь вакытта йокы эләкмәде. Эш, йорт, балалар... Бигрәк тә печән өстендә авыр иде. Төш турысында, велосипедка атланып, бала имезергә кайтып китәм. Малайларның дүртесен печән өстендә имезергә туры килде. Кул белән чапкач, печән әзерләү икешәр айга сузыла иде, яңгырлы җәйләрдә сентябрь аенда да чаба идек бит.

– Ә мин, карчыгым, сиңа шәһәр кешеләре кебек, матур букетлар бүләк итә алмадым.

– И картым! Син миңа алып кайткан ул кыр чәчәкләре шәһәр чәчәкләреннән мең мәртәбә затлырак, мең мәртәбә кадерлерәк иде! Аннары, укытучы булып эшләгәч, бик күп җәмәгать эшләрен дә тартырга туры килде бит миңа. Синең беркайчан каршы сүз әйткәнең булмады, киресенчә, үзең дә катнашып, булышып яшәдең. Ул без куйган спектакль, концертларны гына ал. Хәтта урыс теленнән тәрҗемә итеп куя идек бит! Крыловның «Пирог»ын куйганда, Иванга – кызыл күлмәк, асрау кызга – сарафан, кофта тектем, хәтта барыняларга эшләпәләрне дә үзебез ясадык бит! Үрдәк, каз ите белән пешергән олы дөгеле бәлешне соңыннан бөтен халык авыз итте. Ул спектакльне караганда халыкның көлгәннәре – менә әле дә күз алдымда тора.

...Әнә шулай, узган гомерләрне искә төшереп, байтак утырдылар алар. Кояш төшлектән узгач, учакны сүндереп, кайтырга кузгалдылар. Бабай балан белән тулы рюкзакны җилкәсенә асып, таягы белән аякларына ярдәм итә-итә, алдан атлады, чиләкләрне күтәргән әби аның артыннан теркелдәде.

Нарат белән каен үскән турыга җиткәч, әби наратның очы корый башлаганын күреп алды. Аңа бик кыен булып китте, «картым күрмәсә ярар иде» дип уйлап, сүзсез генә атлаган картына карады.

Бераз баргач бабай: «Карчыгым, нарат корый башлаган бит...» – дип куйды.

– Әй, давыл кагылып үткәндер әле... Әнә, һаман каенын саклап тора бит, баһадир кебек әле ул...

– Әйе, агачларның да адәм баласы аңлый алмый торган әллә нинди хикмәтләре, серләре бар... Әнә күрәсеңме, алар тирәсендә күпме нәни нарат, каеннар үсеп чыккан. Киләчәктә бу урында урман шаулап торачак. Димәк, карт нарат белән каенның нәселләре дәвам итәчәк дигән сүз...

...Бу баланга бару соңгысы булган икән – кыш үтеп барганда бабай дөнья куйды. Әби ул җыйган баланнан аның ашларына балан бәлеше пешерде...

Мөхәммәт ГАЛЛӘМ

Тугры юл

«Исра» сүрәсе, 9нчы аять.

«Шик юктыр ки, бу Коръән иң тугры юлга юнәлтүче; изгелек кылган мөэминнәргә үзләре өчен бөек бер әҗер алачаклары турында сөенечле хәбәр китерүче».

Белем вә мәгариф

Әфәнделәр!

Шундый бер гасырда яшибез ки, бу заманда гыйлемсез яшәү һич мөмкин түгелдер. Белем вә мәгариф – динебезнең нигезе саналадыр. Дөнья-ахирәтебезнең бәхете өчен гыйлем зарури булуында шөбһә юктыр. Ирегетләргә вә хатын-кызларга шәригатебез гыйлемне фарыз кылмыштыр, гыйлемнән дә бөек бер гыйбадәт юктыр. Бер сәгать гыйлем алу еллар буена гыйбадәтләр кылып яшәүдән артыктыр. Бер тиенләп булса да, гыйлем юлына ярдәм итү – башка урыннарга йөзәрләп бирүдән дә артыктыр.

Тәкрарлыйм – заманыбыз шундый бер замандыр ки, гыйлемсез вә мәгърифәтсез тору – камил тормыш түгелдер. Рәсүлуллаһның (с.г.в.) бу хактагы хәдис-шәрифләре безгә киң хакыйкатьтер, гомерлек бер канундыр, чөнки гыйлем – динебезнең төп нигезедер.

Мөхтәрәм пәйгамбәрләрдән гыйбрәтләник – алар да бит үз кәсепләре белән тереклек кылдылар. Бертуктаусыз гыйлем өйрәттеләр: «Мин – пәйгамбәр», – дип тормадылар. Менә бу мөхтәрәм затлар сүзләре белән дә, эшләре белән дә безгә өлге-мисаллардыр. Бу яктан алар бөтен халыкка үрнәк булдылар, барлык эшләре халыкны яктыртуда булды.

Мөхтәрәм җәмәгать! Без бу хакта кимчелек кылабыз, гыйлемгә вә аңа ярдәмгә түбән карыйбыз. Бу начар гадәтебезне калдырсак икән!

Мөхтәрәм зыялыларыбыз, хәлле кардәшләребез! Дәүләтегезнең кадерен белегез, хәләл урыннарга гына сарыф итегез, байлыкларыгыз белән горурланмагыз, Хакка әҗере кылынмаган байлыкта шатлык юктыр, торганы бер үкенечтер. Милләтебезнең ярдәмгә иң мохтаҗ урыннары – яңадан ачылган мәдрәсәләребездер. Мәчетләребез вә мәдрәсәләр файдасына малыбызны сарыф итәргә гайрәт күрсәтик. Зәкятләребезнең иң урынлы җирләре – мәдрәсәләр вә андагы шәкерт, укытучылар булуын онытмыйк. Дини гыйлемсез надан кавемнең азагы һәлакәттер. Шул һәлакәттән коткара торган юл бер генә – халкыбызның ихтиһады, хәллеләребезнең юмартлыгы, милләттәшләребезнең ихласлыгы вә тырышлыгыдыр.

Ислам динендә булып, тормышларын әйбәт гамәлләр, юмартлык үрнәкләре белән бизәп яшәгән ерак бабаларыбыздан үрнәк алыйк, аларның шәрәфле вә гыйззәтле яшәүләре зиннәтле вә ялтыравыклы тормышларында, йорт вә җирләрендә, кием-салымнарында чагылмаган, бәлки милләтебезгә карата чиксез зур ярдәм күрсәтүләрендә, дин өчен тырышуларында күренгән.

Көн-төн тырыштылар, торган шәһәр вә авылларында мәктәп, мәдрәсә вә мәчетләр, китапханәләр тергезделәр. Шәрәфле вә мәңге онытылмаслык гамәлләр шулардыр. Моны сез дә онытмагыз, тарихта гүзәл исемегез калсын дисәгез – милләт вә динебезнең хаҗәт урыннарына мал вә дәүләтегездән өлеш чыгарыгыз!

Әй, фәкыйрьләр!

Аллаһуның тәкъдире белән фәкыйрьлек хәленә дучар булгансыз икән – фәкыйрь булуыгызга хурланмагыз, хафаланмагыз. Кыямәт хисабыгыз җиңел, дәрәҗәгез бөек булачактыр. Фәкыйрьлек – хурлык түгелдер. Шулай да, динебез фәкыйрь булырга кушмый, һөнәр вә

кәсеп итәргә боера. Фәкыйрь булуга юл юктыр. Инде берәүләр тырышып та эше уңмый, бу хәлгә төшә калса – сабыр итү тиештер. Йөз суыгызны түгеп, берәүләргә сорарга баруыгызны иң соңгы чиктә генә кулллансагыз икән. Рәсүлуллаһ Әкрәм: «Берәү теләнүдән бер ишек ачса, Аллаһ аңа фәкыйрьлектән җитмеш ишек ачар», – димештер. Инде берәү йөз суын түгеп, сорап килсә – сез, мал ияләре, аны рәнҗетә күрмәгез, хәерле ярдәмдә була күрегез.

Мөхтәрәм яшьләребез!

Сез мәчет вә гыйбадәтханәләр хозурына ихласлык вә күңелегездә ташыган мәхәббәт белән киләсез, Җәнаб Аллаһ сезләргә сәламәтлек насыйп әйләсен икән. Белсәгез ки, яшьлек вазыйфасы бөектер. Ватан вә мөселманнарның гыйззәт, намус вә шәүкәтен сакламак сезгә йөкләнмештер. Миллионнарча дин кардәшләрегез сезнең белән мактанырлык булсын. Милләтебезнең йөз аклыгы, абруе вә шәрәфенә сәбәп булсагызчы... Саф чәчәк кебек газиз вакытыгызны бушка үткәрмәгез: дин вә милләтебезгә файдалы гамәл белән көннәрегезне бизәгез – милләтегез сездән күп нәрсәләр көтә. Киләчәктә милләтебез агалары булачагыгызны онытмагыз. Дин вә милләтебезгә һавалы караш белән түгел, олуг бер ихтирам белән карагыз.

Яшьлек гаярьлеге вә кызулык белән олугларга зарарлы тел озайтмагыз. Үткән заманнарга яраган күп нәрсәләрнең, шулай ук олы буын вәкилләренең сезгә бик үк килешеп җитмәгән урыннары да булыр. Аларны ихтирам итегез. Сез үзегез дә берзаман картаеп, үзегездән яшь булганнар тарафыннан шундый хәлгә төшү ихтималын онытмагыз, тәүфыйктан аерылмагыз. Ата-аналарыгызны хөрмәтләгез, аларга һәм бер-берегезгә шәфкатьле булыгыз. Өммәтебезне киләчәктә бәхетлерәк яшәтә алырлык кыйммәтле кешеләр булып, ил агалары булып җитешергә гайрәт итегез!...

Мөхтәрәм мөселманнар!

Гаиләгез белән гүзәл гомер кичерегез, аларны гүзәл тәрбия кылыгыз. Коръән Кәримдә әйтелгәнчә, хатыннарыгыз белән күркәм мөгамәләдә булыгыз, аларны рәнҗетмәгез, сукмагыз, сүкмәгез, тиешсезгә аерып җибәрмәгез. Бер дә торырга мөмкин түгел икән – мәһәрләреннән мәхрүм итеп, хур итеп аерылышмагыз. Шәригатебездә аеру дигән нәрсә булса да, иң актык бер чиктә генә булырга тиештер. Балаларыгызның сәгадәте, киләчәктә кеше булып үсүләре – хатыннарыгыз белән гүзәл яшәүгә кайтып каладыр. Ата-анагызны олылагыз, аларга: «Уф...», – дип тә әйтмәгез. Һәрвакыт шатландырып торыгыз. Үзегезне тәрбия итеп үстерүчеләр шулар икәнен хәтерегездән чыгармагыз. Вафат булсалар – каберләренә барып, тез чүгеп, дога укып, рухларын шатландырыгыз. Кардәшлектән киселмәгез, фәкыйрь кардәшләрегезнең күңелләрен табарга гайрәт итегез, аларны рәнҗетмәгез.

Күршеләрегез теләсә нинди бер милләттән булса да – алар белән гүзәл торыгыз, күршелек хакының олуг булуын онытмагыз.

Әй, мөселманнар, үзегезнең бу галәмгә мөселман булып килүегезгә, динебезнең кадерен белегез. Гел гыйбадәттә булып, һәртөрле ваклыклардан: ялганчылык, эчкелек, зина кылу, ялганга шәһадәт бирү, бер-берегезгә золым вә хыянәт итү, хөсетлек кылу, монафикълык кылу, гайбәт, ата-анагызны рәнҗетү, намаз-ураза калдыру кебек гөнаһлардан сакланыгыз!.. Аның химаясендә яшәгән хөкүмәтебезгә итагатьле булыгыз. Ватаныбызның кадер вә хөрмәтен белик!

Әй, кардәшләр! Бу дөньяда гомерләребез аз булса да – милләтебез вә халкыбызның гомере озындыр. Шуны онытмыйк, гүзәл эшләр калдырырга гайрәт итик. Һәркайсыбыз ялгыз башыбыз белән тар каберләргә керәчәгебезне онытмыйк. Гарасат мәйданына җыелып, һәрбер гамәл вә эшебез өчен хисап алыначагын онытмыйк!

Чыганак: Мөхәммәт Галләм. Тугры юл: вәгазь-нәсыйхәт вә хөтбәләр. – Уфа: 2010. – 79-85 битләр.

Хәрәкәтле уеннар

Сикереш

Балалар уң аякларын алга сузып, тыгызланып түгәрәккә басалар. Сигнал буенча барысы да читкә сикерәләр һәм зур түгәрәк хасил итәләр. Сикергәндә кем «мин беренче» дип башта кычкырып кала, шул искәрмәстән үзе янында торган иптәшенең аягына килеп басарга тырыша. Әгәр баса алса, аягына бастырган бала тагын үз чиратында күршесе аягына басарга тырыша. Шулай итеп, түгәрәк буенча аякка басыш китә. Аягына бастырганнар уеннан чыга бара. Уен түгәрәктә балалар беткәнче дәвам итә. Иң соңыннан калганы җиңүче санала.

Зиһен сынаш уеннары

Күз кысыш

Уйнаучылар аллы-артлы булып парланып түгәрәккә басалар. Берсе парсыз кала. Ул алгы яктагы иптәшләренең берәрсенә күз кыса. Ул исә үз чиратында җәһәт кенә күз кыскан кешенең янына барып басарга тиеш. Арттагы кеше исә алдагы иптәшен тотып калырга тырыша. Сизми калса, алдагы бала күз кысучыга китә. Аннан парсыз калган кеше күз кыса һ.б. Бер мәртәбә күз кысылган парлар урыннарын алмашалар. Уен шул рәвешчә берөзлексез дәвам итә.



Фотосурәтләрдә Төмән өлкәсе Түбән Тәүде районы Тарман авылы балалары.

Тел көрмәкләндергечләр

Мин агамны агалаган,
Атын дагалаганмын.
Бер кат түгел, күп мәртәбә
Дагалаганмын.

* * *

Аттым карга,
Төште карга,
Карга төште ак карга.
Шул карганы
Карар өчен
Карга җыелган карга.

* * *

Килгән Гата, кигән ката,
Уң аякта сул ката.
Катада түгел хата,
Ката киелгән хата.

* * *

Җәен җиләк җыйганда
Җәмилә җиңен җырткан.
Җылый ла җаным Җәмилә.
– Җылама, җаным
Җәмилә, җәен җиләк
җыйганда, җиңеңне
җамармын, җәме,
җаным Җәмилә!

* * *

Өйгә кергән чыпчык,
Очып йөри чып-чып,
– Чыпчык, чыпчык,
чык, чыпчык!
Очып чык, чыпчык,
чык, кошчык!
Чык, чык, кошчык,
очып чык!

Чыганак: Татар халык уеннары.
Төзүчесе Рәшит Ягъфәров. – Казан:
«Раннур» нешр. , 2002. –
35-37, 40, 160, 193 битләр.

Табышмаклар

Бик югары очадыр,
Зәңгәр күкне кочадыр.
Бала куян аны күрсә,
Оясына качадыр.
(Бөркет)

* * *

Әнәс аның кыштырдык
Тунын салдырып атты.
Ә ул аны ачуыннан
Көне буе елатты.
(Суган)

* * *

Майда җиргә күмделәр,
Җәй буена көттеләр.
Ә көз көне бер урнына
Унны җыеп кэрделәр.
(Бәрәңге)

* * *

Кырык катлы тун кигән,
Ничек ул ярылмаган.
Тунны төймәләр иде дә,
Сәдәпләр тагылмаган.
(Кәбестә)

Табышмаклар Гөлнур Хәйруллинаның
«Урман мәктәбе» китабыннан алынды.

Чулпы

Кайсы гына заманда яшәсә дә, озын толымлы кызлар һәрчак сокландыра, алар һәрчак күз уңында. Татар кызларының чәчләрен озын итеп үстереп, толымнарын бизәп йөрүе элек-электән табигый саналган. Матур чәч бизәгечләр милли киемнең бер өлеше булып торган. Кыз баланың чәче үремгә керерлек булуга, аларга чулпы такканнар. Чулпыларны көмеш, җиз тәңкәләрдән – вак акчалардан, чукып, чүкеп, нечкә җиз чыбыклардан үреп ясаганнар. Кыйммәтле асылташлар белән бизәлгәннәре дә булган. Элеккеге чулпыларны кулга алып карасак, алар шактый авыр. Бу авыр чулпылар хатын-кызларның толымнарын артка тартып торган. Шуңа күрә татар кызлары гәүдәләрен туры тотып, төз басып йөргәннәр. Чулпының асылма бизәкләре бер-берсенә бәрелеп чыңлап торырга тиеш булган. Татар кызының килгәнен башта ишетәсең, аннары күрәсең, дигән гыйбарә дә шуннан килеп чыккандыр, мөгаен. Алай гына да түгел, элеккеге ышануларга карасак, чәч толымы бизәгечләре күз тиюдән саклый дип уйлаганнар. Аның чыңы явыз көчләрне куркыта дип ышанганнар. Чулпыларга кызыл акык (сердолик) куярга яратканнар. Акык сәламәтлек, иминлек, шатлык һәм байлык китерүче таш дип исәпләнгән.

Чылтыр-чылтыр, зең-зең...

Бүген дә озын толымнарына матур итеп чулпылар тагып йөрүче асыл кызларыбыз бар. Зәйнәп Хөснуллина 180 нче гимназиянең дүртенче классында укый. Фортепиано, скрипкада уйный, төрле чараларда матур итеп татарча шигырьләр сөйли, «Нур» театр студиясенә йөри. Күптән түгел генә гимназияләрендә узган «Ак яулыклы әбием» конкурсында үзе иҗат иткән шигыре белән бик матур чыгыш ясаган. «Әбиемнең сандыгы» республика бәйгесендә катнашып та беренче урынны яулаган. Бу конкурска әзерләнгәндә Зәйнәп калфак тарихын өйрәнгән. Үзенең чыгышында калфак турында сөйләп кенә калмыйча, калфак ясау буенча мастер-класс та күрсәткән. Кичләрен әнисе Ләйсән белән бергәләп кул эшләре эшләргә яраталар. Калфак, чулпы, төрле чәч бизәгечләре ясап куйганнар, әнә. Аларны төрле бәйрәмнәрдә чыгыш ясаганда кулланам, ди Зәйнәп. Гимназиягә йөри торган биштәре дә милли бизәкләр белән бизәлгән аның.

Ә безнең журналга исә, Зәйнәп Хөснуллина чулпы ясау буенча мастер-класс әзерләде. Әйдәгез, бергәләп үзебезнең милли чәч бизәген ясарга өйрәнәбез!

1. Иң беренче, китаптан яки интернеттан чулпы үрнәген табып куегыз. Шуңа карап, чулпының рәвешен китерү уңайлы булачак.

2. Кул эшләре өчен төрле кирәк-ярак сатыла торган кибетләрдә чулпы өчен кирәкле материалларны алырга мөмкин. Без менә шундыйларын булдырдык. (Рәсем №1)

3. Чулпы ясаганда тимер бизәкләрне нәни тимерчыбык белән нәзек «карга борыны» (тонкогубцы) ярдәмендә бер-берсенә тоташтырабыз. (Рәсем №2)

4. Чулпы бизәкләрен бер-берсенә симметрик рәвештә урнаштырганда матур килеп чыга. (Рәсем №3)

5. Бизәкләрне бер-берсенә тоташтырып бетергәч, иң өстәге алкага ефәк лента, яки нечкә күн бау (иң мөһиме нык булсын!) тагабыз. Бу чулпыны чәч толымына беркетү өчен кирәк. (Рәсем №4)

Зәңгәр кашлы чулпыбыз әзер! Әлбәттә, бүгенге мастер-класс нәкъ элеккечә асылташлар куеп, кыйбатлы тәңкәләр белән чулпы ясауны күздә тотмый. Һәркем үзендә булдыра алган материал белән генә эшләдек. Мондый чулпыны һәркем ясый һәм бәйрәмнәрдә куллана ала. Гади булса да, балаларга гореф-гадәтләребезне аңлату өчен файдалы эш дип уйлыйбыз.

Гаилә белән бергәләп кул эшләре эшләргә яратучы укучыларыбыз! Сез дә үзегезнең иҗади эшләрегезне безгә җибәрегез, журнал укучыларыбызга өйрәтегез, һөнәрләрегез турында сөйләгез!

Сездән хатлар көтәбез!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Гөлҗимеш

Балачактан иң матур хатирә: дәү әнием кечкенә ак чәйнекне кайнар су белән чайкап ала да киштәдәге төргәккә үрелә. Төргәкне сүтеп җибәргәч, шифалы үләннәр җыелмасы: мәтрүшкә, тукранбаш, кура җиләге яфрагы һәм чәй кәгазенә төреп куелган гөлҗимеш кәтере килеп чыга. Үләннәрне кара чәй белән кушып чәйнеккә сала да, өстенә самавырдан кайнар су коя. Аннан ул, чәйнекне йомшак сөлге белән төреп, мич алдына урнаштыра. Җәйге болын исләре чыгарып тәмле чәй пешә, өй эче тагын да ямьләнеп китә. Менә шул тылсымлы чәйнең бер ингредиентын – гөлҗимеш кәтерен, без бүген Апас районы Каратун авылында яшәүче дәү әниебез – Фатыйма Сираҗиева белән сезнең өчен махсус бергәләп әзерләрбез.

«Кәтер» сүзен безнең Тау ягында әбибабайлар күп куллана. Ачлык елларында алабута орлыгы кушып пешерелгән бәрәңге кәтере ашап яшәүләрен еш искә алып сөйли алар. Камыр ризыгы уңмыйча, катып киткән булса, «кәтер булган бу» дип бәя бирәләр.

Гөлҗимеш кәтере җәйнең һәм көзнең иң файдалы җимешләреннән әзерләнә.



Кирәк була:

1. 1 кг гөлҗимеш
2. уртача зурлыктагы 4 алма
3. кура җиләге, карлыган, җир җиләге яфраклары, мәтрүшкә (үләннәрнең төрлесен, үзегез теләгән күләмдә кушарга мөмкин).

Эш барышы:

1. Гөлҗимеш, алмаларны юабыз.
2. Үләннәрне, гөлҗимеш, алмаларны – барысын бергә кушып иттарткычтан чыгарабыз.
3. Чыгарылган хуш исле массадан кечкенә коймаклар ясап, майланган табага (таба астына махсус кәгазь дә җәяргә ярый) тезәбез һәм мичкә куябыз.

4. Коймаклар әйбәтләп кибеп, кәтер рәвешенә керсен, ләкин күеп китмәсен өчен мичне 200-220 градуска кадәр кыздырабыз да, сүндереп тотабыз. Мич суына төшкәч, яңадан кабызып кыздырабыз, аннары яңадан сүндереп суытабыз. Шулай 2-3 кат кабатлана. Кәтер, озак саклансын өчен, әйбәтләп кибеп бетәргә тиеш. Тиешенчә кибеп беткәч, гөлҗимеш кәтерен ак кәгазьгә тереп, кышкы салкын көннәрдә шифалы чәй итеп куллану өчен җыеп куялар.

Куллану тәртибе:

Гөлҗимеш кәтерен, аз гына чеметеп, кара чәй пешергәндә салалар. Термоста төнәтеп эчәргә дә була. Мондый чәйне иммунитетны ныгыту, тынычлану өчен дә кулланалар!

Сәламәт булыгыз! Табигать белән бер сулышта яшик!

Укучыларыбыз! Сезнең якларда гына әзерләнә торган төрле аш-су рецептлары бардыр. Аларны безнең журналга да язып җибәрсәгез иде!

Раилә САБИРОВА

Сатуда бәя иректе

ИНДЕКСЫБЫЗ– 16987

Себер күле. Гөлсинә Хәмидуллина фотосы.

Кадерле укучыларыбыз!

Гомеребезнең тагын бер елын бергәләп йомгакларга җыенабыз. Илдәге вазгыять шактый катлаулы бу елда, күңелегезгә күпмедер җылылык, рухи азык бирә алганбыз икән, димәк, без дөрес юлда. Алдагы елларда да бездән аерылмассыз дип ышанабыз.

Исегезгә төшерәбез: 2019 елның беренче яртыеллыгы өчен матбугатка язылу төгәлләнеп килә. «Түгәрәк уен»га республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә дә язылырга мөмкин. Безне МАП (Межрегиональное агентство подписки) каталогыннан эзләгез.

Индексыбыз –16987. Ярты елга язылу бәясе – 278 сум 53 тиен.

Бергә булыйк!